Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 13 (1429) 7 апрель 2023 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

2

Илебездә патриотлык тәрбияләгәндә туган төбәккә, кече Ватанга мәхәббәт кирәклеге турында онытып җибәрәләр.

8

Рәссам Хәмит Латыйпов сәнгатебезне югары дәрәҗәдә пропагандалап кына, яшьләрдә телебезгә, милләтебезгә карата хөрмәт тәрбияләп була дип саный.

12

Мәчетләрнең бар агы, алсуы, яшеле, күзгелесе – искиткеч гыйбадәтханәләр дөньясына сәяхәт.

Галиҗәнап Татар Сүзенә дә Яшәү фарыз иман китереп!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстанның күренекле фотографы Фәрит Гобәев Россиякүләм «Алтын каләм» конкурсының «Алтын киштә» номинациясендә җиңү яулады.

- Уфаның Милли яшьләр театрында Мостай Кәримнең «Авыл адвокатлары» повесте буенча «Силсәүит, Алдар һәм Адвокат» спектакленең премьерасы булды.

- 9 апрельдә Казанда «узачак «Fashion Iftar»да катнашучылар арасында гомрә хаҗына юллама уйнатылачак, иң актив волонтерга да юллама тапшырылачак.

- Мәскәүнең Татар мәдәнияте үзәге китапханәсендә язучы, «Татар дөньясы» газетасының баш мөхәррире Ринат Мөхәммәдиевнең яңа китабын тәкъдим иттеләр.

- Казанның Ф.Аитова исемендәге 12 нче гимназиясендә Туфан Миңнуллин исемендәге республика конференциясе узды.

- Төркиянең югары уку йортларында укучы 70 тән артык татар студенты һәм актив яшьләр өчен Истанбулда ифтар узды.

- 10 майда Г.Камал театрында олылар өчен татарча тулы метражлы беренче мультфильм – «Әлдермештән Әлмәндәр» күрсәтеләчәк.

- Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла төрки шагыйрьләрнең Үзбәкстанда узган «Мумтаз шигърият» фестивалендә катнашты.

- Казан шәһәре Башкарма комитеты татар телен өйрәнү һәм татар мәдәниятен үстерүгә багышланган «Үз телем» бәйгесенә гаризалар кабул итә башлады.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Алсу ХӘБЕТДИНОВА, Чаллы татар драма театры артисты:

«Безнең халык «чәйнәп, әвәләп каптыра» торган спектакльләргә ияләшкән. Әлбәттә, хәзерге спектакльләр күп сораулар калдыра. «Бу болай икән бит», – дип карады да, чыгып китү белән эчтәләген онытты түгел. Шактый фәлсәфи спектакльне кабул итмәүчеләр дә юк түгел. Алар булырга тиеш тә. Күктәге кояшны да бит кайбер кеше: «Әй, нинди рәхәт кояш, җылыта», – ди. Икенчеләре аннан кача, «эссе бүген» дип, битен яшерә».

СЫНАМЫШЛАР

7 апрельдә аяз булса, җәй яшенле була; бу көнне яшенле яңгыр яуса – тиздән җылыта; түбәләрдә кар ятса, ул 6 майга кадәр эремәячәк; бу көнне карлыгачлар очмаса, яз салкын була ● 8 апрельдә нинди көн булса, 8 октябрьдә дә шундый һава көтелә ● Язын эретмичә озак тундырып торса, җәен корылык фаразлана ● Каен суы күп акса, җәй яңгырлы була ● Сыерчыклар килгәч, чын яз башлана ● Елгаларда боз тиз эреп бетсә, ел уңышка бай була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 01 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 32 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **13 сәгать 31 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **14 апрельдә 14 сәгать 03 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

7 апрель – Бөтендөнья сәламәтлек көне.

11 апрель – Халыкара фашист концлагерь тоткыннарын азат итү көне.

10 апрель – 140 ел элек Бакчасарай шәһәрендә төрки-татар телендә «Тәрҗеман» газетасы нәшер ителә башлый (1883–1918);

– артист, нәфис сүз остасы, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Айрат Гәрәй улы Арслановның тууына 95 ел (1928-2010);

– җырчы, Татарстанның халык артисты Азат Тимершаех улы Хөсәеновка 65 яшь (1958).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Апрельнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 10, 11 апрель.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(6-13 апрель)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рамазан аеның 16 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ

Иршад ГАФАРОВ

ПАТРИОТЛЫК...

Үткән елның август аенда Алабуга шәһәрендә Россиянең күп төбәкләреннән укытучылар мәктәп балаларында патриотик хисләр тәрбияләү мәсьәләләре турында киңәшмәгә җыелды. Безнең карашка, аның төп нәтиҗәсе – беренче сентябрьдән һәр атна башында мәктәпләрдә дәүләт байрагын күтәрү һәм гимнын җырлау булды.

Ләкин болар белән генә патриотик хис тәрбияләп булу шик тудыра. Әүвәл «патриот» сүзенең нәрсә аңлатуына тукталыйк. Ул грекча «якташ» сүзе, татар телендә аны хәзер «ватанпәрвәр» дип тә кулланалар. Димәк ул ватанын, халкын яратучы, алар өчен бөтенесен эшләргә әзер торучы, дигән сүз. Бу урында «Калкан һәм кылыч» дигән фильмнан җыр искә төшә: «Ватан нәрсәдән башлана? Шәт, ул безгә әни җырыннан башлана торгандыр...» Әни туган телдә җырлады, шуңа да ул безнең заманда икенче төрле – «ана теле» дип тә атала иде. Әгәр җыр онытылса, тел дә онытылырга мөмкин, аның артыннан ватан да... Янә К.Ушинскийның «Тел бетсә, халык үзе дә бетә», – дигән сүзен искә алырга булдык. Моның иң ачык мисалы: Россиядә күп төрле мактаулы исемнәргә, дәрәҗәләргә лаек булган һәм инде телен, динен, ватанын алмаштырган Чулпан Хамматова.

Берничә ел элек Казанда «Бөек Җиңү: мирас һәм варислары» исемле Халыкара Раштуа укулары үткән иде. Анда дин әһелләре, укытучылар, эзтабарлар һәм төрле яшьтәге дингә ышанучылар дин, тәрбия, патриотлык мәсьәләләре турында сөйләшү алып барды. Моның өчен тарихи уен-реконструкцияләр (Питрәч районында Брест крепосте герое П. Гаврилов ватанында), һәлак булган сугышчыларның мәетләрен эзләүдә катнашуның (Казанның 101 санындагы мәктәбе «Коткаручылар» төркеме) әһәмияте билгеләп үттеләр. Бу – яхшы күренеш, ләкин монда аз санда гына катнашучы булырга мөмкин. Шуңа да тарихка беренче адымны укучылар мәктәптә укытучы ярдәмендә ясый.

Бу урында «олы ватан» – Россия һәм «кече ватан» төшенчәләре турында да искәртергә кирәк. Үзенең бер чыгышында В.В.Путин «кече ватан»га мәхәббәт, аның тарихын белү кирәклегенә басым ясады. Безнең өчен ул – Идел Болгарстаны, Казан ханлыгы, Татарстан Республикасы. Уку программаларыннан милли һәм төбәк компонентлары алып ташлангач, укучылар алар турында мәгълүмат алудан мәхрүм ителде. Дөрес, «Эфир» каналында Дәүләт Думасы депутаты Т.Ларионова: «бу эшне һәр атна булачак сәясәт сәгатьләрендә өйрәнергә мөмкин», – дип сөйләгән иде. Үзе мәктәптә озак еллар укытучы булып эшләвен искә алса да, мең елдан артык дәүләт тарихын шул вакыт кысаларында гына өйрәнеп булмаганын оныткан, ахрысы. Шуның өстенә ул инде Мәскәү тарафыннан ике айга сәясәт сәгатьләрендә нәрсә өйрәнергә кирәклеге турында исемлек җибәрелүен билгеләп үтте. Ә аңардан бер адым да читкә китәргә ярамый бит!

Программаларда Смоленск, Чернигов, Новгород һ.б. кенәзлекләр тарихын өйрәнүгә шактый вакыт бирелсә дә, Россиядә гомер кичерүче бүтән халыклар турында искә дә алынмый. Хәер, «тынычсыз күршеләр: болгарлар....», дигән санап үтү бар, димәк, алар еш кына рус җирләренә һөҗүм ясап торган булып чыга. Әмма бу чынбарлыкка бөтенләй туры килми. Бөтен чыганакларда болгарлар тыныч, сәүдә белән шөгыльләнүче халык итеп искә алына. Әле Н.М.Карамзин да заманында алар турында: «хәрби рухлары булмыйча, сәүдә һәм җир эшкәртүне яратучылар», – дип язган иде. Никтер урысныкы булып саналган Юрий Долгорукий, Андрей Боголюбскийларның 1120, 1164, 1172 елларда Болгар өстенә зур яу белән килүе һәм безнең бабаларны талап китүе турында гына телгә алмаганнар.

Үзеннән-үзе сорау туа: «Тарихын белми торып, ватанга мәхәббәт тәрбияләп буламы икән? Без бит «туганлыкны оныткан иваннар түгел!» Мәсәлән, һинд халкы гыйбадәт кылган «ступа», һинд диненең нигезләреннән берсе булган Сансара турында инша язып кына алтынчы сыйныф укучысына Ватанга – «олысына» яки «кечесенә» мәхәббәт хисе тәрбияләп буламы?

Яки җиденче класста атнага икешәр сәгать «Урта гасырларда Европада крестьяннар һәм шәһәр халкының көндәлек тормышы, Иезуитлар берләшмәсе, XIII гасырда Англиядәге аграр революция, бәйсезлек өчен сугыш чорындагы атаклы америкалылар, колонияләр белән идарә итү, Николай Коперник, Джордано Бруно» һ.б. турындагы сораулар белән балалар күңелендә ватанга мәхәббәт хисен уятып булуына һич ышанмыйм!

Ә менә әле 1394 елда ук, ягъни Коперникка кадәр 150, Бруного кадәр 200 ел элек яшәгән Болгар шагыйре Сәйф Сараиның Җир шары галәм үзәге түгел, ул Кояш тирәсендә әйләнә, дигән кыю фикере укучыларда зур кызыксыну тудырыр иде.

Болгарстанда урта һәм югары уку йортлары – мәдрәсәләр булуын билгеләп үтик. Аларда, соңрак танылган галимнәр, шагыйрьләр, тарихчылар, табибләр булачак тырыш яшьләр укыган. Белем алу өчен биредә чит илләрдән дә килгәннәр. Шундыйлардан, Биләр шәһәре мәдрәсәсенә укырга улын алып килүче гарәп галиме Әбу Хәмид әл Гарнатины, мәдрәсәне тәмамлап Анатолия һәм Сириядә эшләгән Ирак кешесе Ибн Хазарны атап була. Югары мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында атаклы галим һәм табиб Әбүл-Гали Хәмид ибн Идрис әл-Болгари, XII гасырның күренекле шагыйре Сөләйман бине Дауд Саксини (Сувари), тарихчы Якуб ибн Ногман әл-Болгари һ.б.

Биредә янә бер параллель үткәрик: Болгарстанда әле X гасырда ук акча сукканнар, ә Русьта беренче тәңкәләр күпкә соңрак күренә башлый. Беренче рус тәңкәләрен сугуның чын вакыты булып XIV гасыр санала. Иң элек, шул исәптән Явыз Иван чорында да, алар ике телдә – рус һәм татарча сугылган. Ә безнең карашка, акча сугу – ул дәүләтнең көчен, аның икътисады һәм мәдәниятенең үскән булуын раслаучы дәлил.

Гарәп сәяхәтчеләренең язуларыннан күренгәнчә, Болгарда астрономия үскән булган, тарихи хезмәтләр язылган, җинаять кодексы булган. Китапханәләр булу турында да мәгълүматлар сакланган.

1133-1134 һәм 1135-1136 елларда Болгарда булган сәяхәтче Әбу Хәмид әл-Гарнати болгар кадие тарафыннан күчереп язылган «Болгар тарихы»н укуы турында язган. Чыганакта аның авторы Якуб ибн Ногман булуы искәртелә.

XI гасырда биредә атаклы галим, табиб, дин белгече Әхмәт Болгари яшәгән һәм иҗат иткән. Соңрак ул Газнада укыган һәм шунда ук зур хөрмәт белән җир куенына иңдерелгән. Ул җирләнгән урында чишмә бар. Аны «Хуҗа Болгари» чишмәсе дип атыйлар. 1971 елда әфганнар Хуҗа Болгари каберенә ак мәрмәр плитәләрдән мавзолей төзи.

Бертуган табибләр Таҗетдин һәм Хәсән ибн Юныс әл-Болгари 1221 елда «Агулануга каршы иң яхшы дарулар» исемендә фармакология буенча трактат яза. Әлеге хезмәт бүген Иран башкаласы Тегеран китапханәсендә саклана.

Идел Болгарстанында шагыйрь Кол Гали (XII гасыр ахыры – XIIIнең башы) яшәп иҗат иткән. 1983 елда Мәскәүдә ЮНЕСКО халыкара оешмасы аның тууына 800 ел тулуны билгеләп үтте. Берничә елдан соң шул ук оешма Мәскәүдә әлегә кадәр авторы билгеле булмаган «Слово о полку Игореве»ның да 800 еллыгын билгеләп үткән булды. Казан дәүләтендә берничә поэма авторы Мөхәммәдьяр яшәгән. Аның юбилее тантаналы төстә Казанда үтте.

Шуннан соң урынлы сорау тумыйча да калмый: «Ә Русьта бу чорларда шундый галимнәр, шагыйрьләр, табибләр булдымы икән?» Википедиядән күренгәнчә, беренче иң күренекле һәм иң билгеле язучы булып XVII гасырда яшәгән протопоп Аввакум санала. Икенче чыганак беренче рус әдәбиятчысы итеп А.П. Сумароковны (1717-1777) атый.

Табылган мәгълүматларга караганда, беренче табиб «немчин Антон» Мәскәүдә – 1485, ә икенчесе – «җидовин Леон» 1490 елда була. Ләкин алар икесе дә кыска гомерле була: елъязмачы раславынча, беренчесен кенәз Коракучины (?) начар дәвалаган өчен Иван III кушуы буенча җәзалыйлар, аннан нәкъ «сарык кебек» суялар. Икенчесен, улының авыруы начар тәмамлану нәтиҗәсендә, бөтен халык алдында җәзалыйлар. Василий Иванович III заманында, Мәскәүдә инде берничә табиб була, алар: Константинопольдан Марк, Феофил (немец), Николай Луев (чит илнеке).

7 сыйныф тарих китабыннан бер өзек китерик: «Василийның Соломония Сабуровадан баласы булмый. Шуңа да ул митрополит Даниил рөхсәте белән аны аера һәм 1525 елда бөек кенәз, үзеннән 30 яшькә кече булган Литва кенәзе кызы Елена Глинскаяга өйләнә. Василий III нең аңа язган хатыннан күренгәнчә, ул «аның кәефе, балалары – 1530 елда туган Иванның, энесе Юрийның сәламәтлеге турында кызыксына». Әлеге хат укучыларда ватанны ярату хисе уятуына шикләнәбез!

(Дәвамы 5 нче биттә).

ҖӘҺӘННӘМГӘ ҖИНАЯТЬЧЕЛ ЮЛ

Җан җәннәт тели – гөнаһ җибәрми, ди мәкаль. Ә гөнаһ эш ул илаһият канунныннан тайпылуны, әдәп-әхлак кагыйдәләре белән санлашмауны, Хак Тәгалә каршында ярамаган язык гамәл кылуны аңлата. Җәмгыятьтә кешеләр өчен куркыныч тудырган һәм закон белән тыелган андый кыңгыр эш-гамәлләр җинаять категориясенә дә керә. Дини кануннар буенча, андыйларга җәза урыны инде җәһәннәмнән билгеләнә. Илаһият кануннарының гөнаһ-газап үлчәмнәре исә җәмгыяви яшәешкә дә бөтен тулылыгы белән кагыла. Әлбәттә, бу җәһәттән катлаулы һәм глобаль колачлы сораулар инсаният яшәешенең хәзерге этабына карата да туа. Кешелек язмышын зур куркыныч астына куйган бүгенге глобаль кризис иблис токымы нигез итеп алган геосәяси (гео – Җиргә бәйләнешле дигәнне аңлата. Сүз, асылда, дөнья тотучылар моңа кадәр үз мәнфәгатьләрендә үткәргән мәҗбүри глобальләштерү сәясәте турында бара) постулатларның ялган булуын фаш итә торган көчле дәлил була түгелме? Бердәнбер һәм универсаль чишелеш метасәясәт (илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү сәясәте) өлкәсендә ятуын аңлагач, аны гамәлгә ашыруның реаль механизмнарын ничек булдырырга?

Беренче сорауга җавапны геосәясәт патриархы, берполярлы дөнья архитекторларының берсе Һенри Киссинджерның фикер сөрешендә бүгенге хәтәр хәлләр фонында урын алган мәгънәви үзгәрешләрдән чыгып эзлик. Узган җәй The Spectator дигән Британия журналына биргән интервьюсында ул Украинадагы низагның мөмкин булган өч чишелешен әйткән иде: Россиянең бу ил территориясенең бер өлешен алып җиңүе; аны Кырымнан кысрыклап чыгару омтылышы; махсус хәрби операция (МХО) башланганчыга кадәрге чикләргә кайту. Икенче вариантны ул Көнбатышның да сугышта катнашу мөмкинлеге белән бәйли. Ә өченче очракта – Украинага коралланү һәм НАТО белән тыгыз бәйләнеш, низагны исә вакытлыча туңдырып торуны юрый. Элегрәк ул үзенең «Лидерлык: дөнья стратегиясенең алты сабагы» дигән китабында, Украинадагы низагның чишелеше аның нейтраль статусын тану аша хәл ителергә мөмкин, дип тә язган иде. Ә быел 17 гыйнварда Давос форумында видеоэлемтә аша ясаган чыгышында Һ.Киссинджер инде, Украинаның НАТО да әгъзалыгы үзен аклый торган чишелеш булыр иде, дип белдерде. Анда ул, Украинадагы низагны җайга салганчыга кадәр, Россия белән диалогны туктатмау яклы булуын да әйтте. Геосәясәт патриархы күптән түгел Мәскәүдә үткән Кытай-Россия сөйләшүләреннән дә үзенчә нәтиҗә ясый. Испаниянең Mundo газетасына биргән интервьюсында ул, Кытай икътисады бүген АКШ икътисады белән чагыштырырлык булуын исәпкә алып, АКШ белән Кытай арасында икенче салкын сугыш башлану мөмкинлеге һәм аның тәүгесенә караганда хәтәррәк булачагы турында әйткән. АКШ һәм Кытай бүген дошманнар булганга күрә, Чин иленең нигезен күтмәскә кирәк итте.

Күрүебезчә, киләчәкне томалаган бүгенге глобаль кризисның аяусызлыгы вә үҗәтлеге геосәясәт әһелләрен дә шактый ук боргаланырга мәҗбүр итә. Чөнки Җирдә яшәешне җайга салырдай яңа идеяләре яки кыенлыкларны ерып чыгуны реаль итәрдәй саллы фикерләре юк. Ә бу инде зур сәясәттә дә кризис башлануы, яшәешне алга таба геосәяси ысул яки алымнар белән генә җайга салып булмаячагы турында сөйли. Бу җәһәттән зур сәясәттә төп геосәяси уенчыларның формалашу тарихын искә төшереп үтү дә урынлы булыр. Мәгълүм булганча, дөнья тотучыларның әле мистерияләр чорыннан ук килгән төп цивилизацион көндәше булып Кытай санала. Көнбатыш цивилизациясе исә, аңа реаль альтернатива буларак, яһүд-нәсара кыйммәтләрендә формалаштырыла. Ә Урталык җирләрендә, алар арасында буфер зонасы һәм идарә ителә торган бербөтен геостратегик киңлек буларак, Россия империясе (Өченче Рим) формалаштырыла. Шуннан бирле ул дөнья тотучылар кулында геосәясәт коралы булып хезмәт итә һәм бу аның бөтен тарихы белән раслана. Зур сәясәттә Көнбатыш һәм Россия әле бүген дә, капма-каршы яктан, әмма уртак максатта (яңа дөньяви тәртип урнаштыру) эш итә. Ә ялган кыйммәтләр, җинаятьчел яшәү рәвеше һәм рәхимсез кан коюларга гына корылган мондый сәясәт кешелек дөньясын бары тик җәһәннәмгә генә китерергә мөмкин.

Хәлбуки, геосәяси кризис кешелек алдына Җирдәге хәятны яңача һәм ышанычлы итеп кору таләбен дә куя. Ә андый юл аның тәкъдиренә үк язылган. Димәк, бәндәләрдән бары тик язмыш кушканны җиренә җиткезеп үтәү, ягъни абсолют кыйммәтләр системасына күчеп һәм илаһият кануннарына (киң мәгънәдә) туры китереп яши башлау гына таләп ителә. Ләкин бүгенге рухи деградация, глобаль кризис һәм тышкы сәясәтнең иске (геосәяси) карашлы яңа концепциясе кабул ителгән шартларда моңа ирешүнең метасәяси механизмнарын булдыру да лязем.

Фоат УРАЗАЙ.

Спектакльләр – киноэкранда

«Татаркино» учреждениесенең Камал театры белән берлектә тормышка ашырыла торган «Кино+Театр» проекты быел бөтен республиканы колачлаячак. Камал театры спектакльләренең видеоверсияләре рус субтитрлары белән татар телендә күрсәтелә.

«Кино+Театр» проекты беренче тапкыр 2019 елда Россиядә Театр елында гамәлгә ашырыла. Әлеге уникаль проект ярдәмендә экраннарда Камал театрының репертуарда булмаган спектакльләре «җанлана».

Быел район кинотеатрлары, муниципаль кино учреждениеләре экраннарында спектакльләрнең видеоверсияләрен күрсәтеп, проектны республикага тарату күздә тотыла.

Камал театры директоры Илфир Якупов фикеренчә, репертуардан төшерелгән спектакльләргә ихтыяҗ зур. Проект кысаларында театрның хәзерге репертуарында булган спектакльләрне күрсәтү дә планлаштырыла.

«Техник сәбәпләр белән бәйле рәвештә без күпчелек спектакльләрне республика районнарына һәм хәтта Мәскәүгә дә чыгара алмыйбыз. Махсус шуның өчен «Кино+театр» проектын уйлап таптык», – ди театр директоры.

«Казанга килеп, театрда спектакльләр карый алмаган тамашачылар кинотеатрларга килеп рухи ләззәт алырлар дип өметләнәбез. Проектның тагын бер өстенлеге – «Кино+Театр» программасына репертуардан төшерелгән спектакльләр кертелгән», – ди «Татаркино» мәдәният учреждениесе директоры Миләүшә Ләбибовна.

Проектның быелгы репертуары Камал театрының танылган актерлары, режиссерларының юбилейлары белән тәңгәлләштереп сайланган. «Кино+ Театр» «Мир» кинотеатрында Марсель Сәлимҗановның 1976 елда видеотасмага яздырып алынган «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле белән башланачак.

Спектакльләр ике ай дәвамында һәр якшәмбе 12 сәгатьтә Казанның «Мир» кинотеатрында һәм район кинотеатрларында, муниципаль кино учреждениеләрендә барачак.

«Кино+Театр» проекты программасы:

9 апрель – «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясе, режиссеры М.Сәлимҗанов;

23 апрель – «Банкрот» комедиясе, режиссеры Ф.Бикчәнтәев;

30 апрель – «Йөзек кашы» драмасы, режиссеры И.Зәйниев;

7 май – «Мәңгелек буран» спектакле, режиссеры И.Зәйниев;

14 май – «Миркәй белән Айсылу», режиссеры И.Зәйниев;

21 май – «Җанкисәккәем» комедиясе, режиссеры Ф.Бикчәнтәев;

28 май – «Бабайлар чуагы» лирик комедиясе, режиссеры И.Зәйниев;

4 июнь – «Мәхәббәт FM» комедиясе, режиссеры И.Зәйниев;

11 июнь – «Сөясеңме сөймисеңме...» моңсу комедиясе, режиссеры – Р.Бариев;

18 июнь – балалар өчен «Авыл эте Акбай» режиссер - Л.Әхмәтова.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

«Тамга» яшьләрне өйрәтә

Г.Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында «TAMGA» режиссерлар лабораториясе уза. Традиция буенча, анда иҗади портфолиосында балалар һәм яшүсмерләр өчен спектакльләр булган яшь режиссерлар катнаша. Быел режиссерлар Олег Молитвин, Лидия Хазова һәм Степан Пектеев чакырылды.

Быелгы лабораториянең темасы – фантастика. Бала чакта барыбыз да шулхәтле оста фантаст булабыз! Үз башыбызда гаҗәеп дөньялар тудырабыз. Үсеп җиткәч тә хыялыйлыгын җуймаган язучылар үз дөньяларын кәгазьгә төшерә, үзләре дә белмәстән, вакытны алдан күрә, күрәзә итә. Ә менә режиссерлар моны ничек итеп күрсәтер икән? Олег Молитвин «Тубагач» (Ш.Идиатуллин) әсәре белән эшли, Лидия Хазова драматург Булат Минкин белән берлектә – Алиса Селезнева турындагы хикәяләр (К.Булычев), ә Степан Пектеев композитор Илнар Фәйзетдинов белән берлектә Адлер Тимергалин әсәрләре буенча эскиз әзерли.

Режиссерларның эшенә театр тәнкыйтьчеләре Жанна Зарецкая, Наталья Шаинян һәм Екатерина Рябова бәя бирәчәк.

Башкортстанга сәфәр

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев Башкортстанга сәфәр кылды. Эшлекле сәфәр кысаларында ул конгрессның Башкортстандагы вәкиллеге үткәргән ифтар мәҗлесендә булды. Ифтарда шулай ук Башкортстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Айнур хәзрәт Биргалин, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Марс Тукаев, Башкортстандагы татар милли-мәдәни җәмгыятьләре җитәкчеләре, татар галимнәре, сәнгать әһелләре, дин әһелләре дә катнашты.

Милли Шура рәисе Тәтешле районында Татарстанның халык артисты Хәния Фәрхигә багышланган музей эшчәнлеге белән танышты.

Шулай ук ул Тәтешле районы Иске Күрдем авылында Әнгам Атнабаевка багышланган музейда да булды. В. Шәйхразыевны мирасханә эшчәнлеге белән Әнгам Атнабаевның энесе, авыл мәчете имамы, 92 яшьлек Мәгъдан Атнабаев таныштырды. Татарстан кунаклары шагыйрь һәйкәленә һәм мәчет янында куелган Гарифулла Киеков һәйкәленә чәчәкләр салды.

2023 елның икенче яртыеллыгына «Мәдәни җомга» газетасына Татарстаннан читтәге өлкә-республикаларда да – Башкортстан, Оренбург, Ульяновск, Төмәндә һәм башка төбәкләрдә язылып була. Газетабыз электрон каталогка кертелгән (язылу индексы – П8254). Игътибар! «Мәдәни җомга» газетасын почта бүлекчәләрендә электрон каталогтан эзләтегез.

1 нче биттә – «Татар сүзе» III Халыкара нәфис сүз телевизион бәйгесенең гала-концертыннан бүләкләү күренеше. С. Камалетдинов фотосы. «Татар-информ».

«Без Тартариядән» – яңа әдәби бәйге

Бу атнада «Мы из Тартарии» («Без Тартариядән») дигән халыкара әдәби бәйге башланып китте. Ул быел беренче тапкыр үткәрелә. «Миллиард татар» оештырган проект хакында «Татар-информ»да узган матбугат очрашуында хәбәр ителде.

Конкурсның максаты татар халкы һәм Татарстанның тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынуны арттырудан гыйбарәт. Бәйге тарихи темаларга иҗат итүче яшь, талантлы авторларны ачыкларга мөмкинлек бирер, дип уйланыла. Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты директоры, тарих фәннәре докторы Радик Салихов республикада, гомумән алганда, тарихи темаларга әсәрләр язу – күптәнге традиция булуын искәртеп үтте. Классик әдипләребез Мәхмүт Галәү, Гаяз Исхакый һ.б. башлаган теманы язучылар Нурихан Фәттах, Вахит Имамов, алга таба Ольга Иванова дәвам итә. Аларның әсәрләре халкыбыз тарафыннан яратып укыла, тарихи романнар белән кызыксыну гаять зур. Р.Салихов тарихыбыз халыкны берләштерергә, милли үзаңны ныгытырга, кече ватаныбызны ярату хисен көчәйтергә, татар халкының тарихи бердәйлеген, мәдәниятебезне, телебезне сакларга тиешлеген билгеләде.

Әсәрләрне «Тарихи хикәя» һәм «Фантастик хикәя» номинацияләренең берсенә тәкъдим итәргә мөмкин.

Язучы, театр һәм әдәби тәнкыйтьче, сәнгать белгече Галина Зәйнуллина конкурска фантастик әсәрләр дә кабул ителүен уңай бәяләде, бездә фантастика темасының әлегә бик йомшак булуына игътибарны юнәлтте. 1980 елларда Владимир Корчагин фантастик әсәрләр яза башлый. Аның «Астийский эдельвейс», «Узники страха» кебек әсәрләрен хәтерлибез әле. Г.Зәйнуллина соңгы вакытта Диана Косареваның фантастика яза башлавын, аның «Биофарфор» дигән күләмле әсәрен искә алды. «Әйбәт әдәби тел белән язылган фантастик әсәрләр кирәк», – диде ул.

Шагыйрь, редактор Эдуард Учаров искәртеп үткәнчә, конкурска беренче гаризалар Башкортстаннан, Киров өлкәсеннән кабул ителгән. «Бу халыкара бәйгенең кирәклеге, аңа ихтыяҗ булуы турында сөйли», – диде ул.

Оештыручылар конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган әсәрләрнең Татарстан һәм Россиядә чыгып килә торган дәрәҗәле матбугатта һәм бәйгенең социаль челтәрләрдәге сәхифәләрендә дөнья күрәчәгенә ышандыра. Конкурсны Россия һәм Татарстан Язучылар берлекләре дә хуплаган.

Җюри составына танылган язучылар, кинематографистлар, тарихчылар, әдәби журналлар мөхәррирләре һәм мәдәният эшлеклеләре кергән. Алар арасында Россия прозаигы, шагыйрь һәм сценарист Денис Осокин («Небесные жены луговых мари», «Овсянки» һ.б.), режиссер, сценарист Салават Юзеев («Курбан-роман: История с жертвой», «Кое-что из ее дневника») һәм башкалар бар.

Конкурста 18 яшь һәм аннан өлкәнрәк авторлар катнаша ала. Бүләкләү фонды 180 мең сум тәшкил итә. Ул алты җиңүчегә бүленәчәк.

Төп номинацияләрдән тыш, аерым бүләкләү каралган – килачәктә сценарий нигезе була алырдай иң яхшы кинематографик текст җюри карары нигезендә билгеләнәчәк. Конкурска эшләрне быелның 30 сентябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Әсәрләр бары тик рус телендә генә кабул ителә. Җюри составына татарча язылган хикәяләрне бәяләрдәй бер татар язучысы да кертелмәгән. Моны конкурсның уйланып бетмәгән бер ягы, дип кабул итәргә кирәктер. Конкурсны оештыручылар алдагы елларда бу мәсьәләне исәпкә алачакларын әйтә. Ә бу бик кирәк! Тарихи романнар язу остасы В.Имамов кебек әдипләребезгә әкренләп алмаш әзерли башларга тиешбез. Татар телендә фантастика жанрын да үстерү сорала.

Сөембикә КАШАПОВА.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Россиякүләм Casta Diva һөнәри премиясе 2022 ел лауреатларын игълан итте. Премия ел саен опера сәнгате өлкәсендәге күренекле казанышлар өчен бирелә.

Россиянең атказанган, Башкортстанның һәм Татарстанның халык артисты Илдар Абдразаков «Европа вакыйгасы» номинациясендә билгеләп үтелде. Бу номинациядә чит илләрдә куелган берничә рус операсы бар.

«Күтәрелеш» номинациясендә премияне Башкортстаннан меццо-сопрано Айгөл Әхмәтшина алды, ул «Ковент-Гарден» Яшьләр программасын тәмамлаган. Айгөл Әхмәтшина Полина (Пиковая дама, Фестшпильхаус, Баден-Баден), Розина (Севильский цирюльник Россини, опера де Пари), Ольга (Евгений Онегин, Чайковский, Сан-Франциско), Маддалена (Риголетто Верди, Метрополитен-Опера) партияләрендә чыгыш ясады.

Яңа ысуллар табар өчен

Казанда «Үз телем» дип аталган проектлар конкурсы башланып китте. Ул балалар һәм яшьләргә татар телен өйрәтү һәм милли мәдәниятебезне үстерү максатын куя. Бәйгенең бүләкләү фонды – 2 миллион сум. Конкурсны оештыручы Казан Башкарма комитеты катнашучыларны гадәти күнегелгән формалардан читкәрәк китеп, тел өйрәнүнең үтемлерәк, кабатланмаган юнәлешләрен табып, яңа проектлар эшләргә чакыра. Катнашучылардан татар телен өйрәнү юлында нәтиҗәле, стандарт булмаган, яшьләрне җәлеп итәрдәй тәкъдимнәр көтелә.

Бәйгедә 35 яшькәчә егет-кызлар, мәктәп укучылары, студентлар катнаша ала. Теләүчеләр yztelem.ru сайтында 9 июльгә кадәр гариза калдырырга тиеш. Җюри эшләр арасыннан финалистларны сайлап алачак, анныры аларга үз проектларын яклап, конкурсның икенче турында чыгыш ясарга кирәк булачак. Иң яхшы идея авторларына 2 млн сумлык бүләк фондын үзара бүлешәчәк.

«Үз телем» конкурсы беренче тапкыр 2021 елда оештырылган иде. Ул чакта 5 проект грантка ия булды: сүзләр тәрҗемә итүче IT-проект, яшь натуралистның өстәл китабы – «Яшел китап», нәниләр өчен «Бөҗәкләр алдаша беләме?» энциклопедиясе, татарча комикслар һәм «SkyTat» онлайн татар теле клубы. Әлеге проектларның барысы да уңышлы тормышка ашырылды.

Эльмира СИРАҖИ.

Чигүле сурәтләр күргәзмәсе

Санкт-Петербургның Татар мәдәни үзәгендә София Теляшованың «Гаилә җылысы» дип аталган шәхси күргәзмәсе узды.

София ханымның декоратив-гамәли сәнгатьнең бер төре – чигүгә салынган күренешләрдән тупланган күргәзмәсе беренче тапкыр гына үтми. Берничә ел элек Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсендәге Даими вәкиллегендә аның «Сагыну» исемле чигүле күренешләр күргәзмәсе үткән иде.

Картиналар чигү рәсем сәнгатенә якын булган сәнгатьнең аерым төре.

Күргәзмәгә куелган чигелгән картиналарда аның иң камил иҗатын чагылдырган табигатьнең төрле төсләре, урман-яланнар һәм андагы җәнлек-кошларны күрергә мөмкин. Күңел җылысы салып чигелгән бу эшләр берәүне дә битараф калдырмый. Чигү аша чагылган тормыш ниндидер сихри көчләр аша үзенә тарта.

Ансамбльдән цирклы тамаша

ТР Җыр һәм бию дәүләт ансамбле Казан дәүләт циркы белән берлектә «Җиде энҗе» этно-цирк спектакле әзерли.

«Без быел уникаль проект әзерли башладык. 2007 елда без республикада беренче мюзиклны куйган идек. Ул «Җиде энҗе» дип атала иде. Без бу проектны яңартырга булдык. Әмма үзебез генә түгел, Казан циркы белән», – диде матбугат конференциясендә ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Айрат Хәмитов.

«Тамашада безнең артистлар белән цирк труппасы да, цирк мәктәбе укучылары да катнашачак», – диде ул.

Әлеге программа Казан циркының репертуар планына кертелеп, аның мәйданчыгында күрсәтелер дип уйланыла. «Бу программада традицияләребез дә, патриотизм да булачак. Тамашаның вокаль өлеше, әлбәттә, татарча була, геройлар ике телдә аралашачак. Чөнки без тамашабызны рус телле тамашачыга да, туристларга да күрсәтергә җыенабыз», – диде Айрат Хәмитов.

● Бөтен кешелек тарихында Җирдә барлыгы 108 миллиардтан артыграк халык яшәгән. Хәзер 8 миллиардтан артык кеше яши, бу планетабызда яшәп киткән бөтен халыкның якынча 7 процентын тәшкил итә. Бүген Җир халкының 25 проценты Кытайда гомер кичерә.

● Тарихта иң кыска сугыш нибары 38 минут дәвам иткән: Англия һәм Занзибар солтанаты арасында 1896 елның 27 августында булган әлеге яуда инглизләр җиңгән.

Мәдәнәдә туган якны өйрәнүчеләр киңәште

Түбән Новгород өлкәсенең татар автономиясе каршында туган як тарихын өйрәнүчеләр клубы уңышлы эшләп килә. Аны 2022 елның декабреннән башлап Зур Рбишча мәктәбенең югары категорияле тарих укытучысы Әлфия Мөхәммәтҗанова җитәкли.

Күптән түгел Мәдәнәнең «Рәшидә» мәчете бинасында урнашкан крайны өйрәнү музее базасында төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең I конференциясе узды.

Өлкә татар автономиясе белән берлектә уздырган конференциядә музей хезмәткәрләре, тарих укытучылары, һ.б. катнашты.

Әлфия Хәйдәр кызы, конференцияне ачып, шушы Мәдәнәдәге искиткеч бай музейны булдырган, экспонатларны берәмтекләп бөтен өлкә татар авылларына буенча җыеп йөргән сафаҗайлы мәрхүм Фәрит ага Беляевны җылы искә алды. Өлкә татарларының милли– мәдәни автономия җитәкчесе Мирзәхләм Абдулганиев үз чыгышында 8 июльдә өлкә үзәгендә узачак I Идел буе сабан туен югары дәрәҗәдә уздырыга басым ясады. Шулай ук ул крайны өйрәнүчеләр клубында һәр татар авылыннан бер генә булса да вәкил булырга тиеш дигән тәкъдим белән чыкты.

Конференциянең төп программасы алдыннан Сәрия ханым Аймалетдинованың күптән түгел басылып чыккан «Тормышка ашкан хыял» китабы тәкъдим ителде.

Пленар утырышта чыгышларны Сергач округы Грибан авылы имамы Ринат хәзрәт Хамзин башлап җибәрде. Конференциянең төп темасы авылларның топонимикасына багышланган иде.

Сергачтагы «Татар радиосы-91,4» студиясе директоры Фәрит Аймалетдинов үзенең чыгышында хезмәттәшлеккә чакырды, радиода туган як тарихына багышланган аерым блок булдырылуы турында белдерде һәм анда чыгыш ясауны системалы рәвештә эшләргә тәкъдим итте.

Туган як тарихын өйрәнүчеләр конференцияне елга бер тапкыр Мәдәнә музее базасында уздырырга, ә ел әйләнәсендә бүтән җирлекләрдә төрле темаларга багышланган сессияләрдә очрашырга дип килеште. Шулай ук барлык татар авылларының топонимикасын туплаган китап чыгарырга, «Беляев укулары» оештырырга кирәк дигән тәкъдимнәр дә хуплау тапты.

Наилә ҖИҺАНШИНА.

«Туган як».

Әстерхан татарларын да аералар

Россия Фәннәр академиясе Тел белеме институтының интернетка урнаштырылган «Список языков России и статусы их витальности» хезмәтендә моңа кадәр Әстерхан татарлары диалекты дип саналган карагаш һәм йорт сөйләшләре ногай теленә кертеп каралган.

Россия Фәннәр академиясенең 2022 елның декабрендә чыккан «Список языков России и статусы их витальности» дигән монография-препринтында (ачык чыганакта дөнья күргән тикшерү эше версиясе) әстерхан татарлары һәм себер татарлары сөйләшләре аерым тел итеп карала. Анда «Без мишәр һәм Казан (урта) диалектларын татар (Идел буе татарлары) теле дип таныйбыз, ә көнчыгыш сөйләшен аерым, себер татар теле, ә әстерхан сөйләшләрен – ногай теле составында карала», – дип язылган. Фәнни хезмәтнең авторлары – Ю.Б.Коряков, Т. И.Давидюк, В.С.Харитонов, А.П.Евстигнеева, А.А.Сюрюн.

«Бу проблема буш урында үзеннән-үзе барлыкка килмәде. Диалектларны татар теленә түгел, ә ногай теленә кертеп карау мәсьәләсен татар галимнәре күтәргән. Россия Фәннәр академиясе, чыганакларга нигезләнеп, шул фикергә килә. Бу очракта, мәсәлән, чыганак булып Татарстаннан тел галиме, профессор Леонид Арслановның

«Языки мира» энциклопедиясендәге хезмәте тора», – диде Әстерхан өлкәсе Татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Динара Мәҗитова.

«Идел буе төбәкләреннән күченгән татарларны икенче төрле «нугайлар» дип атаганнар. Алар шул ук Әстерхан татарлары. Тормыш-көнкүреше, гореф-гадәтләре, мәдәнияте буенча нугай белән ногайлар бер-берсеннән аерыла. Энциклопедия, фәнни әдәбиятта нугай (ягъни Әстерхан татары) сүзен ногайлар дип тәрҗемә итәләр», – диде ул.

Д.Мәҗитова фикеренчә, Татарстан галимнәре Әстерхан татарларын нугайлар дип атаганга күрә, ногай мәдәнияте белән кушылу барлыкка килгән.

«Икенчедән, татар галимнәренең хезмәтендә «бу – ногай мәдәнияте», – диелгән. Шуңа күрә ногай җәмгать эшлеклеләренә фәнни яктан дәлил булсын өчен, җәмгатьчелекнең фикерен сорап тору да кирәкми, чөнки бу дәлилне инде татар галимнәре формалаштырган», – дип аңлатты ул.

Әстерхан өлкәсе Татар милли-мәдәни автономия рәисе бу мәсьәләне хәл итәргә тырышуларын әйтте. «Җыеннарда сүз гореф-гадәт, мәдәният турында гына чикләнеп кала. Тарихи белешмәләр белән фәнни документ тотып: «Менә монда шулай язылган. Моны Татарстан Фәннәр академиясе чыгарган», – дип төртеп күрсәткәч, безгә нәрсәгә нигезләнәсе кала? – диде ул. – Бу сорау, беренче чиратта, галимнәргә бирелергә тиешле. Әгәр әлеге галимнәрнең фәнни хезмәте тикшерелеп, анализланып,



РОССИЙСКАЯ АКАДЕМИЯ НАУК
ИНСТИТУТ ЯЗЫКОЗНАНИЯ

Ю. Б. Коряков, Т. И. Давидюк, В. С. Харитонов,
А. П. Евстигнеева, А. А. Сюрюн

Список языков России
и статусы их витальности

Монография-препринт

Москва
Институт языкознания РАН
2022

аңа бастырылуга рөхсәт бирелгән икән, безгә сорау бүлырга тиеш түгел. Татарстан галимнәре үзләре үк шундый фәнни хезмәтләр язган вакытта, тел мәдәниятен саклау, үстерү турында сөйли алабызмы?»

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

ПАТРИОТЛЫК...

Тагын бер В.Мединский җитәкчелегендә эшләнеп Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган, татарлар тарихына чиләкләп шакшы һәм ялган атылган китаптан өзек китерик: «Казан ханлыгын яулап алу халык хәтерендә бөек милли-дини вакыйга булып саклана. Менә бу тарихи дөреслекне рус-татар мөгамәләсендәге ниндидер тыныч, гаугасыз чор итеп күрсәтергә телиләр!... Әйтелгәнгә тагын бер нәрсә өстәргә мөмкин: халык хәтерендә татардан да куркыныч һәм начар беркем дә сакланмаган».

Китап җитлегеп өлгермәгән төрле милләт балаларына юлланган. Шундый «кот чыгарлык» хәбәрләрне укыганнан соң алар ничек бер-берсенең күзенә карый ала соң? Шуннан нигә безнең яшьләрдә ватанпәрвәрлек һәм толерантлык юклыгына шикләнергә мөмкин?

Бу китапны шәрехләүне рус милләтеннән булган блогерга юллыйбыз: «Мәдәният министрының «татарлар Россия өчен фашистлардан да начаррак» – дип санавы акылга сыймаслык хәл. Мин, гомумән, мондый кешенең министр, бигрәк тә мәдәниятнеке булуына исем китә. Миллионлаган россиялеләрнең бабаларын нацистлардан да куркынычрак дип санау, шул ук вакытта шәһәрләрне талау, яндыру, ә соңыннан көчләп чукындыруны, кяферләр өстеннән җиңү, яхшылыкның усаллык белән көрәше дип күрсәтергә тырышу, кешелексезлекенә түгел, башка сыймаслык күренеш». Дөрес, китапка үзгәрешләр кертелгән, диләр. Тик рустагы: «Каләм белән язганны балта белән дә юынып булмый!»– дигән мәкаль барлыгын онытмаска кирәк.

Республика турында күп яздылар, күрсәттеләр. Казанга «Хезмәт батырлыгы каласы» дигән мактаулы исем дә бирелде. Чөнки Бөек Ватан сугышы елларында республика армияне кирәк-ярак белән тәэмин итү үзгәгенә әйләнде. Фронт өчен барлыгы 600 ләп төр продукт җитештерелде. Кызыл Армия сафларына 700 меңнән артык якташыбыз чакырылды, шулардан 350 меңе сугыш кырында мәңгелеккә ятып калды. Болар турында укучыларга сөйләргә кирәктер бит! Ә нинди сәгатьләрдә?

Тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам, күп язучылар герой-якташларыбыз, хәтта иң каһарманнары турында да хәбәрдар түгел. Мәсәлән, үзенең илгә, кешеләргә карата булган мәхәббәте белән миллионнар йөрәгенә юл тапкан Муса Җәлил исемен хәтерләү дә кемнәр өчендер авырлык тудыра. Ә бит аның турында атаклы азәрбайҗан шагыйре Самед Вургун искиткеч сүзләр әйткән иде: «Дөнья һәм дөньяви әдәбият үзләренең исемнәрен бетмәс данга каплаган күп шагыйрьләрне белә, ләкин Муса Җәлил кебек үзенең исемен үлемсез шигырьләре һәм батыр үлеме белән мәңгеләштергәннәр күп түгел. Менә алар: бөек Байрон, Венгриянең данлыклы шагыйре Петефи, герой Юлиус Фучик һәм, ниһаять, Муса Җәлил». Ул – СССРда Советлар Союзы Герое дәрәҗәсенә һәм Ленин премиясе Лауреаты исеменә лаек бердәнбер кеше.

Кызганыч, безнең сөйләмнән бүгенге мәгънәсендә «милләт» дигән сүзнең дә юкка чыгу куркынычы бар. Бу турыда үзенең рус булмаган милләтләргә тискәре карашы белән билгеле В.Тишковның тәкъдиме буенча Россия Конституциясенә «күп милләтле Россия халкы» урынына «күп халыклы Россия милләте» атамасын кертергә теләве раслый. Дөрес, В.Путин үзенең соңгы юлламасында «күп милләтле Россия халкы» дип ассызыклап әйтте. Бер ил, бер дин, бер халык тарафдарлары «күпмилләтлелек Россиянең дә СССР кебек таркалуына китерәчәк», дип расларга тырыша. Бу чын ялган.

Илне таркатырга тырышучылар арасында үзләрен ватанпәрвәргә санаучы «бер халык» тәгълиматын күтәреп чыгучылар да аз түгел. Әлеге «ватанпәрвәр»ләр берсен-берсе уздырып гади халык алдында Кызыл Армиянең югалтулары күп булды дип расларга тырыша. Бу очракта алар А.Солженицын, В.Астафьевка сылтыйлар (имеш, алар икесе дә сугышта катнашкан, димәк, алар ялгышмый. Искәртик, Астафьев гади элемтәче булып хезмәт иткән, окоптан ярты чакрым җирне генә күргән булуга карамастан, бөек стратег кебек фикер йөртә!). Аларның беренчесе 1939-1953 елларда СССР да 110 млн кеше һәлак булды дип ышандырырга, ә икенчесе бер немецны үтерү өчен, Кызыл Армиянең 7-10 кешесен югалтуын расларга тырышты. Димәк, бу саннар укучыларда безнең әти-бабаларыбыз сан белән җиңгән икән, ә батырлык белән түгел, дигән шикләнү тудыра. Ни өчен болай эшләнә? Димәк, үзләрен шулкадәр кырдыргач, руслар (совет кешеләре дип укырга кирәк) бик начар сугышчы, алардан куркырга кирәкми. Бу махсус, совет кешеләрен кимсетү өчен эшләнә. Хәлбуки, Ватан сугышы алдыннан көчләр ике якта да тигез диярлек була. Шуның өстәвенә «ватанпәрвәрләр» Германиянең аркадашларын һәм бөтен Аурупа илләренең немецларга эшләвен исәпкә алмый.

Соңгы тапкыр махсус дәүләт тикшерү комиссиясе раславынча, сугыш елларында барлыгы 28 млн кеше һәлак булган, аларның 8 млн чамасы – хәрбиләр. Шуны да искәртик: югалтулар исәбенә соңыннан тиешле җәзаларын алган власовчылар, бандеровчылар, полицайлар, җәзачылар, сатлыкҗаннар, хыянәтчеләрдән төзелгән бүтән төркемнәр, алар тарафыннан юк ителгән совет кешеләре, үз теләкләре яки мәҗбүри рәвештә басып алучылар ягында булучылар һ.б. кертелгән. Моңардан башка бу санга социалистик милекне урлаган, талауларда катнашкан, дезертирлык, үзүзләренә кул салган өчен атып үтерелгәннәр, авырудан, ачлыктан үлүчеләр һ.б. кертелүен онытмаска кирәк.

Ватанпәрвәрләр илнең кануннарын белергә һәм аны төгәл үтәргә тиеш. Ә «өстәге» абзыйлар үзләре үк канунны бозгач, балаларга моны ничек аңлатып була? Мәсәлән, Республика канунында акка кызыл белән гает көннәре «ял көннәре» дип язылган. Берничә ел элек 1 сентябрь әлеге көнгә туры килде. Шуңа да карамастан укучылар да, укытучылар да мәктәпкә барырга мәҗбүр ителде. Ярар, барсыннар ди. Шунда бит балаларга ислам дине турында бер күпме мәгълүмат бирергә, аның Россия җирлегендә рәсми рәвештә кабул ителгән беренче дәүләтчел дин икәнен, берничә елдан аның 1100 еллык юбилее булачагы турында сөйләргә була иде. Шулай ук әле монгол баскынчыларының бәреп керүенә кадәр өч йөз ел бар бит әле. Димәк, безнең ерак бабаларыбызның алар белән бернинди бәйләнеше юк. Бу мәгълүматлар бүтән милләт балаларында да кызыксыну тудырган булыр иде.

Бу хәтта гади кануннарга гына түгел, Конституциягә дә кагыла. Аның 43 маддәсенең икенче өлешендә: «Граждане России имеют право на получение основного общего образования на родном языке, а также на выбор языка обучения в рамках возможностей, предоставляемых системой образования в соответствии со ст. 6 Закона «Об образовании», – дип язылган.

Шулай икән, мәгариф түрәләре өчен законны үтәү мәҗбүри түгел булып чыга. Ләкин алар бит «Зәңгәл шәл» пьесасындагы: «Чум, чум, чум – закон безгә ни пачум!» – дип җырлаучы «качкыннар» түгел!

Россия тарихы әледән-әле чит ил тикшеренүчеләрен дә җәлеп итә. Шулардан берсе – Япониянең Киото университеты галиме Мами Хамамото рус булмаган феодалларның Россия дворянлыгының йомышлылар катламына керү тарихын өйрәнә. Ул «йомышлы татарлар» терминына этник түгел, бәлки социаль-юридик мәгънә бирә. Авторның бу мәкаләсендә әлеге төшенчә бөтен мөселман халыкларының (ягъни, «татарлар»ның) феодаль катламын үз эченә ала.

Йомышлы татарларны чукындыру

(XVII гасырның беренче яртысы)

1552 елда Казан ханлыгын яулап Россиягә кушкач, патша хөкүмәте православие диненә булмаган бар халыкны – мөселманнарны һәм мәҗүсиләрне буйсындыра һәм аларны көчләп христианлаштыру эшенә керешә. Башка диндәгеләрне чукындыру курсы баштан ук сәяси максатларны күздә тота. Христианлаштыру процессы бер көчәеп, бер көчсезләнеп торса да, әлеге курс Екатерина II хакимлеге чорына кадәр рәхимсезләнә генә бара. Чукынганнар арасында бигрәк тә югары катлау вәкилләре күп була. Мәсәлән, XVII гасыр башында Кама буенда йомышлы татарларның 40 проценты, ясаклы татарларның исә 5 процентка якыны гына православие диненә күчкән. Бу турыда документларны Мәскәүдәге Россия борынгы актлар дәүләт архивының 131 нче «Татар эшләре» фондында табып була.

Чукындыру процессы

Әлеге фондта яңа чукындырылганнарга яки «чит диндәгеләр»не чукындыруга кагылышлы 150 ләп акт саклана. Бу документлардан күренгәнчә, 1615 елдан 1702 елга кадәр 600 гә якын кеше чукындырылган. Аларның күбесе – Мәскәү тирәсендә яшәгән йомышлы татарлар. Араларында хәтта Төркия, Иран һәм Нугай Урдасыннан да иммигрантлар очраштыра, ә менә Урта Идел буе халкы хакында мәгълүмат бик аз.

Йомышлы татарларны чукындыру процессы йә Мәскәүдә, йә аларның яшәгән җирләрендә уздырылган. Мәскәүдән еракта яшәүчеләр үзләренә православие диненә күчүне рөхсәт сорап воеводаларга үтенеч юллаган, алар исә патшага хәбәр иткән. Мәскәүдә яшәүчеләр дә патшага үтенеч юллаган. Әлеге гаризаларны махсус оешма – Илчелек приказы тикшереп, чукынырга теләүченең җире һәм байлыгы исәпләнгән. «Морза» титулына ия булучылар һәм үзләренең Чыңгыз нәселеннән булуын дәлилләүчеләргә чукындырылганнан соң мактаулы «кенәз» титулы бирелгән. Әсирлеккә төшкәннән соң православие диненә күчүчеләр дә, үзләренең морза булуын дәлилли алса, кенәз титулына ия булган. Мәсәлән, Нугай Урдасыннан морза улы Солтанбәк Мамаев әсирлеккә төшкән һәм Әстерханда рус сәүдәгәренә сатылган, ул аны көчләп чукындырган һәм Иван исеме кушкан. Мамаев аннан качкан һәм Вологдада укчы булып хәрби хезмәткә урнашкан. 1633 елда ул патшага үтенечен юллаган, Илчелек приказы аның чыннан да морза икәнен ачыклагач, кенәз титулы, җир биләмәсе һәм акча бирелгән.

Илчелек приказында сорау алынганнан соң, чукынырга теләүчеләр монастырьга җибәрелгән. Анда кимендә 40 көн дин нигезләрен өйрәнгәннәр, бу вакытта алар киендерелгән һәм казнадан акча алган (мәсәлән, 1650 елда көненә 4-6 тәңкә бирелгән). Тиешле белемне үзләштергәч, чукындыру йоласы үткәрелгән. Аны үткәрү алдыннан һәр чукынучыга «кабул итүче» билгеләнгән. Йоладан соң яңа чукындырылучылар бүләкләнгән. Әгәр православие диненә югары катлау кешесе күчсә, аңа патша белән очрашу оештырылган. Патша сараенда үткәрелгән шундый аудиенцияләрнең биш беркетмәсе сакланган. Әлеге очрашуда түрәләр яңа чукынучыга нинди бүләкләр бирелүе белән таныштырган.

Чукынган өчен бүләкләү

Башта шәрык чыгышлы 16 яңа керәшенгә бирелгән бүләкләрне карап үтик. Алар иң югары ранг – «стольник» (патша сараенда хезмәт итүче) чиннындагылар. Чукыныр алдыннан аларга алтын йөгертелгән көмеш тәре, күлмәк, билбау, сафьян читек, кафтан, чикмән, башлык, аеруча аксөяк чыгышлыларына исә бик кыйммәтле әйберләр, мәсәлән, 30 сумнан 210 сумга кадәрле энҗе муенсалар бүләк ителгән. Һәркайсына уртача 79,29 сум акча сарыф ителгән (иң зур сумма – 540,56 сум, иң азы – 15 сум).

Христианлыкка күчкәч патша биргән бүләкләр арасында көмеш тустаган, ат (актларда бәясе бик сирәк күрсәтелә), бәрхет, атлас, камка, кырык кеш тиресе (20 сумнан 40 сумга кадәр) бар. Атаклы нәселдән булганнарга туннар, башка кыйммәтле киемнәр дә бирелгән.

Чукыныр алдыннан йомышлы кешегә аңа биреләсе җир мәйданы һәм акча билгеләнгән. Ярославль татары Көрел морза Исупов җир һәм акча сорап үтенечен җиткергәч, Мәскәү хөкүмәте аңа православиегә күчкән очракта 1000 чирек җир һәм 100 сум акча, мөселман булып калса, 500 чирек җир һәм 40 сум акча вәгъдә иткән. Әмма Көрел морза барыбер чукынмаган. Суздальдә йомышлы татар Сарый морза Исмәгыйлевка 600 чирек җир һәм 40 сум акча билгеләнгән, чукынгач, җире 1000 чиреккә, акчасы 100 сумга җиткерелгән. Ярославльдә татар Василий Маметевка христиан диненә күчкәнче 350 чирек җир һәм 25 сум акча билгеләнсә, аннары җире 600 чиреккә, акчасы 50 сумга җиткерелгән. 1605 елдан 1678 елга кадәр йомышлы морзаларның уртача хезмәт хакы 40 сумга, ә яңа чукындырылган 37 кенәзнеке 86 сумга тәңгәл булган.

Алдарак әйтеп үтелгән 16 стольникка бирелгән бүләкләрне карап китик. Бирелгән җир күләме уртача 1016,92 чиреккә тәңгәл булып, иң зур мәйданлысы 1500 чирек, иң кечкенәсе 600 чирек тәшкил иткән. Уртача хезмәт хакы 116,15 сумга (иң күбе – 200, иң азы – 40 сум) тәңгәл булган. Чагыштыру өчен: 1608-1690 елларда 326 стольникның уртача хезмәт хакы 55 сум (иң күбе – 680, иң азы – 7 сум) тәшкил иткән. Саннарны чагыштырудан хөкүмәтнең яңа чукынган стольникларга бик югары хезмәт хакы түләве күренә. Шул 16 керәшен арасыннан иң кыйммәтле бүләкләр 1623/24 елларда чукынган һәм боярга әйләнгән Яков Черкасскийга (Үрүскән морза) бирелгән. Аның кабул итүчесе бояр Иван Никитич Романов булган. Чукыныр алдыннан Үрүскән морзага алтын тәре (5,9 сум), тафта күлмәк-ыштан (15 сум), асылташлы муенса (50 сум), ефәк билбау (1,86 сум), озын күн кафтан (20,7 сум), бәрхет башлык (5,9 сум), камкага охшаш бизәкле җитен тукымадан ыштан (2,21 сум), сафьян читек һәм башмак (0,8 сум), энҗе муенса һәм энҗеле башлык (210 сум), кисея күлмәк-ыштан (10 сум), билбау (1,45 сум), атлас чикмән (4,01 сум), ефәк тасма (4,8 сум), көмеш төймәле тун (107,73 сум), мех башлык (20 сум), кыска киң җиңле, челтәрле озын кафтан (12,9 сум), көмеш төймәле, озын җиңле кафтан (6,32 сум), энҗеле муенса (20 сум), постау кафтан (8,97 сум) бүләк иткәннәр. Христиан диненә күчкәч, ул патшадан көмеш кубок һәм аргамак алган. Бүләкләрнең тулаем суммасы 954,24 сум тәшкил иткән.

Стольник чины бирелмәгән керәшен кенәзләренең бүләкләре азрак булган. Мәсәлән, 15 кенәзнең һәркайсына уртача 72,45 сумлык (иң күбе – 349, иң азы – 3 сум) бүләк бирелгән. Тагын бер документтан күренгәнчә, яңа чукындырылган 25 кешенең һәркайсына бирелгән җир мәйданы уртача 730 чиреккә тәңгәл булган (иң күбе – 1200, иң азы – 400 чирек), аларның уртача хезмәт хакы 70,21 сум тәшкил иткән (иң күбе – 150, иң азы – 25 сум).

Моннан тыш, мактаулы титулга ия булучыларга йорт салу өчен дә акча бирелгән. Мәсәлән, 1619/20 елда кенәзләр Борис (Әбләй) Куликов һәм Левонтий (Бәк) Шейдяков 65 әр сум, 1632/33 елларда Федор Бәрәнгәзиев – 200 сум, Иван Игәнәев – 70, Григорий Бәрәнгәзиев 80 сум акча алган.

Гади татарларга чукынган очракта кием-салым, 5-10 сум акча һәм сыйфатлы постау бирелгән. Мәсәлән, титулсыз 27 йомышлы татар һәркайсы уртача 269,6 чирек җир биләмәсенә ия булган (иң күбе – 470, иң азы – 10 чирек), уртача хезмәт хакы 10,4 сум тәшкил иткән (иң күбе – 20, иң азы – 7 сум).

Күп кенә йомышлы татарлар христианлыкка гаиләләре белән күчкән, шунлыктан документларда телгә алынган яңа керәшеннәрнең яртысы – аларның гаилә әгъзалары. Аларга да бүләк тиеш булган. Кенәз хатыннарына казнадан кием-салым һәм 5-10 сум акча, балаларына 14-20 сум акча, хезмәтчеләренә 2 сум акча; титулсыз йомышлыларның хатыннарына исә постау һәм 4-8 сум акча, балаларына 1-5 сум акча бирелгән.

Күргәнегезчә, православие диненә күчү икътисади яктан бик файдалы булган. Шулай да халык диненнән ваз кичәргә бер дә ашкынып тормаган, күчкәннәрне исә бер дә өнәмәгән. Мәсәлән, 1619 елда Ярославльдә чукынырга ниятләгән йомышлы татар Зурабәк Шейдяковны абыйлары 3 атна буе богаулап тоткан. 1625 елда Сарый һәм Бари Исмәгыйлевлар үзләренә чукынырга рөхсәт итмәгән этиләре өстеннән шикаять язган һәм Мәскәүдән берәр кеше җибәреп, үзләрен алып китүләрен үтенгән, ахыр чиктә алар икесе дә гаиләләре белән православие диненә күчкән. 1627 елда яңа керәшен Фома Кулушев һәм аның дусларын Бәрәй морза Күтүмев үз диннәреннән күчкән өчен җәзалаган, әмма тегеләр барыбер исламга кире кайтмаган. 1647 елда йомышлы татар Кылчаков Канай морза Шейдяков өстеннән шикаять язган, янәсе, чукынырга ниятләвен ишеткәч, ул аларның гаиләсен бер ел буе утарында бикләп тоткан.

Шул рәвешле, йомышлы татарларның христианлыкка күчү очраклары һәм аларга бирелгән бүләкләр белән танышып үткәч, XVII гасырда чит диндәге халыкларның элитасын чукындыру процессына рус хөкүмәтенең үзе тыкшынуы турында нәтиҗә ясарга була: чиркәү исә моңа әллә ни игътибар бирми, ул чукындыру йоласында гына катнаша. Хөкүмәт шул рәвешчә милләтнең иң бай, иң дәрәҗәле затларын үз диненнән яздырырга тырыша.

Мами ХАМАМОТО, Япония.
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА тәрҗемәсе.
(«Гасырлар авазы» журналыннан)

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА

АРЧА ДАСТАНЫ

I

АРЧА ГИМНЫ

Флёра Гыйззәтуллина шигыре
Риф Гатауллин көе

Илһам нуры җанны чорнап ала,
Ак каеннар шаулап яфрак яра.
Изге манаралар күккә ашып,
Азан әйтеп таңны каршы ала.

Кушымта:
Ак каеннар Ватаны син, Арча!
Илһамият Ватаны син, Арча!
Изге моңнар Ватаны син, Арча!
Ватанымның ал таңы син, Арча!

Һәр юлчыга яшел яфрак изәп,
Арча җырын җырлый аккаен –
Мөхәммәттәй затлы туган телем,
Халкым кебек тугры Тукаем!

Кушымта:
Бөек Тукай Ватаны син, Арча!
Мөхәммәтләр Ватаны син, Арча!
Ай-йолдызлар Ватаны син, Арча!
Ватанымның ал таңы син, Арча!

Җидегән чишмәләрдән ургылган моң
Яшьлегеңә, Арча, кыйбла ача!
Мәрҗаниләр, Курсавилар рухы
Гыйлем тавы булып алга баса.

Кушымта:
Рухи таулар Ватаны син, Арча!
Сулмас яшьлек Ватаны син, Арча!
Дан-шөһрәтләр Ватаны син, Арча!
Ватанымның ал таңы син, Арча!

II

КАЙТУ

...Пар атлымы, рухи канатлымы –
Юлдашларым нинди булмасын,
Гел Арчага тоташтыра мине
Азнакайдан сузган юл башым.

Изге азан моңын хуш күрепме,
Мин гел куш офыкка табынам.
– Азнакаем!!! – дисәм, кайтавазым
Ишетелә Арча ягыннан.

Әйе... Әйе, Арча минем өчен
Аклык хаклыгына әйләнде.
Адым саен тоям иҗат нуры
Йөрәгемә тамыр җәйгәнне!

Әйе, тоям: йөрәк тибешемдәй
Якын миңа монда барча моң...
...Моң таҗында – Арча!..
Бөек Тукай!!!... –
Ай-йолдызлы күге Арчаның.

Юл өстендә җидегән чишмәләре:
Ургыла су җиде улактан.
Чишмә фалын җирле халык һәрчак
Сафлык-инсафлыкка юраткан.

Халык, әйе:
– Иминлеккә! – дигән
Чишмә буен күлләр биләсә...
Һәркем монда ил язмышы белән,
Тукай тавышы белән сөйләшә.

Пар аккошлар шигъри наз сугара
Төнбоеклы күлләр читендә –
Бу тылсымлы милли гүзәллекне
Әйләндереп булмый чит телгә.

Яла ягып булмый туган якның
Ак кошына, кара кошына...
Сагыш тулы үксез күкрәктә
Күкрәп тора корыч тояклар.

Шул тояклар корта тамырдан
Халыкларның гомер гөлләрен...
Мин гел сыкрау-сыктау ишетәм
Үрләгәндә иҗат үрләрем.

Адым саен читкә сөреләм:
Әйтерсең мин илсез каторҗан!
Йөрәкләргә мәкер тырнагын
«Иванчы»лар тирән батырган.

Шуңамы соң йөрәк җырымның
Һәр иҗеге сыкрап моңлана:
«Күкрәк көче – мин! – дип,
– Арчаның»,
Апуш бага ятим дөньяга.

Кайтам Арчага мин,
Җир шарыдай
Өмет элеп керфек очыма.

III

ЧАТЫРЛАРГА ТӨЯП ТАРТЫР МОҢ...

Арчалардан искән таң җиле
Кылганына кагылып алса да,
Чал гасырлар аша баш иеп,
Сәлам юллый Чатыр Арчага.

Арча көен җанда тибрәтеп,
Таулар гизәм туган ягымда.
Таң нурына терәп күкрәген,
Тора Арча хезмәт сагында.

Әйе, тора карап туп-туры
Кансыраулы тарих күзенә –
Ил өстенә килгән яуларның
Бар кайгысын каплап үзенә.

Канда йөзеп Казан... Уфасын
Өмет белән Арча сугарган.
Богаулардан арыну өмете
Ураллларга барып уралган.

...Бу халыкка туа-тумыштан
Көрәш дәрте дөртләп кабынган:
Маңгайларга... камыш билләргә
Балта, кылыч белән чабылган.

Бөек җиңүләргә ыргылган
Арча халкы шушы килеш тә...
Шушы хакта сөйли Чатырга
Себерләрдән алган «белешмә».

Сибләә башкаема моң салып
Кылганнары мәшһүр Чатырның.
Мәңге бетмәс... бетмәс татарда
Чатырларга төяп тартыр моң!

Азнакайдан Арча ягына
Мин дә шушы моңнан авыштым.
Ялкыннары дөрли җанымда
«Себер тракты»ндагы сагышның.

Сөрген моңын – богау чыңнарын
Аз ишеттемени бу яклар?
Ятименнән өркеп, чирканып
Әмма Арча читкә йөгерми –
Камыш билен бөгеп җиргәчә,
Гөлзадәләр анда җыр эрли.

Хезмәт аһәңнәрен Арчаның
Мин шул җырлар аша отамын –
Һәрбер нур бөртеген үз күреп,
Аттырганда чорның бу таңын.

Хәйран калып газиз милләтнең
Җырга ашкан һәрбер сүзенә,
Җиргә ямьле язлар кайтканда,
Җыя безне Арча үзенә.

Туфаннарның гомер юллары
Тукай моңнарына тиңләшә...
Шул моңнарның саклап кадерен,
Мең яшә син, Арча! Мең яшә!

Ерак киләчәге милләтнең
Бүген дә бит шомлы моңга бай!..
...Күзен алмый Урал, Чатырдан
Калымада үксеп тулган ай...

Тома ятимлегем ягыннан –
Мин дә тиңдәше бит бу айның.
Чорлар буе үксим кочаклап
«Апуш» кына чагын Тукайның.

IV

МИН – ТУКАЙНЫҢ СЕҢЕЛКӘШЕ

Бишек җыры көйлим,
шигырь көйлим,
Ятимлектән иңгән тәмугта...–
Гыйбрәт өчен
берсен-берсе тотып
Ашар чиккә җиткән халыкка.

Бай баласы балда-майда коенганда,
Ятим-җилпе борчак-борчак күз яшь түгә.
Күңелем тулды... Ике яшьлек Апуш миңа
Көтмәгәндә «сеңелкәш...» дип эндәште дә.
Аңа – ике!.. Миңа инде биш тулганда
Очраштык без шыр ятимлек кочагында,
Ул ашамый минем өчен саклап тоткан
Шешәдәге өч-дүрт бөртек борчагын да!
Безнең арадагы охшашлыкны тәкъдир
Ачлык, ялангачлык белән бәйләндергән.
Очрашканда зар елатмас өчен, ахры,
Сак-Сокларга соңра безне әйләндергән.
Тукай язын дүрт-биш гасыр алдан тоеп,
Шөкер кылып иманнары исән-саугa,
Арча халкы, Грозныйдан качып китеп,
Нәсел типкән безнең мәгърур Чатыр-тауга.

Әнкәм яклы әбкәм, ахры, Арчадандыр:
Шәмсекамәр – Ай-Кояш бит исем-аты!..
Исемнәре җисеменә туры килгән
Якташларның моңы тирән, йөзе якты.
Елдан-елга үрчи Сак-Сок күрәчәге,
Кол-качакның юл өстенә тау игә дә...
Мәмдүдәнең моңлы гаме, рифмалашып,
Дәвам иткән минем әнкәм Мәүгыйдәдә.

* * *

Ятимлеккә тарган сабый баланыңмы,
Ананыңмы бакыйлыкта җаны тына?!
Габдулланың күз яшьләре тама сыман
Борчак ашы бүлеп куйган савытыма.
...Яшь бөртеге исәбеннән саный китсәң,
Мин – Тукайның мең гасырлык сеңелкәше!
Әмма исрафлыкта узган ул вакытны
Нинди назлар түгеп кабат терелтәсең?!
Ни әйтәсең тук чырайлы әзмәвергә,
Үзен «Тукай токымы!» дип таныткaнда,
Борчак бөртегедәй ымсындыргыч
Өметеңә синең каныкканда?!
Ут казаларыннан аралаган булып,
Суд җәзаларына кабат тарттырганда?!
Бер гөнаһсыз Сак-Сок чагымнан ук
Мин адашып калдым мәллә ят урманда?
Уралдан да, Җаектан да ары китеп,
Шәфкатьсездән рәхим-шәфкать, ирек көтеп,
Көтекләндем, китекләндем, теткәләндем...
Белгән Тукай: көткән ирке буылмаса,
Тыны бетми үпкәләрнең.
Еламасаң, күрер күзләр сукырайммый!..
Ил авазын ишетмәсәң, тонмый колак.
Картаеп һәм кибеп-корып, сукыраеп
Хатирәләр гөрелтесен тыңлый Болак.
Кара-каршы ярларыннан Илне күзли
Гасырларның чарасызлык шәрәлеге...
Шыбырдашып төптән типкән
бу фонтаннар
Шагыйрьләргә тиеш шампан
шәрабеме?»
Әллә ауган дәверләрнең күз-яшеме
Хаклык даулап Ил иңенә күтәрелә?
Коточыргыч даулы-гаулы бу кыргый мәл
Үтә генә күрсен иде. Үтә генә!...

Насыйп булсын иде безгә чал тарихның
Фал китабы төсле ачык чынбарлыгы...–
Ил язмышын хәл итәргә кирәк чакта
Сөю океаннарын айкап чыгарлыгы.

АГАЧ УЮЧЫ

Татарстан һәм Россия Рәссамнар берлекләре әгъзасы, танылган рәссам, керамика һәм агач ую остасы Хәмит Латыйповның 2021 елда нәшер ителгән «Уелган бизәкләр» әдәби-нәфис басмасы һәвәскәр осталар, укытучылар һәм укучылар өчен тәкъдим ителгән. Бу сәнгать төре белән кызыксынучылар аны Татарстан китапханәләрендә таба ала.

Талант иясенең агачтан уеп ясалган сәнгать әсәрләре фотолары күпләп тупланган әлеге альбом бар сәнгать сөючеләрнең дә күңеленә хуш килерлек. Альбомда «Паннолар», «Уеп ясалган панноларның эскизлары», «Вазалар», «Декоратив тәлинкәләр», «Сувенир сыннар», «Сандыклар һәм ишекләр» бүлекләре белән таныша алабыз. Андагы язмалар да бик төгәл, һәркемгә аңлаешлы телдә. Ул рәссамның гаҗәеп матур график рәсемнәре белән дә бизәлгән. Сүз уңаеннан, Хәмит Нәҗип улы Чаллы каласында оештырылган «Ел рәссамы» бәйгесенең «Сынлы сәнгать» номинациясендә быел да беренчелекне яулады.

Останың фотосурәтләр аша барланган фактуралы хезмәтләре нибары ике гади эш коралы – пычак һәм өтерге белән генә башкарылган. «Әлеге альбомымда мин уеп эшләү сәнгатендәге иҗади мөмкинлекләрне киңәйтү алымнарын чагылдырдым. Озак еллар дәвам иткән иҗат юлымны янә бер кат барладым. Алар арасында авыл капкаларындагы, коймаларындагы, тәрәзә йөзлекләрендәге кош сурәтләренә таянып иҗат ителгәннәре дә шактый. Авыл осталарына хас гадилек, ихласлык кушып уелган сурәтләр мине һәрчак сокландыра килде. Алар мине һәрчак иҗатка рухландырды, җаныма ниндидер көч-куәт өстәде. Балачактан бирле күңелем түрендә саклаучы шушы бизәмнәр мине тагын да нәфисрәк сурәтләр иҗат итәргә этәрде. Әйтик, менә 2006 елда ясаган «Кош» панносы – шуңа бер ачык мисал. Бу әсәремдә мин башта фонны чокып, тигезләдем, шул фонга башка бер төр бизәкләр кертмәдем, бизәмнәрне бары тик кош сурәте эченә генә уйдым, – дип аңлата сәләтле остаз. – Гомумән, кош сурәтләрен еш уям. Чөнки ялан кошның авазы туган-үскән җирләремнән, әллә никадәр ерак аралардан да миңа кадәр әле дә ишелә төсле! Андый кошларны аерым-аерым итеп тә иҗат иттем һәм аларның һәр кайсының үз холкын да барладым, аларны «Уйланучан кош», «Гаҗәеп кош», «Сәер кошлар», «Ялан кошлары», «Сакчы кошлар», «Тырыш кошлар» һ.б. дигән исемнәр белән атадым. Мондый, төрле холыкка ия балык сыннарым да җитәрлек, алар да йә усал, йә шаян яки инде тыныч һәм яхшы кәефлеләр... Иҗатчыларның бик сирәге генә балык сурәтен ясамыйдыр. Минем агач ую сәнгатемә кагылышлы иҗаттымдагы һәрбер эшләнмәмдә дә диярлек балыклар да, җәнлекләр, кошлар да чагылыш таба.

Панноларымның күбесе борынгы дастаннарга, риваятьләргә таянып та иҗат ителде. Без бит ул дастаннарны бик еш искә дә алмыйбыз диярлек, безне тормышның башка мәшәкатьләре, хәсрәтләре басты. Милләтемнең әкиятләре, риваятьләре, бәетләре күңелемне һәрчак җәлеп итә, шәхсән үзем аларны кат-кат укыйм, чөнки алар буенча әллә никадәр иҗат эшләре ясарга мөмкин бит».

– Хәмит абый, сезнең иң беренче агач эшләнмәләрегез үк милли тематикада булгандыр дип күзаллана...

– Әйе. Иң яраткан иҗат эшләремнең берсен 1975 елда Уфа сәнгать училищесының II курсында укыганда ясаган идем. Ул елны Г.Тукай иҗатына таянып, «Шүрәле» панносын иҗат иттем. Иң ошаткан эшләрем рәтенә кергән әлеге хезмәтемдәге Шүрәлегә соңгы елларда башка караштан чыгып карыйм. Ул миңа киләчәккә юл таба алмаган кавемебезне хәтерләтә. Үз милләтенә, киләчәккә таба юл – минемчә, ана теленең бар уку йортларында, мәктәпләрдә күбрәк сәгатьләр укытылуы белән бәйле. Хәзерге көн татар балаларының рус телендә генә гәпләшүләре – никадәр дәрәҗәдә аяныч күренеш. Үз ана телендә югары белем ала алмаячакларын алар инде яхшы белә, шуңа күрә дә аларның аңын чит тел генә җәлеп итә башлый. Ни өчен зур милләтебезнең үз ана телендә укыта торган университеты, институты булмавы миңа аңлашылмый. Аларны ачарга ни комачау итә соң?!

Аннары 1977 елда, һаман да шул Уфа училищесында укыган чагымда камил перспектива кануннарына таянып ясаган «Суга бару» панносы фотосурәтен дә әлеге басмага керттем. Калган хезмәтләрем дә милләтем мәдәнияте белән генә бәйле. Олы тарихыбызны барлап, «Җиңүче», «Туган ил турында җыр» кебек панноларны, төрле сувенирларны да иҗат иттем, уен коралларыбызны искә алып, кубызда, курайда, гармунда уйнаучыларны да сурәтләдем. Әйе, аларның кайберләреннән моңсулык та бөркелә, чөнки кайдадыр бик еракта калган вакыт, гомернең иң асыл чагы сагышка төрелеп искә төшә. Гомумән, бар эшләремдә дә аерым бер моң булуын теләүче рәссам мин.

– Ә битлекләр?! Алар... безнең милләт сәнгатенә һич кенә дә якын түгел...

– Битлекләр темасы – яшүсмер, яшьлек елларым белән бәйле. Мине гомерем буе журналларда, китапларда басылган фотолардагы Африка битлекләре кызыксындырды. Бу да бит халык сәнгате. Әлбәттә, ул илләрдә алар дин белән дә бәйле. Битлекләрнең энергетик ауралары тоеп, аларда Галәмнең һәм кешелекнең яшәү серләре яшеренгән дип фаразлый идем. Шушы гаҗәеп мавыктыргыч темага алынып, 2004-2005 елларда агачтан битлекләр сериясен уйдым. Битлекләр күп рәссамнарның игътибарын җәлеп итә. Әйтик, кеше йөзе сурәтен геометризацияләп ясарга гына омтылган, кубизмга мөкиббән рәссамнар да битлек эшенә һәрчак тартылган.

– Сез иҗат иткән савыт-сабалар искиткеч матур...

– Вазаларны, кечкенә мичкәләрне, бал савытларын ясау – ул һәрчак күңелле иҗат! Туймазы фарфор заводында, Туймазы медицина пыяласы заводында күп еллар хезмәт куйдым һәм шунлыктан бихисап формадагы вазаларны, савыт-сабаларны үзле балчыктан ясау тәҗрибәм булганга күрә дә, аларны ясау бик зур авырлык тудырмады. Мондый эшләнмәләремне пычак белән генә уйдым, аларда өтерге бик аз кулланылды. Әмма шушы савыт-саба өчен уелачак сурәтнең әйләнгеч яссылыкка ятасын аңлап, кешеләргә рәсемнең бер фрагменты, бер өлеше генә күренеп торуын да истә тотарга кирәк булды, шуңа күрә әлеге төр эшләнмә рәсемнәрнең үз үзенчәлекләре бар, билгеле. Алардагы бизәмнәр бер-берсе белән үрелеп барырга, камил булырга тиеш. Үзенчәлекләр ваза формаларына да өстәлде. Әйтик, «Болгар вазалары» сериямдәге савытларның композицияләренә борынгы Болгар архитектурасы чалымнарын керттем, бу аларның капкачлары аша да барланды. Алар, әлбәттә, башта станокта чокып эшләнде, шуңа күрә капкачлы мичкәләр – иҗатымдагы тәҗрибәләр синтезы да.

Сувенир сыннарда исә мин шартлы чишелешләргә дә килдем, идея лаконизмын да үз иттем.

– Хәмит абый, иҗатыгызда терек

табигать, аеруча урман күренешләре бихисап...

– Чөнки балачагым елларындагы беренче хатирәләрем Башкортстанның матур табигате белән бәйле. Аның яме, андагы урманнар һәм чишмәләр җыры, кошлар сайравы – мине яшәргә өметләндергән рухи кыйммәтләр дияр идем. Мин ул авазларны гомерем буе сагынып яшим! Моны үз туган авылсыз калган кеше генә аңлый булыр. Мәгълүм ки, мин үскән Бүләр авылы җир йөзендә юк инде. 1970 еллар азагында аны гигантомания бетерде. Ул чор чиновниклары кечкенә авылларны таркатып, андагы халыкны башка, зуррак авылларга, үзәкләргә күчерергә кирәк дигән фәрман чыгарган булгандыр. Әмма мондый вакыйгалар күпләрне сантый итте, рухи фаҗигаләргә китерде. Чөнки кешеләрнең күбесе күченеп киткән җирләргә күнегә алмады. Безнең Бүләрдә кибет, ферма, дүрт сыйныфлык мәктәп тә бар иде. Зират та. Авылыбыз урман, басуларга бай җирдә урнашкан. Гаҗәеп чишмәсе дә бар иде аның. Мин шул 45 ләп йортлы авылыбызны бик тә сагынып, гел кайтып йөрдем. Аның һәр йорты, урамы хәзер дә төшләремә керә. Элекке авылдашлар белән арба юлы буйлап кайтып, һәр җәй саен Бүләр җирлегенә барыбер җыелабыз... Туган җир тарта.

Шушы, туган ягым хозурлыгын түгәрәк декоратив тәлинкәләр иҗат иткәндә дә гел күз уңында тоттым. Аларда татарлыгым тагын да алга чыкты, тәлинкә фоннарын милли чигүләребезне, каюлы читекләребезне хәтерләткән, үз милләтебезгә генә хас бизәкләр белән баеттым. Әмма шул ук вакытта агачтан уюның билгеле бер кагыйдәләре булуын да искә төшерер идем, чөнки агач уюу осталары бу хакта да онытмаска тиеш: төрле тәҗрибәләр ясыйм дип, агач эшләнмә композициясендә билгеләнгән чикләрне бозу уңышка китермәскә дә мөмкин. Чөнки агач – ул ялгыш яисә артык кисеп бозуларны бер дә яратмый.

Милләт уңышы төшенчәсенә әйләнеп кайтсак, татар үзен-үзе кайгыртырга тиеш дип саныйм. Балаларыбыз ике белемгә: үз тарихыбызга һәм ана телебезгә омтылса гына, без милли үзенчәлекләребезне саклап калачакбыз. Сынлы һәм гамәли сәнгатебезне ныклап пропагандалаганда гына, яшь буында аларга карата мәхәббәт уяначак. Узган ел көзендә «Хәзинә» милли сәнгать галереясында ачылган «Туган җирдә» шәхси күргәзмәмә ата-аналар үз балаларын, мәктәп укытучылары үз укучыларын ияртеп килде. Кечкенә балаларның, яшүсмерләрнең гамәли эшләнмәләрем, яңа картиналарым белән танышуларын, миңа да бихисап сораулар яудыруларын күрү күңелемә якты киләчәгебезгә карата бернигадәр өмет өстәде.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Тайсуганда тарихи вакыйга

Әлмәт районының Тайсуган авылында бу төбәк өчен генә түгел, милләтебез өчен тарихи вакыйга булды – биредә Коръәннең өр-яңа тәфсирен тәкъдим иттеләр. Бу Коръән тәфсирен узган гасырның илленче елларында Златоуст шәһәрендә Мөхәммәдтаһир Байтукалов язган, ул исә шушы Тайсуган авылы тумасы. Мөхәммәдтаһир хәзрәт 1897 елда Тайсуган мәчетенә имам итеп билгеләнә, шул ук вакытта данлыклы мәдрәсәнең мөдәррисе дә була. Коръән-Хафиз, гарәп, фарсы, төрек телләрен камил белгән яшь хәзрәт тиз арада халыкның мәхәббәтен яулый, мәдрәсәсендә йөзләгән шәкерт әзерли.



Әмма 1917 елда данлыклы мәдрәсә ябыла, хәзрәтнең йорт-җире, бар мал- мөлкәте тартып алына, үзен кулаклар исемлегенә кертәләр. М. Байтукалов килеп кулга алганнарын һәм сөргенгә сөргәннәрен көтеп утырмый, 1929 елны башта Уфага, аннан Урал тауларындагы Златоуст шәһәренә кача. Гаиләсе дә аның артыннан килә, эз яшерү өчен, балалары әниләре фамилиясендә Зәйнетдиновлар булып йөри башлый, Мөхәммәдтаһир хәзрәт соңыннан этисенең исемен фамилия итеп ала, Әхмәдзәкиев булып языла.

Зур дини гыйлеме һәм тәҗрибәсе булган Мөхәммәдтаһир хәзрәт Златоустта көндезләрен калайчы булып эшләп, гаиләсен туйдыра, төннәрен исә китап яза. 1945 елда ул «Мәсаил вәгаз» хезмәтен тәмамлый, аннан соң Коръән тәфсиренең 3 томлыгын әзерли. 1962 елда, 85 яшендә, бакыйлыкка күчә, кабере Златоуст шәһәрендә. Уллары Әхмәт 20 яшендә Бөек Ватан сугышында һәлак була, кызлары Зәйнәп һәм Зәкия 90 яшькә кадәр яшиләр. Әтиләре үлгәч, 1962 һәм 2013 елларда алар Тайсуганга кайтып, туган йортларының бүрәнәләрен кочаклап елый, бабалары Әхмәтзәки каберендә дога кылып, бәхилләшеп китә... Бәхрелхәят абыстай исә 1971 елда бакыйлыкка күчә, Златоуст шәһәрендәге татар зиратында ире Мөхәммәдтаһир хәзрәт белән бер чардуган эчендә ята...

Мөхәммәдтаһир хәзрәтнең Урал тауларын урап кайткан менә шул Коръән тәфсирен туган авылында тәкъдим итү чарасы булды. Бу кыйммәтле хезмәтнең Тайсуганга әйләнеп кайтуы үзе бер вакыйга. Хәзрәт үлгәч, аның хатыны һәм кызы, кульязмаларын күтәреп, Мәскәүгә дә, Казанга да килеп карый, әмма бастырып чыгара алмыйлар. Бары тик 2018 елда, бу кыйммәтле хәзинә борынгы кульязмалар белгече Илфат Сөләйманов кулына килеп кергәч кенә, чын эш башлана. Ул еллар буе зур хезмәт куеп, бу кульязмаларны гарәп әлифбасыннан кирилл хәрефләренә күчерә, басмага хәзерли, ниһаять, 2021 елда Казанда «Мәсаил вәгаз» китабы, 2022 елда Төркиянең Кония шәһәрендә Коръән тәфсире басылып чыга. Аңа кадәр Илфат Сөләйманов Златоустка да барып кайта, Мөхәммәдтаһир хәзрәттән калган архивны барлый, чын мәгънәсендә, бу мирас игелекле кулларга килеп эләгә. Ике мең битле бу кульязманы китап итеп бастырып, моңа кадәр билгесез булган рухи мирасны милләткә кайтару өчен, ул титаник хезмәт куйган.

Бу хезмәтләрнең дөнья күрүендә яшь галим, борынгы кульязмалар белгече Альфрид Бустановның, укытучы Нарим Ихсановның, Тайсуган авылының төбәк тарихчысы Ренат хаҗи Газизовның да роле зур. Төркиядә яңа басылып чыккан Коръән тәфсирен Тайсуганда халыкка тәкъдим итүне оештыручы, М.Байтукаловның тормыш юлын чагылдыручы күргәзмәләрне эшләүче, туган авылы турында китап язучы да әле ул Ренат хаҗи!

Бу чара да югары дәрәҗәдә үтте. Чиләбедән Мөхәммәдтаһир хәзрәтнең оныклары Фәридә һәм Диләрә, киленнәре Вера, оныкчыгы Руслан да килгән иде.

Тайсуган зур тарихлы, ныклы татар авылы, биредә дин укытулар көчле куелган, монда йөзләгән кеше, сигез төркемдә, дин дәресләре ала, бу эшләрдә Ләйлә абыстай Газизованың роле зур. Урта мәктәптә 150 бала укый, авылда миллилек һәм дин көчле булганга, хәтта Әлмәттән килеп укучы балалар да бар икән. Җыелышта М.Байтукаловның музеен ачу, «Байтукалов укулары» уздырырга кирәклеге турында да тәкъдимнәр яңгырады.

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

Яңгырлы кичтә

Афзал ШАМОВ

(Дәвамы. Башы 11, 12 нче саннарда).

Кая китте Дәүләт? Кая барып урнашты? Озак вакыт белүче кеше булмады. Хәер, Камилә аны эзләтеп тормады. Ул үзенең һәм кешелекнең дәрәҗәсен яхшы белүче горур хатыннардан иде.

Хәзер менә Дәүләт аның каршында, бер генә метр ераклыкта утыра. Маңгае, күз төпләре җыерчыкланган, артка кайтарып тараган чәчендә, ут яктысында җемелдәп, ак бөртекләр күренә. Соргылт күзләре электәге кебек йөгерек. Бер нәрсәдән икенче нәрсәгә бик тиз күчә, һәм ара-тирә ул күзләрдә Камиләгә таныш булган шаян чаткылар ялтырап китә.

Камилә дә картаймаган түгел. Ул да яшьлек елларын артта калдырып бара. Җентекләбрәк карасаң, аның битендә дә аз-маз җыерчыклар күренә. Гәүдәгә дә үсеп, тазарып киткән. Электәге шикелле чандыр түгел. Кайчандыр озын булып үсеп торган толымнарын кистергән, чәче, җыйнакланып, күпереп тора. Бөдрәле булса кирәк. Әллә кискәнгә бөдрәләнгәнме? Дәүләт аның йөзенә, күзләренә дә, җәя сыман сызылып килгән иреннәренә караштыргалап ала да: «Матурлыгын югалтып бетермәгән икән әле, шайтан», – дип уйлап, нәрсәдер әйтергә тели, ләкин сүзен башлап җибәрә алмый. Килеп керү белән үк Камилә тавыш чыгарып, кычкырышып, елар һәм ләгънәтләр дип көткән иде ул. Әмма Камилә тавыш чыгарырга теләми булса кирәк, күзләрен идәнгә, бер ноктага текәгән дә утыра, ара-тирә ул да нәрсәдер әйтергә теләгән сыман, башын күтәреп, аңа караштыргалап ала.

Авыр тынлык. Бу тынлыкны бетерергә, куарга теләгәндәй, тыштагы яңгыр, каяндыр килеп чыккан җил белән шаярып, үзенең вак тамчыларын тәрәзәгә китереп бәрә, йорт каршында, тәрәзә алдында үсеп утырган гөлҗимешләр дә, кинәт купкан җилгә каршы тора алмыйча, ялангач ботаклары белән тәрәзәгә сыеналар, җылыга, ышыкка керергә теләгән кебек, тәрәзә пыялаларын тырнап, шыкырдатып алалар... Берничә минут шулай уза. Бүлмә эче тәрәзәләргә килеп бәрелгән яңгыр тамчылары, ялангач ботакларның кыштырдаулары белән тула. Аннары җил каядыр китеп югала, гөлҗимешләр дә тырнакларын кире алалар, бары тәрәзә пыяларының эре-эре күз яшьләре белән елаганнары гына күренә. Бүлмәдә яңадан тынлык урнаша.

– Тукта әле, нишләп утырам соң мин, – диде Камилә пышылдап кына. – Чәй куеп җибәрим. Туңгансыз.

Ул, урыныннан торып, аяк очларына гына басып йөргән кебек, җиңел, йомшак адымнар белән кухня эчендә әйләнгәли башлады.

Чәй әзерләнгәч, Дәүләт, урыныннан торып, коридорга чыгып китте, аннан берсе ак, икенчесе кызыл аракылы ике шешә һәм кәгазьгә төргән бер тотам казылык алып керде, аларны барысын бергә өстәл өстенә куйды. Камилә шунда ук аларны җыеп алып, Дәүләтнең кулына тоттырды һәм бәхәсләшерлек урын калдырмаган тон белән әйтте:

– Кире чыгарып куегыз, үзегезгә кирәк булыр.

Дәүләтнең төшенмичә гаҗәпләнеп карап торуын күргәч, аңлатып бирде:

– Сыем җитәрлек. Үз азыгы белән килгән кунак – кунак түгел. Тагын шунысы да бар: моңа кадәр әле минем өемә бер чит кешенең дә аракы белән казылык күтәреп кергәне булмады. Моннан соң да булмас дип уйлыйм.

– Мин бит чит кеше түгел, – диде Дәүләт.

– Сезме?.. Сез миңа чит. Чит кеше.

Дәүләт, аның җыерылган кашларын, бигрәк тә күз карашын күреп, гаҗәпләнеп уйлады: «Нишләгән бу?! Каян килгән аңа бу кыюлык?» Шулай да ул үзенең чит түгеллеген исбат итәргә теләде:

– Нишләп чит булыйм?.. Бала әтисе түгелмени мин? – һәм ул, моны раслап, кулы белән дә, башы белән дә бала йоклап яткан бүлмәгә таба ымлады. Әмма үзенең бу сүзенә, ишарәсенә шунда ук үкенде, чөнки Камилә, иреннәрен кысып, аңа текәлеп карап тора иде. Яңаклары алсуланып яна, колак яфраклары кызарган. Барыннан да бигрәк, аны әллә теш арасыннан, әллә калтыраныбрак әйтелгән сүзләре таңга калдырды:

– Балага җан бирү – эти булдым дигән сүз түгел әле. Баланы аяк үстерергә, тәрбияләргә кирәк. Аны кеше итәр өчен үз җаныңны бирергә кирәк... Барыгыз, әйберләрегезне чыгарып куегыз.

Дәүләт, буйсынып, алып килгән әйберләрен күтәреп, коридорга чыгып китте. Аннан әйләнеп кергәндә, инде күзләрендәге шаян чаткылар югалган, ә үзе бераз боегып калган кыяфәттә иде. Табын янына утыргач, ул, әйберләр алып килүен акларга теләп булса кирәк:

– Мин бит аларны үз итеп, якын итеп алып килгән идем, – диде. – Утырырга күңелле булсын өчен.

– Сез болай да күңелләнеп килгәнсез.

Дәүләт сәер елмайды:

– Анысы инде батырлык өчен.

– Нинди батырлык өчен?

– Мин бит синең белән чынлап сөйләшергә кайттым. Кара әле, Камилә, син бит бала түгел, аңларга тиеш, – дип, ул, кыюлана төшеп, бераз төче тавыш белән сөйләргә кереште: – Кайттым дигәч тә, бөтенләйгә кайттым. Монда калырга телим. Синең белән. Гомергә. Күп йөрдем. Җитәр... Гаебемне беләм, җанкисәгем... Нәрсә, җанкисәгем дигәнне яратмыйсыңмы әллә?.. Алай әйтергә ярамыймыни?.. Үзең беләсең ич, синең өчен җанымны биргән чаклар булды. Кем белә, бәлки, мин сине беркайчан да онытa алмаганмын. Анысы сиңа караңгы. Үзем генә беләм. Хәер, син барыбер ышанмыйсың. Ышанмаска хакың да бар. Нигә яшерергә! Булган эш – булган. Дүрт аяклы ат та абына. Егет кешенең башыннан ниләр узмас та, ниләр үтмәс. Бер уйласаң, гаеп итеп тә булмый. Бер уйласаң, гаебем зур, җанкисәгем... Нигә кашларыңны җыерасың? Мин бит аны үз итеп, якын итеп әйтәм. Синең кебек «сез» дип сөйләшмим. Нигә күңелдә таш сакларга? Нигә барысын берьюлы чыгарып ташламаска? Беләм, гаебем кечкенә түгел. Ташлап киттем. Хәлеңне дә белешмәдем, акча да җибәрмәдем, хәтта кайда икәнемне дә белдермәдем...

Камилә, җәймә чукларын бармаклары белән аралаштыргалап, аның туктала-туктала сөйләгәнен эндәшми генә тыңлап утыра иде. Аның соңгы сүзләрен ишеткәч, күтәрелеп карады.

– Шулай да мин сезнең кайларда йөрүегезне белеп тордым, – диде. – Бу турыда сөйләшмик. Кирәк икән, соңыннан сөйләшербез... Әтинең бик матур бер гадәте бар иде: башта кешенең тамагын туйдыра, аннары гына җитди эш турында сөйләшә иде. Минем дә шулай буласым килә... Ашагыз. Нигә эчмисез? Суына бит. Эчегез.

Алар икесе дә, узганнар турында хәзергә сөйләшмәскә теләп, әмма икесе дә, күңелләреннән шул турыда уйлап, чәйләрен эчәргә, алларындагы азыкларны капкаларга тотынды. Дәүләтнең тамагы шактый ачыккан иде ахры, алдындагы тәлинкәне бик тиз ялтыратты. Камилә аңа утлы газ өстендә бераз чыжлап торган табадан тагын итле бәрәңге салып бирде, кимеп барган сыр, колбаса янына яңа телемнәр өстәде.

Дәүләт Камиләне бу хәлдә очратырмын дип көтмәгән иде. Аерым фатир, гади, җыйнак, пөхтә җиһазлар, шүрлектәге китаплар, аннары Камиләнең олыгаеп китүе, аның алдында каушап калмавы, үзен ирекле, кыю тотуы, тагын нәрсәләрдер, барысы да аны бераз аптырашта калдырган иде.

Чынаягын өченче тапкыр чәйгә сузганда ул, узганнар турында хәзер сөйләшмәскә дигән киңәшне онытып, яңадан юка телләнеп сөйләргә кереште. Ләкин Камилә аның беренче җөмләсен ишетү белән үк сүзен бүлде, терсәкләрен өстәл өстенә куеп, уңайлабрак утырды һәм, аңа төбәп карап әйтте:

– Дәүләт, әгәр сөйләшергә телисез икән, әйдәгез чынлап сөйләшик. Яшермичә сөйләшик. Намуслы кешеләрчә. Ризамы?

Дәүләт аның тавышы ныгыганын, калтырануы беткәнен сизеп алды. Бая аның тавышы теш арасыннан чыкмаган, ә калтырануыннан гына шулай яңгыраган икән.

– Риза.

Камилә, ничек сүз башларга дип, бераз уйланып торды. Аннары, Дәүләтнең күзенә карап, сорады:

– Маһирәң кайда хәзер?

Маһирә – аның белән бергә Казаннан качып киткән кыз иде.

Бу исемне ишеткәч, Дәүләтнең күзләре кысыла төште, әллә уйланып, әллә болай гына, алдындагы күмәч валчыкларын бармаклары белән җыештыргалап, бераз җавапсыз торды. Камилә яңадан сорады:

– Кайда икәнен белмисезме әллә?

Дәүләтнең ирен кырыйлары тартылып китте: көлемсерәү идеме бу, әллә искә төшерергә теләмәү идеме?

– Кем белә аны, – диде, ниһаять, ул. – Аның белән торырлык түгел иде. Бик сөйрәлчек булып чыкты.

– Ярар, Маһирәне тикшермик. Анда эшем юк. Чиләбедә тагын өйләнгәнсез дип ишеткән идем. Анысы кайда хәзер?

Бу юлы Дәүләтнең кашлары югары сикерде: «Каян белә?» Теләмичә генә җавап бирде:

– Язылышмаган идем мин аның белән...

Хатын аның сүзен дәвам итүен, ачыграк сөйләп бирүен көтте. Сөйләргә теләмәгәнлеген күргәч, кайтарып сорады:

– Шулай да кайда соң ул хәзер?

Дәүләткә ачыктан-ачык сөйләп бирмичә мөмкин түгел иде, яшермәскә сүз бирелгән иде. Аннары хәзергә ул ялганы тотылуын да теләми иде. Каһәр төшкәннең, барысын да белеп торуы мөмкин:

– Кайда дип, кем белгән инде аны. Кайда йөри торгандыр. Мин кумадым... Үзе китте. Торырга теләмәде. Әй, китүе яхшы ла аның! Әллә кем түгел иде. – Һәм ул, юмалап, Камиләнең күңелен табарга теләп, дәвам итте: – Кая инде ул, җанкисәгем, сиңа җитәргә! Синең кискән тырнагыңа да тормый алар... – Ләкин юмалавыннан шунда ук туктарга мәҗбүр булды, чөнки Камилә аның сүзләрен яратмаганлыгын бик ачык сиздереп карап тора иде.

– Ташласагыз ла, зинһар, шул кирәкмәгән төче сүзләрегезне! – диде ул аңа салкын гына. – Иң яхшысы, шуны әйтегез: Төмәндәгесе белән язылышкан идегезме?

Моңа дөресен әйтмичә мөмкин түгел. Ләкин дөреслек авыр һәм ачы. Шуңа күрә ул сүзне икенчегә борырга тырышты:

– Димәк, син минем кайларда йөрүемне белеп, күзәтеп торгансың. Шулаймы?

– Юк, күзәтмәдем. Хәтта сорашмадым да. Шулай да белдем. Авылдашларыгыз әйтте.

Дәүләтнең бу сүзләргә ышанмавы көлемсерәвеннән, күз карашыннан сизелеп тора иде: «Күзәтеп, белешеп торган. Оныта алмый, күрәсең, һаман ярата икән», – дип уйлады ул, һәм күзләренә яңадан әлеге шаян чаткылар кайтты, йөзе дә ачылып, җанланып китте. Аның бу минуттагы кыяфәте һәм күзендәге тынычсыз чаткылары нәрсәдер өмет итүен сиздереп торалар иде.

Ул, ниндидер эчке көч, бәйсез теләк ихтыярына бирелеп, үз-үзенә ышанып, урыныннан торды, тиз генә ишеккә карап алды, аннары төче елмаеп, Камиләгә таба килә башлады. Хатын, аның бу үзгәрешен күреп, урыныннан торган, төз, зифа буе белән басып тора иде.

– Дәүләт, әгәр хур ителеп, мыскылланып чыгып китәсегез килмәсә, тыныч кына утырыгыз! – диде ул аңа. Бу сүзләрне ул шундый тыныч һәм ышандырырлык итеп әйтте, Дәүләт, кинәт туктап, тынып калды һәм, хәкарәтле көлемсерәп, яңадан урынына кайтты. Аның кемнән көлемсерәвен – үзеннәнме яисә Камиләдәнме икәнен төшенерлек түгел иде.

– Сезгә йокларга вакыт, – диде хатын. – Минем дә иртүк эшкә барасым бар.

Ул тиз генә өстәл өстен җыеп алды. Аяк очларына гына басып йөреп, бүлмәдән урын-җир әйберләре алып керде, идәнгә, матрас өстенә ак, чиста простыня җәйде, мамык мендәр салды һәм үзе ябынып ята торган юрганын кертеп бирде. Дәүләт аның йомшак йөрешеннән, адымнарыннан, бөтен хәрәкәтеннән күзен алмый карап тора иде.

– Ярар, йоклагыз. Хәерле төн, –диде хатын, ишеккә таба борылды.

Дәүләт әле һаман нәрсәдер өмет итә иде. Бала ишетмәсен дигән кебек, пышылдап кына сорады:

– Ә үзең кайда ятасың?.. Бәлки...

Хатын аның сүзен тыңлап бетермәде, ишекне ябып, чыгып китте.

(Дәвамы киләсе санда).

«Идегәй» – дастан үрнәге

**(Дәвамы.
Башы 11, 12 нче саннарда.)**



Табигый инде, Чыңгыз токымына караучы олуг хан Туктамышның үзен тәхеттән төшерүдә якыннан торып катнашкан, Алтын Урданың фактик идарәчесе булып киткән Идегәйгә өстен катламнар һәм халык алдында үзенең хөкемдар булырга хокукы барлыгын расларга кирәк булгандыр. Шулай ук Алтын Урданың бер өлешендә барлыкка килгән Нугай Урдасы башында, аннан соң да озак еллар буена утырган Нуретдин исемле улы һәм оныклары да моңа мохтаҗ булгандыр. Дастанның «Җәмигъ эт-тәварих» исемле Кадыйр Галибәк җыентыгындагы бер вариантында бирелгән «Идегәй»нең «изге нәсел» шәҗәрәсен тарихчы М.Госманов нәкъ шуңа бәйләп аңлата да. Шәҗәрә буенча, Идегәйнең нәсел башы Мөхәммәд Пәйгамбәрнең хәлифәсе-көрәштәше, каенатасы булган Әбүбәкердән башлангыч ала, ә кайсыдыр буында мөселман изгесе һәм кыпчакларның героик эпос геройларын яклаучы легендар Баба Төкләскә (Төкле Бабага) барып тоташа. Реалистик төсмер бирелеп, әлеге шәхес XII йөздә яшәгән атаклы суфи шагыйрь Әхмәд Ясәви белән дә тиңләштерелә. Әсәрдә Идегәйнең бабасы Баба Төкләс Хуҗа Әхмәт булган дип күрсәтелә дә.

Дастан герое Кара-Тиен Алып сүзләре буенча, укучы Идегәйнең әнисе, имеш, пәри (яки аккош) булган дигән әкияти-мифик мәгълүмат белән дә очраша. Янәсе, Баба Төкләс, үзенең аккош «тире-киемен» салып, күлдә су коенган чибәр кызга өйләнгән, Котлыкыя исемле балалары тугач, әлеге кыз-аккош боларны ташлап киткән. Котлыкыя исә, үсеп җиткәч, гүзәл пәри кыз белән кавышкан, һәм шул никахтан Идегәй туган, имеш.

Югарыда китерелгән ике шәҗәрәнең икенчесе – тотемистик катламнан арындырылып һәм ислам дөньясының «алтын баганалары» белән бәйләп мөселманлаштырылганы – соңрак барлыкка килгән дип исәпләнә. В.Жирмунский фикеренчә, ошбу изгеләштерелгән «фәнни» шәҗәрә Идегәйнең, Алтын Урда башында утырырга хакы барлыгын раслау максатыннан, үзе исән вакытта ук туа башлаган булырга тиеш. Ул төрле каналлар аша, шул исәптән «социаль заказ» буенча аерым чичән-җыраулар ярдәмендә дә, Алтын Урданың ислам дине тоткан халкы арасына максатчан рәвештә таратылгандыр да. Идегәйдән соң Нугай Урдасы башында калган нәселе-варислары да, әлбәттә, бу эштән читтә калмагандыр.

Дөрес, шәхси дәгъвасын гамәлгә ашырганда, Идегәй илдә хан тәхетенә Чыңгыз нәселеннән чыккан бәк яки әмир генә утырырга тиеш дигән канунга яраширга мәҗбүр булган. Әмма шул ук вакытта ул «изге нәсел» шәҗәрәсен дә бик оста эшкә җиккән булуга охшый. Дастанда турыдан-туры аның үз авызыннан әйтелгән сүзләр нәкъ шуны раслап тора да:

Туксан башлы Урдага
Тунамый ия булмасам...
Әйткәнемне кылмасам...
Мин үчемне алмасам,
Төкләс бабам биргән
Идегәй атым корысын!

Алга таба каһарман гаять эреләнеп, масаеп, хәтта: «Борынгыдагы Чыңгызның үзе белән тиңдермен», – ди. Шушы ук фикерне, «Чыңгызның кайсы улынная кимдермен?» – дип, икенчерәк сүзләр белән Идегәйнең улы Нурадын да әйтә.

Иң мөһиме: «Идегәй» дастанында ил-дәүләт тотучы хөкемдарның дәрәҗәсе Чыңгыз нәселеннән чыгу-чыкмавына карап кына түгел, ә аның идарә итү осталыгы, ягъни күрсәткән эш-гамәлләре белән билгеләнергә тиеш дигән гадел фикер үткәрелә. Менә шуңа күрә Чыңгыз токымына караучы «законлы хан Туктамыш» (гәрчә баштагы чорда зур уңышларга ирешкән булса да!) кылган хаталары өчен әсәрдә урынлы тәнкыйть ителә. Үлемгә хөкем ителгән Котлыкыя авызыннан: «Били белсәң, ханиям, икселмәс (кимемәс, какшамас) дәүләт иде бу», – дип, ханга кискен гаепләү сүзләре әйттерелә. Шулай ук заманында бай төбәктә яшәгән җирле халыкның каласы юкка чыгуы һәм үзенең «кола чүлгә» күченергә мәҗбүр ителүе өчен дә гаеп ташлана. Соңгы очракта сүз Аксак Тимер белән алып барылган мәгънәсез сугышларның аяныч нәтиҗәсе хакында бара. Бу турыда тарих һәм әдәбият галиме М.Әхмәтҗанов, 1395 елгы сугышны да кертеп, болай яза: «Алтын Урда халкы арасында моңарчы күрелмәгән күченү-буталу хәрәкәте башлана. Әлеге дә баягы 1391, 1395 еллардагы мәхшәрдән соң икътисад, һөнәрчелек, мәдәният үзәге булган шәһәрләр һәм утрак тормыш хөкем сөргән төбәкләр бушап кала, дөресрәге, хәрабәләр өеменә әйләнә» (Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы. – Казан, Мәгариф, 2002. – 178 б.). Нәкъ шушы фаҗигале хәлләр Котлыкыяда гына түгел, халыкның төрле катламнарында да ризасызлык тудырган. Соңгы сугыш аеруча зур корбаннарга, җитди югалтуларга китергән һәм хакимият алмашыну белән тәмамланган. Калганы инде безгә билгеле.

Алда сөйләнгәннәрдән күренүенчә, Алтын Урда тормышына һәм Туктамыш белән Идегәй шәхесләренә бәйләнешле вакыйгалар гаять катлаулы, киеренке һәм кискен булган. «Идегәй» дастаны әлеге вакыйгаларны төрле үзгәртүләргә, сәнгати-эстетик эшкәртүгә дучар итсә дә, аларның реаль нигезлешен һәм рухын сакларга тырыша. Шул ук вакытта, бигрәк тә Идегәй образының шактый нык идеаллаштырып, калку итеп тасвирлануында, билгеле бер дәрәҗәдә социаль заказга нигезләнгән субъектив-тенденциоз бәяләмә дә катнаша. Әлеге бәяләмә, һичшиксез, халыкның гадел хөкемдар образында үзе күрергә теләгән гаделлек, туган җирне ярату, коллыкта яшәүчеләрне азат итү, кануннарны саклау, бала-җанлылык кебек сыйфатлар белән дә үрелеп килә. Өстәвенә дастанда каһарманны гади халыкка һәрчак ярдәм итүче чын кеше итеп сурәтли һәм данлый торган берничә вариантлы рефрен да бар. Әлеге рефренда саналган кешелек сыйфатлары Идегәйдә көтү көтеп үскән вакытында ук инде тернәкләнгән, акрынлап аны гади халык арасында танытткан итеп тасвирлана. Менә ул рефренның Колчура тарафыннан әйтелгән варианты:

Ятимнәргә – яр булган,
Колчурага – дус булган,
Аты юкка – ат булган,
Чүлләгәнгә – су булган,
Адашканга – юл булган,
Ялгызга – ясак булган,
Җәяүгә – таяк булган,
Карны ачканга – тамак булган
Идегәй ир бар икән.

Әмма искә төшерик: халык үзе идеаллаштырган Идегәйне, иле өстенә дошман гаскәрен алып килгәнә, Сарайны җимерттергәнә өчен, үзе үк ачыктан-ачык гаепли, кискен рәвештә хөкем дә итә. Монда инде дастан авторларының чичән-җырауларның, – үзләре тудырган һәм социаль заказ йогынтысын да чагылдырган идеал, романтик, ягъни героик-эпик образ кысалары белән генә чикләнмичә, тарихи-реаль Идегәйнең халык күңелендә тирән эз калдырган хыянәткә бару фактын да кертеп җибәрүе, димәк, объектив дөреслеккә баруы күренеп тора. Нәкъ менә җимерек Сарай символы аша һәм дә Идегәйнең хәтта үз гаиләсендә шау-шу чыгуын тасвирлау ярдәмендә халык Аксак Тимер явының илгә иксез-чиксез бәла-казалар китергәнлегенә дә ишарә итә.

Сөйләнгәннәрдән үзеннән-үзе соралып торган бер нәтиҗә шул: гомумән, эпик Идегәй, берьяктан, идеаль-героик итеп сурәтләнгән образ булса, икенче яктан, ул – драматик-трагик каһарман да. Бу, һичшиксез, аның тормышта героик табигатьле, әмма каршылыклы трагик шәхес булганлыгы белән бәйле. Идегәйнең үз иленә мөнәсәбәтле ялгыш һәм мәкерле адымын аклап булмаса да, шуннан чыгып аны, узган чорның дәрәҗәле галиме Р.Фәхретдин кебек: «Тимерләнкне бу мәмләкәткә алып килеп, Дәшти Кыпчак дәүләтен харап иттерде... Бу көндә ошбу җир мөселманнарының түбән вә хур булып калуларының сәбәпчесе Тимерләнк вә аның да мондый һәлакәтне җиренә җиткерүгә сәбәпче Идегәй мирза булды» (Фәхретдин Р. Идегәй мирза // «Шура» журналы. – 1908. – № 8), – дип гаепләү һәм бу ике шәхесне үзара тәңгәл кую белән килешеп булмый торгандыр. Шулай ук, бүгенге кайбер галимнәр кебек үк, Идегәй образына яки шәхесенә Алтын Урданың таркала һәм җимерелә башлавына нигез салучы дип мөһер сугу да акланмыйдыр. Мондый үтә берьяклы карашлар Алтын Урда тарихын монографик планда өйрәнгән мәшһүр галимнәрнең – Б. Д. Греков белән А. Ю. Якубовскийның объектив һәм гадел нәтиҗәсе белән бөтенләй ярашмый. Менә ул нәтиҗә: «Идегәй иң соңгы Алтын Урда хөкемдарларының берсе иде. Ул Көнчыгыш Европада татар хакимиятенең элекке бөек державачылыгын булдырырга омтылып кына калмады, ә билгеле бер вакытта аны гамәлдә дә тормышка ашырды» (Греков Б. Д., Якубовский А. Ю. Золотая Орда и её падение. – М. : Изд. АН СССР, 1975. – С. 104.).

(Ахыры киләсе санда.)

Марсель БАКИРОВ,
филология фәннәре докторы.

Атнаның сәяси мизгелләре

Низагны җайга салу шарты

РФ тышкы эшләр министры урынбасары М.Галузин, RTVi телекомпаниясенә биргән интервьюсында, Россиянең Украинадагы низагны тыныч юл белән җайга салырга әзер булуы турында белдергән. Аныңча, Украина һәм Европада гадел, тотрыклы тынычлык урнаштыру өчен түбәндәгеләрне үтәү кирәк: Киевнең – сугыш хәрәкәтләрен, ә Көнбатышның аңа корал куюны туктатуы; чит илләрнең яллы хәрбиләрен аннан чыгару; Украинаның нейтраль статусын тәэмин итү; аның НАТО һәм ЕСтан баш тартуы; «атом-төш коралсыз ил» статусын раславы; Украина һәм халыкара оешмаларның бу илдәге территориаль реальлекне тануы. Ә низагны туктатуның мәҗбүри шартлары итеп ул Украинада демилитаризация-денацификация үткәрү, рус теле һәм рус телленәрнең хокукларын яклау, Россиягә каршы кертелгән санкцияләрне туктату һәм гаризаларны алу, бу илгә һәм аның юридик вә физик затларына карата суд әзәрлекләүләрен туктату кебек таләпләр дә куя.

Апрельдә БМО КШ да рәислек Россиягә күчә. Бу чорда ул «Арриа формуласы» буенча КШ әгъзаларының формаль булмаган очрашуын уздырырга җыена икән. Очрашуларның мондый формасы әгъзалар арасында ачык фикер алышу мөмкинлеге бирә, имеш. Ә Россия анда МХО зонасыннан балаларны эвакуацияләү мәсьәләсен күтәрергә җыена. Шуңа күрә ул КШ әгъзаларын, Украина кораллы көчләре анда торак пунктларны утка тотканда һәм башка җинаятьләр кылганда, Россия ничек итеп балаларны яклавы һәм куркынычсыз районнарга күчереп урнаштыруы турында тәфсилләп сөйләргә җыена, имеш.

Игътибарны атнаның кайбер башка вакыйгаларына да юнәлтик. Үзәк банкның 2022 елда 721,7 млрд сумлык зыян күрүе мәгълүм булды һәм бу 2021 елдагыдан 27 тапкыр күбрәк. РФ Президенты В.Путин санкцияләрнең Россия икътисадына тискәре йогынты ясау мөмкинлеге турында әйтте. Финляндиянең НАТОга әгъза итеп алынуына инде Төркия дә ризалык биргән. Россиянең зур сәнәгать объектларында янгын чыгу һәм шартлау очраклары дәвам итә. Россия Венгрияне дус булмаган илләр исемлегенә керткән. Мәскәүдә суд АКШ журналисты Эван Грешковичны, шпионажда гаепләп, кулга алган.

Фоат УРАЗАЙ.

ИҢ ГАҖӘЕП

● Малайзия. Путра мәчете. Алсу граниттан.

Иранның Шираз каласында Насир әл-Мөлк мәчете бизәлеше чын мәгънәсендә төсләр калейдоскобына тиң! Ул – дөньядагы иң матур мәчетләрнең берсе. Бизәлеше сәбәпле ул хәтта могҗизаи шкатулкага да охшаш. Мәчет эченә керүгә үк, диварлардагы, түшәмдәге, идәндәге җете бизәкләрдән баш әйләнерлек! Кояш нурлары төсле витражлы тәрәзәләр аша бина эченә үтеп кереп, мәчет залларын сокландыргыч лабиринтка әйләндереп куя. Әлеге бина зур түгел,әмма аның заллары буйлап барган кешеләр, гүя ки, төсле, параллель дөньяга эләгә. Ул 1877-1888 елларда Каджарлар династиясенең Мирза Хәсән Али Насир әл-Мөлк заказы буенча төзелгән. Аның икенче аталышы да бар – Алсу мәчет. Чөнки мәчеттәге төп бизәк – розалар. Калада өч йөз төр роза гөлләре үстерелә, шул сәбәпле бу мәчеттә дә шушы кала символы сурәтләнгән.

● Алсу мәчет. Филиппин.

Ә менә чыннан да тулысынча алсу төстәге генә мәчет – Филиппинда. Димауком мәчете (халык аны Алсу мәчет дип тә йөртә) 2014 елда Магинданао провинциясендә ул чаклардагы мэр С.Димауком теләге белән, аның милке булган җирдә төзелгән. Мәчетнең төсе – тынычлык, мәхәббәт, узара дуслык символын аңлата. С.Димауком аны үз акчасына салдырган. Бинаны мөселманнардан кала христиан динен тотучылар да төзегән, ә бу үзенә күрә диннәр татулыгын искәртә. Кала башлыгы күрсәтмәсе буенча мэрия, базар бинасы, мәктәп, полиция участоклары һ.б. төр җәмәгать биналары да алсу төскә буялган. Әмма шунысы да мөһим: Филиппиндагы халыкның 5% гына исламда. Мәчеткә йөрүче балалар биредә Коръән сүрәләрен өйрәнә, гадәттә, алар да укырга алсу киемнәр киеп килергә тырыша.

1999 елда Малайзиянең Путраджая каласында алсу граниттан төзелгән, 15 мең кешене сыйдырырлык Путра мәчете дә үзенең алсу төсе белән аерылып тора. Ул – Малайзия премьер-министры резиденциясе янәшәсендә, Путраява дип аталган ясалма күл читенә салынган. Мәчетнең манарасы 116 метрдан артык һәм исламның биш нигезен символлаштырган биш дәрәҗә-күрсәткечтән дә тора.

Мароккодагы Касабланка шәһәрендә Хассан II мәчете илдә иң зурысы, ул дөньяда да жиденче зур мәчет дип исәпләнә. Ул Хассан II идарә иткәндә 1986 елны алты мең һөнәрче тарафыннан төзелә башлап, 1993 елда гына төгәлләнгән. Иң биек манарасы 210 метрны тәшкил итә, ул Хеопс пирамидасыннан да биегрәк! Мөселман динендә булмаган француз архитекторы Мишель Пинсо манарага лазер урнаштырган, ә аның яшел яктылык линиясе, нуры бик еракларга сузылып Мәккәгә таба юнәлдерелгән.

Биредә берьюлы 105 мең кеше намаз кыла ала: 25 мең кеше – мәчет эчендә һәм 80 мең кеше – мәчет ихатасында. Гыйбадәт залын 78 алсу гранит колонна бизи, идәнгә яшел оникстан һәм алтынсу мәрмәрдән ясалган плитәләр җәелгән. Түшәмдәге гаять авыр пыяла люстра Италиядән кайтартылган. Бина Атлантик океан янындагы чыгынтыга салынган, шуңа да мәчетнең пыяла идәне аша... су төбен дә күреп була!

Ә менә Әл-Сәхәбә мәчете Шәрм эш-Шәехтәге иң яңа һәм иң зур мәчет дип санала. Аның төзелеше 2016 елны гына тәмамланган. Мәчетнең ике манарасының биеклеге – 81 метр. Ул көндез дә, кичләрен дә чиксез матур, архитектурасы да кабатланмас, шуңа күрә әлеге мәчет ил халкын да, чит дәүләт туристларын да үзенә тартып торучы урыннарның берсе.

Пакьстанда урнашкан Шаһ Җаһан мәчете дә илнең архитектура энҗесе! Ул Татта каласында урнашкан, аны төзүчеләр башта Урта Азия архитектурасын күреп илһамланган. Мәчетнең төзелү тарихы үзенчәлекле: XVII гасырда Таттада, әле мәрмәрдән Таҗ-Махалны да төзетәчәк һәм үзе дә шунда җирләнәчәк Шаһ Җаһан яшәгән. Ул, идарәче әтисе Җиһангирга каршы түнтәреш күтәрүдә гаепләнгәч, башкаладан качарга мәҗбүр булган. Ә соңрак, тәхеткә утыргач, Таттаны онытмаган. Кайчандыр кунакчыллык күрсәткән өчен ул анда зур мәчет төзетергә ният кылган. 1644-1647 елларда төзелгән мәчет ачылган. Ул гаҗәеп архитектурасы белән үзенә тартып тора. Моңа кадәр Шаһ Җаһан Сәмәркандка барып кайткан булганга күрә, бина Урта Азия йогынтысында, биредә дә кирпеч, дивар бизәлешендә исә матур зәңгәр плитәләр кулланылган. Көньяк Азия бинасын төрле төсләрдәге плитә белән бизәү иң катлаулы эш булып саналган. Мәчет гөмбәзе өчен йолдызлы бизәк, күк йөзен хәтерләтүче зәңгәрләаклы плитәләр сайланган. Дивардагы плитәләргә каллиграфик язмалар өстәлгән, аларны язган осталарның исемнәре дә шул тирәгә теркәп куелган: Абдулгафур һәм Абдулшәих. Мәчеттәге бизәкләр геометрик формаларда килеп чыгарлык итеп ясалганга күрә, Бөек Моголлар заманы өчен бу башка төр декоратив элемент та.

Шаһ Җаһан мәчете манарасы булмау белән дә үзенчәлекле. Ләкин аны 93 гөмбәз каплап тора. Ахрысы, әлеге үзенчәлек бинада искиткеч акустика тудыра, михраб янында укылган догалар мәчетнең теләсә кайсы өлешендә дә ишетелеп тора!

Ирандагы Шаһ Черах мавзолей-мәчете – Шираздагы искиткеч үзенчәлекләрнең тагын берсе. Анда Муса әл-Кадимнең уллары – Әхмәт һәм Мөхәммәд җирләнгән.



● Катар. Доха мәчете күренешләре.

МӘЧЕТЛӘР

● Мали. Дженнедагы үзле балчыктан ясалган мәчет.



● Иран. Шираз. Шаһ Черах мәчете.

Алар 835 елда габбасилар белән шигыйлар арасындагы каршылыклар вакытында үтерелгән. Мәчет XIV гасырга карый. Мавзолей мәчет вазыйфасын да башкара. Шигыйлар бирегә еш килә. Баштарак патшабикә Таши Хатун әмере белән Әхмәт һәм Мөхәммәд җирләнгән урынга гөмбәзле корылма куелган булган. Шаһ Черах аталышы «Яктылык шаһы» дип тәрҗемә ителә. Мондый аталышның үз сәбәбе бар: риваять буенча, аятолла Дастахиб төнлә ниндидер яктылык күргән һәм куркып калмыйча, шул якка таба юнәлгән. Зираттагы кабердән сибелүче нур биредә күмелгән җәсәдтән тарала, ә аның кулындагы балдакка «Бөеклек Аллаһ Тәгаләнеке. Әхмәт Муса улы» дип язылган икән. Шулай итеп, Муса әл-Кадим улларының кайда җирләнгәнлеге ачыкланган.

Әлеге мәчет-мавзолей – Иранның мәдәни мирасы исемлегенә кертелгән тарихи һәйкәл. Аның тышы берникадәр гади, диварлар бизәлешендә традицион мозаика кулланылган, архитектура стиле дә бу яклар өчен ят түгел. Мәчетнең ике манарасы бар. Ике катлы булса да, биек итеп ясалмаган. Ә менә аның эчке диварларына үтүчеләр, биредә пыяла кисәкләре һәм көмеш пластиналар белән бизәлгән матурлыкка тап була. Көзге кисәкләре төрле формада булгач, яшел, алтынсу һәм көмешсу төсләр белән нурланып тора, түшәмдәге кыйммәтле люстралар бу байлыкны көчәйтеп җибәрә. Гөмбәзе исә көзге фрагментлары, берилл һәм фирүзә төсендәге пыялалар, кыйммәтле ташлар белән капланган. Шуңа күрә халык аны «Көзгеле мәчет» дип тә атый. Ул могҗизаи матурлыгы белән мөселманнарны гына түгел, туристларны да җәлеп итә. Якты нурлы бина эченә кергән кайберәүләр, нинди динне тотса да, мәчет бизәлешен күреп, һуштан язардай була. Биредә фотога төшерү тыела. Чөнки дога кылучыларны фотога төшерү җинаять кылу белән бер. Ә гомумән алганда, бар да игелекле мөнәсәбәттә.

Көзгеле залда ялтыравык саркофаг тора, аның янында һәрвакыт ир-ат һәм хатын-кызлар чираты – изге кеше җәсәден күрергә килүчеләр. Моннан кала бу мәчеткә махсус килеп, идәннәренә утырып, биредәге матурлыкка сокланучылар да күп. Кемдер дога кыла, кемдер Коръән укый... Бала таба алмаучылар ихлас теләкләрен кабатлый.

Иран каласы Исфаханда урнашкан моннан да гаҗәбрәк бизәлештәге, борынгы Лотфулла җәмигъ мәчетен дә искә алырга мөмкин. Аның дүрт айваны, ягъни бер-берсенә каршы урнашкан капкалары булуы җәйлы. Мөкарнаслар – бал корты кәрәзләренә охшаш корылмалар мәчетнең көньягында инде XIII гасырда ук ясалган һәм мәчетне күрергә килүчеләр арасында аларга сокланып, бизәм нечкәлекләренә бик озак карап торучылар күп.

Моннан кала да планетада бик затлы итеп төзелгән һәм бизәлгән мәчетләр бихисап, тик мәчетләр арасында бик гадиләре дә юк түгел. Әйтик, үзле балчыктан ясалган иң зур мәчет – Малиның Дженне шәһәрендә. Ул – Африка күрке. XV-XVI гасырларда шәһәр Африкада таралачак ислам үзәгенә әверелгән. Каладагы беренче мәчет 1200 һәм 1300 еллар арасында төзелсә, бүгенге мәчет 1909 елгы. Ул үзле балчык, ком һәм су кушып ясалган тыгыз измәдән салынган. Үзәк башнясының биеклеге – 16 метр чамасы. Хәзер инде мәчет эченә электр уты да тоташтырганнар. Әмма бу дин йортына бары мөселманнарны гына кертәләр. Гомумән, Малидагы барлык мәчетләргә дә мөселманнар гына керә ала.

Мәчетләр арасында иң заманчасы, һичшиксез, Катар дәүләте башкаласы Дохада урнашкан мәчет. Әлеге футуристик архитектура үрнәге башкала үзәгеннән читтәрәк урнашкан. Керамикадан житештерелгән тышлыклар кешеләрне кояш нурларыннан саклый. Мәчет университет шәһәрчеге эчендә, биредә Ислам дисциплиналары факультеты урнашкан. Ул Лондондагы архитектура бюросы проекты буенча төзелеп, 2015 ачылган һәм үз эченә 1800 кешене сыйдыра. Аның 90 метрлы ике манарасы исә Мәккә юнәлешенә туры китереп урнаштырылган, алар «фән һәм яктылык» төшенчәләрен дә символлаштыралар. «Белем шәһәре» үзе 2003 елда ук ачылган. Анда мәктәпләр дә, алдынгы университет филиаллары да эшли, моннан кала биредә Аш-Шакаб – гарәп токымлы атларны үрчетү үзәге дә урнашкан. Кислородлы парк, заманча сәнгать музее һ.б. Белем белән дин үзара бәйле дигән концепциядән чыгып, төзелмәнең спираль пландагы күп коридорлары уку бинасы белән мәчетне үзара тоташтыра. Бина исламның биш баганасын чагылдырган биш нигезгә таянып күтәрелгән. Мәчеттән тыш, монда китапханә, уку аудиторияләре, бакча, ял бүлмәсе, укытучылар кабинетлары да бар. Тышкы диварлар һәм манаралар Коръән аятьләре белән бизәлгән. Әлеге заманча корылма бик күп халыкара бүләкләргә лаек булды. 2015 елда Сингапурда узган Бөтендөнья фестивалендә дә ул иң яхшы дини бина дип табылды. 2017 елда уку биналарын проектлау буенча АКШ архитектура премиясенә дә лаек булды һәм башка илләрнең талантлы архитекторлары өчен дә илһам чыганагына әйләнде!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
әзерләде.

● Иран. Исфахан каласы. Лотфулла мәчете.

● Марокко. Касабланка. Атлантик океан янындагы Хассан II мәчете.

● Әл Сәхәбә мәчете. Шәрм эш-Шәех. Мисыр.

Мәдәни җомга
7 апрель
№13, 2023

Татар дөньясы

Ижау хәбәрләре

● Удмуртия татарларының милли-мәдәни автономиясе каршында Бриллиант Абдрахманова җитәкчелегендә эшләүче «Ак калфак» оешмасы алтынчы тапкыр 107 нче балалар бакчасында «Татар кызчыгы-2023», «Татар малае-2023» бәйгесе уздырды. Һәр бала бик күп бүләкләр белән бүләкләнде, һәр гаиләгә рәхмәт хатлары тапшырылды. 3 кыз, һәм бер малай 8 апрельдә узачак республикакүләм бәйгедә катнашачак.

● 1 апрельдә Ижау шәһәренең Габдулла Тукай исемендәге 6 нчы татар гимназиясе Удмурт дәүләт университетының тел һәм әдәбият институты белән берлектә 15 нче тапкыр «Тел һәм мәдәниятләрнең заманча палитрасы: яшьләр карашы» дигән төбәкара фәнни-гамәли конференция үткәрде. Удмуртия һәм Татарстан укучылары үзләренең эшләрен тәкъдим итте. Конференциядә татар теленддә чыгышлар булуы да сөенечле.

● Ижау шәһәрендә «СССР музее» ачылды. Музей булдыру идеясе «Сундук» антиквар кибете хуҗасы Альберт Низамовныкы. Ул совет чорындагы уникаль, сирәк очрый торган әйберләрне бер урында җыярга булган. Музейда сервизлар, төрле шкафлар, идән һәм стена келәмнәре, агач чаңгылар, лампалы телевизорлар һәм башка әйберләрне күрергә мөмкин. Мирасханә башка музейлардан интерактив булуы белән аерыла: телерадиола төймәләрен басарга, креслоларда утырырга, пионер галстукларын бәйләп карарга була. Шәһәр халкы музейга яңа экспонатлар бүләк итә башлаган инде.

● Алнаш районының мәдәният йортында Татар мәдәнияте көне узды. Бәйрәмдә Алнаш районы хакимиятенең мәдәният идарәсе начальнигы Наталья Антонова, Удмуртия татарларының милли-мәдәни автономиясе рәисе, «Яңарыш» газетасы редакторы Рәмзия Габбасова, «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Бриллиант Абдрахманова катнаштылар. Сәхнәдә татарча, русча җырлар яңгырады, төрле биюләр башкарылды.

«Яңарыш» газетасы.

ӘСӘЙ АВЫЛЫ

(Башы 12 нче санда).

Имана җире булмаган хуҗалыклар да шактый. Болар башлыча яшь хуҗалыклар. Андыйларның бер өлеше җирне арендага алса, икенчеләре көнлекчеләр булып ялланган. Киресенчә, имана җирен арендага биреп, үзләре исә башка кешеләргә көнлекче булып эшләүчеләр дә булган.

1907 елда Әсәй халкы тагын бер мәчет салырга рөхсәт ала. Әлеге 207 ир-ат һәм 192 хатын-кыздан торган өченче мәхәлләдә имам-хатыйп һәм мөгаллим булып Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтзарипов (1881 елгы) сайлана. Мөәзин хезмәтен Мөхәммәтәмин Габдерәхимов (1869) башкара.

Бу чорда беренче мәхәлләдә имам-хатыйп һәм мөгаллим булып Әхмәтша Әхмәтҗанов (1883 елдан) белән Мөхәммәтгәрәй Мөхәммәтсадыйковлар (1882) хезмәт итә. Мөәзинлеккә 1902 елда Мөхәммәтхафиз Мөхәммәтшәрипов килә.

Икенче мәхәлләдә Мәхмүт Шәрәфетдинов (имам-хатыйп һәм мөгаллим, 1874 елдан) һәм Фазлыәхмәт Шаһимөхәммәтовларны (имам һәм мөгаллим, 1902 елдан) күрәбез (БР МА, И-295 фонд, 14 тасв., 11 сакл. бер.).

Истәлекләргә караганда, әлеге мәчетне Габдерәхим хаҗи Габделкәримов салдырган. Мәчетләр каршында 3 мәктәп эшли. Беренче һәм икенче мәчеттә укыту иске методта (ысулы кадим), ә өченче мәчеттә яңа методта (ысулы җәдид) алып барыла. Яңача укытуны Чупайдан (хәзерге Минзәлә районы авылы) килгән Габделхәй исемле укытучы башлап җибәрә. Ул телгә кешеләрне русча да өйрәткән, кайбер дөньяви фәннәр белән таныштырган, үзе бик гыйлемле булган. Авылда аның, шәкертләре белән мәчет манарасына менеп, «Туган тел»не җырлавын әле дә искә алалар. Әсәйдән ул 1915-1916 еллар тирәсендә китә. Аннары Казанда яши, хәрби чинда була (бу хакта Габделхәй укытучының язмышы белән кызыксынган Гариф Әхмәдиев сөйләде).

Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан мәчетләрдә кайбер үзгәрешләр була. Мәхмүт Шәрәфетдинов муллалыктан китә, аның урынына имам-хатыйп һәм мөдәррис итеп 1914 елның февралендә Ризаэтдин Мәхмүтов (1886 елгы) раслана. Өченче мәхәллә мулласы Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтзарипов 1912 елны дөнья куя, имам-хатыйп һәм мөдәррис итеп Мөхәммәтшаһит Мөхәммәтзарип улы Батыршин сайлана.

1916 елда Бөгелмә өязендә хуҗалыклар исәбен алалар. Әсәйдә 359 хуҗалык, 746 ир-ат һәм 962 хатын-кыз теркәлә. Беренче бөтендөнья сугышы тәмамланмаган, шуңа күрә ир-атлар хатын-кызларга караганда күпкә аз була. Бу сугышта авылның шактый ир-аты катнаша. Сугыш башлангач, Азнакай волостенда качаклар күренә башлый. Алар Сәпәй (2 кеше), Уразай (10), Азнакай (15), Балтач (4), Әгерҗе (3) һәм Әсәй (3) авылларына килеп утыра. Әсәйдә 3 качакның берсе – ир-ат.

Авыр сугыш елларында да авыл халкы күп мал-туар асраган. Әсәйдә барлыгы 752 ат, шул исәптән 587 эш аты, 884 мөгезле эре терлек, 1652 сарык һәм 533 кәҗә була (ТР ДА, 993фонд, 1 тасв., 38 сакл. бер.). Билгеле, хуҗалыкларга карап мал-туар саны нык аерылган. Бигрәк тә гаилә башлыклары сугышка киткән хуҗалыкларга авыр була. Аларның мал-туары һәм чәчүлек җирләре азая.

Нинди генә авырлыклар булмасын, халык дин таләпләрен тайпылышсыз үтәп барган. Дүртенче мәхәллә булдыру мәсьәләсен сугыш елларында күтәреп чыгу – моның ачык мисалы. Самара губерна идарәсе яңа мәчет салырга рөхсәтне 1916 елның 29 апрелендә бирә. Шактый гына төзелеш эшләре башкарылып ятканда, хакимият алышына, гражданнар сугышы башлана. Шул сәбәпле эшләр ярты юлда туктап кала, имам сайлау да кичектерелә. 1918 елны гына әлеге вазыйфага Хәмзә Әхмәтшин раслана. Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Хәмзә мулла Митрәйдән күчеп килгән. Бу мәхәлләдә Заһидулла Мотыйгуллин мөәзин хезмәтен башкарган.

Беренче бөтендөнья сугышы бетеп, Россиядә хакимияткә большевиклар килгәч, 1918 елда авылда ярлылар комитеты төзелә. Комитетның беренче рәисе булып Зарип Садыйков эшли, сәркәтип итеп Пашков фамилияле рус кешесе китерелә.

Бу чорда авыл башкарма комитеты да оештырыла. Беренче авыл комиссары Фәррахетдин Шәрифуллин була. Комитет әгъзалары булып Габделгазиз Бәдигов, Миңлезакир Хәсәншиннар тора.

Гражданнар сугышы чорында авыл аша акларның һәм кызылларның отрядлары үтә. Әмма бу тирәдә зур сугыш хәрәкәтләре булмый.

1920 елның кышында продотрядлардан аеруча җәфа чиккән авыллар «сәнәклеләр» фетнәсенә кушыла. Әлеге отрядлар Әсәйдән дә олау-олау икмәк ташый, бик күп кешеләр запассыз кала. Менә шул запас булмау аркасында 1921 елда авылда күп кеше ачтан үләчәк. Продотрядлар Әсәй кешеләрендә зур ачу тудырса да, ни сәбәпледер, восстаниегә кушылучылар булмый.

Баш күтәрүчеләр тирә-як авылларда продотрядларга ярдәм күрсәткән коммунистларны һәм активистларны эзәрлекли. Яңача укыткан хәлфәләргә дә аларның беркадәр ачуы була. Шуныктан Әсәйдә Шәет хәлфәне «сәнәклеләрдән» саклап калу өчен Митрәйгә озаталар. Шуннан соң аның турында хәбәр булмый.

Башка авыллар кебек, 1921 елгы ачлыкны Әсәй дә авыр кичерә. Кешеләр агач кайрысы һәм тамыры, үлән ашый, иске тиреләрне пешереп карый. Әмма болар гына ач үлемнән коткара алмый, күпләр кырыла.

Билгеле булганча, Америка хөкүмәте, Герберт Гувер җитәкчелегендә, Россиянең ачлыктан интегүчеләренә булышлык оештыра. Америка ярдәме Әсәйгә дә килеп җитә. Ашханә ачып, авылда бушлай ашатулар оештырыла. Күп кешеләргә ул ярдәмнән өлеш чыгарыла. Әмма ашханә озак эшләми, кешеләр ачлык белән бергә-бер кала. Нәтиҗәдә, ачтан үлүчеләр саны тагын да арта башлый.

Беренче бөтендөнья, аннан гражданнар сугышы һәм 1921 елгы ачлык авылның социаль-экономик үсешенә гаять тискәре йогынты ясый. Күп кенә хуҗалыклар таркала, халык саны кими.

1921 елда авылдан берничә хуҗалык яңа урынга күчеп утыра – Таллы Бүләк поселогы барлыкка килә. 1922 елның көзендә поселок халкы мәчет салырга рөхсәт ала. Имам итеп Харис Хәйрелислам улы Сәйфуллин раслана.

1926 елда Россия буенча халык санын алу үткәргәндә, Әсәйдә нибары 1236 кеше исәпләнә (1916 елда 1708 кеше иде). Бу күрсәткеч буенча ул Азнакай волостенда дүртенче урында тора.

Егерменче елларның беренче яртысы авылга шактый яңалыклар алып килә. Шуларның икесенә аерым тукталып үтик. 1922 елның язында авылда элек эшләп килгән мәктәп бетерелеп, аның урынына совет мәктәбе ачыла. Беренче укытучылар – Сөнәгать Хәйруллин һәм Гамилә исемле хатын-кыз (фамилиясе билгесез). Укучылар күбәйгәч, 1934 елдан уку ике сменада оештырыла. Бишенче-җиденче классларга Уразай, Митрәй, Урманай, Карамалы, Көчле Бүләк, Галимовка, Маратовка, Октябрь Бүләге, Таллы Бүләк авылларыннан килеп укыйлар. Ул чорда мәктәпнең директоры булып Мөнир Садриев эшли.

● Истәлек тактасы ачу тантанасыннан. Әсәй мәдәният йортының ВК төркеменнән.

Икенче зур яңалык – авылда кулланучылар кооперациясе оештырылу (1924 ел). Аны оештыруда Садри Насрыев актив катнаша һәм кооперациянең беренче рәисе итеп сайлана; бухгалтеры булып Иван Панин эшли. Кооперациягә керү взносы – 50 тиен, пай взносы – 2 сум 50 тиен була. Шул акча исәбенә авылда таштан кибет салына. Товарны Бөгелмәдән алып кайтканнар.

Башка авыллардагы кебек, Совет законы нигезендә 1920 елларда Әсәйдә дә мәхәлләләр теркәлү үтә. Авылда 1917 елга чаклы өч мәхәллә булса, хәзер аларның саны дүрткә җитә.

Беренче һәм икенче мәхәллә муллалары һәм мөәзиннәре хакында 1900 елгы мәгълүматларга таянып әйткән идек. Совет чорында аларның исән булганнары (беренче мәхәлләдә Әхмәтша хәзрәт) вазыйфаларын башкаруны дәвам итә. Беренче мәхәлләдә тагын Гәрәй хәзрәт, ә совет чорында Бәйрәкәдән күчеп килгән Хәсәнҗан Әхмәтҗанов та мулла булып тора.

(Дәвамы киләсе санда).

Таһир КӘРИМОВ,
тарих фәннәре кандидаты.

Айдар ХӘЛИМ:
«Соңга калмыйк, татарым!»

(Ахыры. Башы 12 нче санда).

– Бу уңайдан, Татарстан Дәүләт Советы депутатларына да теләк-дәгъва бар. Туган телебезне үстерү, аның абруен күтәрү белән бәйле законнар үз вакытында кабул ителсен иде. Сүзем дистә еллар элек ахырына җиткерелмәгән бик мөһим документ – югары дәүләт вазыйфаларына дәгъва итүче башка милләт вәкилләренең татар телен белгән очракта гына сайлану хокукына ия булуларын раслаучы закон турында.

– Чыннан да, ул вакытта депутатлар эшләрен ахыргача җиткермәде. Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы законны раслаганда, әлеге документ та кабул ителгән булса, туган телебез, милләтебез бүгенге хәленә төшмәгән дә булыр иде. Республика парламентында да татар җанлы депутатлар күбрәк килер, туган телебезне әледән-әле кыркып торган федераль законнарга да киртә куелыр иде. Иң аянычы, югары дәүләт вазыйфаларына татар телен белмәгән кешеләрне кую, бу хакта закон кабул итмәү татарны милләт буларак кимсетүгә, бетерүгә туры юл ача. Татарстан парламенты кичекмәстән әлеге документны кабул итәргә тиеш. Сүз туган телебезнең, милләтебезнең абруе хакында бара.

– Татар теленең, татар милләтенең язмышын хәл итүдә, милли рухны, милли үзаңны үстерүдә 300 дән артык язучы-шагыйрьләрне берләштергән Язучылар берлегенең роленә дә тукталыйк. Уйлап баксаң, бу – бик зур көч. Иҗат әһелләренең һәркайсының әйтер сүзе, язган әсәрләре бар. Айдар абый, шәхсән, сезнең өчен сәяси өлгергәнлек үрнәге итеп куярлык язучылар, шагыйрьләр кемнәр алар?

– Җавабым бәлки берaз кискенрәк тоелыр, ләкин бу – минем фикер. Татар язмышын хәл итүдә бүгенге Язучылар берлегенең роле әлегә артык тыйнак. Күпчелек әдипләр халыкның башыннан сыйпап, җаена гына торып яза. Бөтен өмет кыю фикерле, үз сүзен әйтә белүче яңа җитәкчедә! Минем өчен сәяси яктан өлгергән язучы ул бер генә – Фәүзия Бәйрәмова һәм ниндидер кушымта ясап, Рабит Батулланы, шулай ук Ркаил Зәйдулланы, Вахит Имамовны кертергә була. Ялгышуым да мөмкин, бәлки бүтәннәр дә бардыр. Ләкин турыдан-туры үзен милләткә багышлаган язучыларны күрсәтүе кыен.

Язучыны язучы итми торган бер искиткеч сәбәп бар. Ул да булса, сүз белән гамәл аерымлыгы. Кызганычка, язучы – еш кына мескен кеше. Иҗатчыдыр ул, бәлки, әмма көрәшче шәхес түгел. Әлеге сыйфатлар, нигездә, бер-берсенә каршы хәрәкәт итә. Язучыларның күпчелеге бүген чын әсәр язу турында түгел, ә китап чыгару, ничек тә булса, Язучылар берлегенә әгъза булып керү турында кайгырта һәм шуңа хезмәт итә.

Гомумән, хәзер язучы булуның кызыгы юк. Чөнки күпчелек язучы җөмлә төзи, сөйләм төзи белми. Соңгы елларда берлек чыгарган кайбер әсәрләрне укый китсәң, анда таң калырлык чатаклыклар тулып ята. Мин уйлыйм, Тукай, Исхакыйларның таләпмыскалы белән үлчәсәң, 350 язучыдан 15-20 гә тула микән? Ә бит Язучылар берлегенә үткән һәр язучының әсәре татар теленең иң камил үрнәге булырга тиеш. Стильләр төрле, ә теле һәрвакыт камил булсын. Шундый таләп куелырга: һәр әсәр жанр таләбенә дә җавап бирергә һәм иң нечкә иләктән дә үтәргә тиеш.

А.Хәлимне гомер бәйрәме белән Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Шакиров котлый.

Татарда атадан яшь калдым, акылдан буш калдым, дигән мәкаль бар. Без шундый булып калдык. Язучылар берлегенең иң алдынгы фикерле, иң акыллы өлеше репрессия чорында һәм Бөек Ватан сугышында күпләп кырылды. 1930-2000 еллар арасында зур көрәшче язучыларның дүртесен генә күрсәтә алам: Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким һәм Салих Баттал. Ә классик мисаллар, шәхсән минем өчен, Такташ, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан исемнәрендә туктала һәм ябыла. Бүген минем күзлектән караганда, берән-сәрән балкып кына алган әсәрләрдән тыш, чын татар прозасы да, татар шигърияте дә, татар драматургиясе дә юк.

– Туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләүдә театр әһелләренең, вакытлы матбугат, телевидение, радио хезмәткәрләренең җаваплылыгын арттырасы иде. Техник бизәлеше югары сыйфатлы булу белән бергә, сәхнәгә куелган һәр әсәр, матбугатта басылган һәр язма, эфирга чыккан һәр тапшыру туган телебезнең бөтен матурлыгын, камиллеген, байлыгын ачып бирергә, горурлык уятырга тиеш. Һәркем Г.Камал театры дәрәҗәсенә тиңләшсен иде.

– Ә минем фикер башкачарак. Чын татар театры булу өчен, Г.Камал театрына халкыбызның тарихын тирәнтен өйрәнеп сәхнәләштерү җитми. Үз халкының ачы язмышын, Казанның бирелүен, алты айлык баладан башлап ак сакаллы картларга кадәр кырылган трагедиясен, Батырша, Сөембикә күз яшьләрен сәхнәдән күрсәтми торып, татарда театр бар, дип әйтә алмыйбыз. Әнә шул югарылыкка омтылырга кирәк. Татар милләтен йокысыннан уяту өчен әнә шундый театр, шундый драматургия, шундый трагедия кирәк. Бүгенге театр ул – татарның «Әниләр һәм бәбиләр», «Диләфрүзгә дүрт кияү» театры. Сүз дә юк, андый темалар да булсын. Тик зыялы татар тамашачысы бүген тетрәндереп, айнытып җибәрә торган тарихи сәхнә әсәре көтә.

Бүген бездә чын татар телевидениесе дә юк. Ә бит бу өлкәдә тупланган тәҗрибә җитәрлек. 2001-2010 елларда Рахман Шәфигуллин җитәкләгән «Чаллы-ТВ» каналында исемнәре җырлап торган 20 дән артык тапшыру саф татар телендә чыгып килде. Шундый яратып, көтеп алып карый идек. Ник берсе дә калмады? Журналистларга сорау бирсәң, тапшыруны чыгарырга акча кирәк, иганәче таба алмыйбыз, диләр. Ничек инде, татар телевидениесе иганәче кулына карап акча теләнүгә калдымыни? Шундый мөнәсәбәт белән ничек итеп татар телен кайтарасың?!

Гомумән, татар тапшыруларының элекке абруен кайтарырга телибез икән, ул ялтыравык кәгазьгә төрелгән, ни тәме, ни сыйфаты булмаган «сый» булырга тиеш түгел. Татар тормышын, татар тарихын, татар язмышын 30 ел инде татарчага тәрҗемә ителгән һинд, төрек сериалларына алыштырдык. Төрек хатыныныӊ хәсрәтле язмышы өчен татар әбисе күз яшен коеп карап утыра. Адәм гарьлеге бит! Татар кайгысы, татар сагышы, әйтерсең лә бөтенләй юк. Әнә шул көн саен, адым саен алдау-йолдаудан арынсын иде татар телевидениесе!

Беренче урында, әлбәттә, сыйфат, эчтәлек, жанрлар төрлелеге һәм милли рух. Таләп нәкъ театрдагы кебек: комедия дә, драма да, трагедия дә күрсәтелсен. Саф татар телендәге яңалыклар сәгать саен яңарып торсын. Тик кайда яңгыр яуган, янгын чыкканын, ягъни гадәттән тыш хәлләрне түгел, ә ачыктан-ачык бөтен дөньякүләм соңгы хәбәрләрне җиткерсен. Телевидение кешенең аңын, фикерләү дәрәҗәсен үстерергә тиеш. «Тиле шоу»лар урынына татар спектакльләре һәрдаим программага куелып торса, халык рәхәтләнеп караячак. Бөтен кешенең дә, бигрәк тә авыл кешесенең театрга йөрү мөмкинлеге юк бит.

Ял көннәрендә генә түгел, көндәлек тапшыруларда да татар прозасын, татар шигъриятен, татар юморын, татар сатирасын ишетәсе, карыйсы килә. Әлбәттә, һәр әсәр югары сыйфатлы, камил сөйләм теленә ия булганда гына, ул татар күңелен кузгата, уйландыра, моңландыра, горурлык хисләре уята ала. Әнә шундый сыйфатка, шундый югарылыкка ирешү турында уйларга кирәк. Чөнки заман каләбендә – татар теле, татар милләте язмышы.

Үзебезнең татар фильмнарына да юл ачарга кирәк. 2005 елдан бирле Мөселман киносы халыкара фестивале Казанда үтә. Тик татарны кинолы итү өчен әлегә бернинди дә тырышлык күренми. 17 ел дәвамында нибары ике фильм («Мулла», «Үксезләр») жюриның югары бәясенә лаек булды. Ник үстермибез татар киносын? Кая безнең кино төшерүче продюсерларыбыз, режиссерларыбыз, операторларыбыз? Рамил Фазлыев белән Нурания Җамалиевадан тыш татар киносын кайгыртучы юкмыни?!

– Соңгы елларда чит җирләрдә таралып яшәүче татарларны бер йодрык итеп туплау максатында, хәтта чит илләргә барып милли Сабантуйлар үткәрү күркәм гадәткә керде. Бу нисбәттән фикерегез?

– Татар телен үстерү һәм саклау комиссиясенең шактый ук өлгерлек белән эшкә алынуы һәр татарда, киләчәккә өмет уята, әлбәттә. Ә менә каядыр, Бразилиягә барып, ике татар өчен Сабан туе күрсәтеп, читләрне ашатып-эчертеп кайтуны авыл кешесе һич кирәк булмаган гамәлгә саный. Бөтендөнья татар конгрессының милли мәҗлесе фондында акча шулай күп икән, татар авылына булышсын, диләр. Бәлки бу теләккә дә колак салыргадыр. Милләтебезнең, телебезнең бишеген элек-электән татар авылы тибрәтә бит!

Ә татар Сабантуйлары, беренче чиратта, татар җирендә чын татарча үтәргә тиеш. Элекке җыеннар кебек. Халыкта милләтнең киләчәгенә тагын бер ышаныч артачак. 2023-2033 елларны туган телебезнең үсешен, милләтнең чәчәк атуын күрсәтүче татар уңышлыгы итеп үткәрәсе иде.

– Айдар абый, татарның үз язмышын кулына алуына ышанасызмы?

– Әлбәттә, ышанам. Килер бер көн, татарым үз бөеклеге белән горурланып, иңнәрен турайтып торып басачак. Берсеннән-берсе асыл гамәлләре белән Җир йөзендәге иң зыялы, иң мәгърифәтле, иң горур милләт икәнен раслаячак. Ә бүген йокысыннан айнып, көрәш мәйданына чыгу юлын эзләүче милләттәшемә әйтер сүзем: «Соңга калмыйк, татарым!»

– Айдар абый, әңгәмәгез өчен зур рәхмәт!

Әңгәмәдәш – Рәзинә НАСЫЙБУЛЛИНА.

Исхакый тәхәллүсләре

Гаяз Исхакый 1919 елдан Ватаныннан чыгып киткәннән соң ун елга якын үз матбагасын булдыру турында хыялланып яшәгән, язган мәкаләләрен җыеп барган. 1928 елның декабрендә чыга башлаган «Милли юл»га аның язмалары ишелеп керә. 1929 елда мәҗмуга ике атнага бер чыга (калган елларда аена бер мәртәбә басыла). Һәр санда Исхакыйның төрле темаларга язган берничә зур мәкаләсе урын ала. Ватанында калган туганнары, якыннары хәленнән бихәбәр булып яшәсә дә, әдип илдәге көндәлек вәзгыятьне белеп торган. «Прометей» оешмасы килгән газета-журналлар белән танышып, андагы язмаларга үз фикерен белдереп барган. Үз исеме белән һәм төрле тәхәллүсләр белән язган мәкаләләреннән тыш, ул «Кырым хәбәрләре», «Төркстан хәбәрләре», «Идел-Урал хәбәрләре» дигән язмалары белән мөһаҗирләрне илдәге хәлләр белән таныштырып торган.

Исхакый биредә укучыларга тәкъдим ителә торган мәкаләләренең берсенә бертуган энесе Әхмәтхәсән улының исемен куйса (Илтөзәр – Ил төзәр), икенчесенә исә тәхәллүс итеп Алтын Урда ханы Бәркә (1209-1266) исемен ала.

Лена ГАЙНАНОВА.

ИКЕ ИХТИЛЯЛ

Зур дөнья сугышы нәтиҗәсендә 1917 нче елда Русиядә вә 1918 дә Германиядә ихтиляллар (революцияләр) булды. Һәр икесенең дә патшалары төшерелде вә һәр ике дәүләттә дә бюрократия нигезендәге сәяси корылыш җимерелеп, җөмһүриятләр ясалды. Бу күрше мәмләкәтләрнең икесендә дә ихтилялның башлануы вә китеше бер төсле кебек иде: һәр икесендә дә эшчеләр вә солдатлар шурасы төзелеп, идарә машинасы коммунистлар кулына кергән иде. Ләкин Германиянең көчле вә иттифаклы (бердәм) социаль-демократлары коммунист «Спартак»ларны бик тиз бастырды. Аларның башлыкары булган Либкнехт берлә яһүди кызы Роза Люксембургны 1919 елның 15 гыйнварындагы урам сугышларында үтереп, коммунист хәрәкәтен туктаткач, Германияне халыкчылык вә демократия нигезендә корырга керештеләр. Шулай итеп, Германиянең ихтилялы бер ел эчендә тәмам булган булса ла, Русиядәге ихтилял унбер ел буена әле дә дәвам итәдер. Шул сәбәпле, сугыш аркасында мали (финанс) вә икътисади эшләре юлдан чыгып беткән Германия, бу көн сугышка кадәрле вәзгыятен алып бара. Халкы тук, эшчеләре тырыш, мали эшләре тәртипкә салынган, сәяси тормыш демократизм нигезендә корылган, мәмләкәтне идарә итү эшенә бөтен халкы катнаша, хөкемсез һичбер кешене ату вә үтерү түгел, япмыйлар да, сүз сөйләүдә, язуда, җәмгыятьләр төзү вә җыеналуда чын мәгънәсе берлә иркенчелек бар. Хәтта мәмләкәтнең хәзерге корылышы вә хөкүмәтенә бөтенләй каршы булган нимес коммунистлары да хөррият берлә файдалана. Гәзитәләрен чыгаралар, җәмгыятьләрен ясыйлар, фиркаләре башка сәяси фиркаләр кебек үк хәрәкәт итәдер.

Русиядә исә халык ач вә ялангач, икътисади тормыш эштән чыккан, акчасы көннән көн төшә, хөрриятнең исеме дә юк. Һичбер кеше үз фикерен сөйли вә яза алмый. Туры хөкем юк, һич тә гаебе булмаган кешеләр берлә төрмәләре тулган. Һич гаепсез кешеләрне чекада вә гөпуда хөкемсез атып үтереп торалар. Русиядә унбер ел буенча кан түгелә, күз яше агызыла, халык кырыла вә фәкыйрьләнә вә бу хәлләрнең кайчан вә ни рәвештә бетәчәге дә мәгълүм түгелдер.

Хәлбуки Германиядә тормыш тынычлык берлә корылган вә халкы умарта корты кебек бертуктаусыз эшләп, мәдәнияткә вә инсаниятә хезмәт итә. Менә ике күрше халык вә мәмләкәт арасында нинди зур аерма бар. Чөнки Германия халкы мәдәнияттә Русия халкы берлә һич тиңләштермәслек дәрәҗәдә өстен булганга күрә, ихтилял дигән нәрсәнең иҗтимагый бер хасталык булганын бик яхшы белә. Шул сәбәпле ул хасталыктан тиз котылырга тырышты вә котылды да. Хәзер ул саусәламәт кеше кебек эш эшли.

Германиядә икътисади тормыш бик күтәренке. Миллионнарча аңлы, укыган вә төпле җәмгыятьләр корып берләшкән эшчеләре бар. Ул эшчеләрнең юлбашчылары гаять зур дәрәҗәдә куәтле вә мәгълүматлы социал-демократ фиркаседер. Кайсы яктан гына Русия берлә чагыштырып караганда да Маркснең фикере буенча: социализм корыр өчен Германия Русиядән мең мәртәбә артык вә зәмин (җирлек, нигез) хәзерләнгәндер. Ләкин нимесләр, бу көн мәйданга чыгуы мөмкин булмаган коммунизм кебек хыял – утопия берлә халыкны ялганлап маташмыйча, мәмләкәтләрен хәзер ясалу мөмкин булган икътисади вә сәяси нигездә генә кордылар. Тегеләй дә, Русиядәге надан вә кара халыкны, коммунизм корабыз вә дөньяда тигезлек ясыймыз дип алдап булса да, Германиянең акыллы вә мәдәни халкын болай алдарга мөмкинме соң? Әлбәттә, мөмкин түгел! Буның мөмкин булмаганлыгын хәзер рус большевиклары үзләре дә бик яхшы беләләр. Бу коммунизм фикере буенча фанатик нәтиҗәдә коммунизм корылачак иде. Ләкин Ленин уйлаганча дөньяның бер җирендә дә ихтилял чыкмады вә булачагы да юктыр. Хәзерге большевиклар буны бик яхшы белсә дә, һаман да бөтен дөньяда коммунизм ясыймыз дигән булып, надан вә кара халыкны алдап, шул фәкыйрь халыкның миллионнарча акчасын тотып, дөньяның һәр тарафына төрле яһүди малайларын агент итеп җибәреп торалар. Чөнки большевиклар коммунизм корамыз дип дәүләт идарәсен кулларына алды. Хәзер коммунизмның мәйданга чыгуына үзләре дә ышанмасалар да, хакимиятне кулдан ычкындырмас өчен эш күрсәтергә кирәк. Зур идеал өчен хезмәт иткән булып күренергә тырышалар. Иске патшалар да шулай итә иде. Ягъни надан халыкның күзен буярга тырышалар иде. Алар, дин исеменнән хәрәкәт итеп, үзләренең инанмаган эшләрен эшләп килә иде. Надан вә кара халыкның башына кем генә килсә дә, шулай теләсә ни кылып вә шул халыкны теләсә ни кыландырып тора. Менә Русия ихтилялының вә бу иҗтимагый хасталыкның унбер ел буена озаеп китүенең сәбәбе – Русиядәге халыкның наданлыгыдыр. Алар бу хасталыкны күп чигеп азаплар күргәч кенә котылачаклар. Соңга калып булса да терелеп эшкә тотыначаклар. Ул вакыт инде ерак түгел. Большевизмның бетү көннәре бик якындыр!..

Ил төзәр.
«Милли юл» 1929, №3,
9-10 битләр.

ХӘЕРЛЕ ЗОЛЫМ

Тарихның безгә күрсәткән хакыйкатьләреннән иң кыйбатлысы – мәзлүм халыкларның иң соңында, үзләренә золым иткәннәрне түбәләп, үз ирекләренә кавышуыдыр. Золымның иң зурысы, бер милләтнең ирек вә истикъляленең (бәйсезлегенең) башка бер милләт тарафыннан көчләнеп алынуы вә йөз елларча тоткын милләтнең изелеп яшәвеедер. Ләкин тоткын булган милләтнең бу золымнан котылуы өчен үзенең изелгәнен сизүе тиештер. Чөнки көчләнүчеләрнең мондый тоткын халыкларны изүе ике төрле буладыр. Авырттырып, әрнетеп изү яисә оештырып вә йоклатып изү. Беренче төрле изелгән милләтләр, тизрәк уянып, бөтен халкы вә бала-чагасына чаклы һәммәсе дә изелгәнлекләрен сизгәнгә күрә, дошманнарын аңлап, чиккән азапларыннан котылу чараларын эзләргә тотыналар. Шул вакытларда ул мәзлүм халыкның юлбашчылары вә милли байракларын күрсәтеп алдан баручылары булса, ул азап чиккән тоткын халык, нинди генә надан вә кара җаһил булса да, үзенең юлбашчыларына иярәчәк вә ирек маяклары кагылган юлдан йөреп, истикъләл кояшы нурын чәчкән милли байрак тирәсенә җыйналачактыр. Әгәр изелү икенче төрле – оештырып вә йоклатып булса, ул вакыт золымның кулыннан котылу шактый авыр бер мәсьәләдер. Чөнки ул изелештә халык укытылмаган вә надан булган кебек, аларның дин вә тәгассыб тамырларына бер дә тиюче булмаганга, ул халыкка үзләренең изелгәнлеген аңлату бик читендер. Бер көнлек азык берлә тамагы тук, дога вә намазы берлә җаны тыныч булган мондый халыкларга ирек вә истикъләлнең мәгънәсен аңлату бик авырдыр. Үзенчә рәхәт яшәгән бер халыкны ирек-истикъләл сугышына кертү мөмкин түгелдер. Бу милләтнең аңлау кодрәте туганга чикле йөз еллар буенча тоткын яшәве бик мөмкиндер. Көнбатыш вә Яурупа милләтләренең бик күп Көнчыгыш халыкларын кул асларында тоткын яшәтүләренең бөтен хикмәте – көнбатышларның көнчыгышларны оештырып вә йоклатып изүләрендәдер. Инде бөтен дөньяга бер уяну дәвере күргән бу соңгы йөз ел – көнчыгышлыларның уяну вә күтәрелү дәвередер дисәк тә ярый. Бу уяныш башлаганнан соң йоклатып изүнең дә файдасы булмаячактыр. Чөнки йөз еллар буенча йоклап уянган бер милләт артык бик җиңел генә йокламас. Тоткын мизләтләрнең маңгай тире берлә кесәләренә алтын-көмеш тутырып вә хәзер икмәк берлә карын туйдырып, рәхәт гомер итәргә өйрәнгәч, көчләүчеләр, бу зәхмәтсез байлыкны кулдан җибәрмәс өчен, тоткыннарны авырттырып изәргә дә башлаячаклар. Менә бу соңгы изеш ул тоткын милләтләр өчен хәерле бер золымдыр. Чөнки бу золым ул милләтне иркенә кавыштырачактыр. Менә без, Идел-Урал өлкәсе төрек татарлары да, 376 елдан бирле Русия кул астында вә рус итеге астында изелеп килмәбез. Буның беренче йөз елы бик ачы бер изелеш булса да, ул вакыт безнең хәлдән таеп, исәнгерәп яткан чагыбыз булганга, кузгалуыбыз мөмкин түгел иде. Соңгы 250 елы – айның алмый, ярты йокы вә ярты һушсызлык берлә изелгән елларымыздыр. Иң соңгы 26 елның унбишендә шул йокы вә хушсызлыктан селкенеп уянган вә аякка баскан идек. Юлбашчыларымыз иректә тормышка юл ачарга башлаган гына иде. Әледә байрак күтәреп якты истикъләл юлына таба йөрергә өлгермәгән идек, зур сугыш башланды вә аннан соң большевиклар килеп чыкты. Бөтен халкымызның балалыгыннан бирле ишеткән дини хикәяләрдән «Дәҗҗал мәлгун» акиятләрен әле дә онытмадык. Дәҗҗалның җәннәт дип күрсәткәне тәмугъ була икән, диләр иде. Менә бөтен дөньяны җәннәт ясарга дип идарәне кулларына алган большевиклар, бөтен Русияне зур бер тәмугъ ясаганнары кебек, чыннан да оҗмах шикелле булган Идел-Урал өлкәмезне дә җәһәннәмгә чәвердәләр (әйләндерделәр). Аларның сүзләренә инанып вә корылган милли идарәмезгә хыянәт итеп, йортилемезне большевикка тапшырган ахмак егетләремез бу көн сөекле халкымызны Дәҗҗал мәлгуненең утына салдылар. Инде үзләре дә чатырдап яналар. Үзләре янсын вә янарга тиешләр дә, ләкин бичара халкымыз бик кызганыч!

Шулай да булса, халкымызның бу соңгы чиккән азапларына карап, нурлы өметләргә дә төшәргә вакыт җитте. Чөнки большевикның бу соңгы авырттырып изүе, иншалла, милләтемез өчен хәерле золым булсын! Чөнки хәзер юлбашчыларымыз, иректә вә мөстәкыйль Идел-Урал өлкәсе өчен хөррият кояшы кебек балкып чыккан истикъләл байрагымызны күтәргәннәр. Бик якында «Милли юл»ның укучылары нурлы вә мөбарәк байрагымызның үрнәген күрәчәкләр. Бу байракны күргәннәр, әлбәттә, аның тирәсенә җыйналачаклар. Яшәсен хәерле золым!..

Бәркә.
«Милли юл», 1929 ел, №3,
10-12 битләр.

Шигъриятнең олы юлында

Нинди сихри музыка! –
Кузгата ул хәтер катламнарын,
Үткәннәргә бүгенгене ялгый,
Киләчәкнең тоям атлауларын...
(«Бу гаҗәеп музыка!»)

Танылган шагыйрь Наил Касыймның бу юлларында моң турында бик дөрес әйтелгән. Чыннан да, моңның сихри үзенчәлеге бар: ул хәтер катламнарын кузгатып, үткәннәргә бүгенгене ялгый ала. Олуг шагыйрьләребезнең иҗаты белән хәзерге буын шагыйрьләребезнең иҗатын бәйләп торучы уртак сыйфат та – моң! Чын шигърият моңсыз була алмый. Бу шигъри юлларда халык күңелендә мактаулы урын алган олуг затларны ихлас сагыну да һәм киләчәккә өмет белән карау да чагыла. Наил Касыйм үзе дә шигърияттә бөек элгәрләре сузган мәртәбәле олы юлны лаеклы рәвештә дәвам итә.

Тар булмаган күңел, газап чигеп,
Җирсезлектән инрәп торса да,
Саклап калган халкым Тукайларын –
Асрамага алып булса да...
(«Кырлайга кайту»)

Бу әсәрдә сүз үткән гасыр вакыйгалары турында барса да, шагыйрьнең поэтик фикерләү һәм сәнгатьчә гомумиләштерү сәләте шулкадәр көчле – шигырь, бер үк вакытта, бүгенге тормыш, хәзерге хәлләр хакында, дип тә аңлашыла. Чыннан да, гаделлеккә табынып, намуска һәм идеалга хыянәт итмичә яшәүчеләргә бүген дә бик авыр бит! Алдашып һәм хәйләли-хәйләли, ялагайлык белән, үзләренең комсыз матди ихтыяҗларын иң төп максат итеп куеп яшәүчеләр исә һаман күбәя, һаман ишәя бара. Кайчагында хәтта бөтен дөньясы әнә шундыйлар кулындадыр сыман тоелып китә... Бүгенге Тукайлар, аның юлына тугры калганнар яңадан ятимлектә, үксезлектә калган сыман... Мондый күңелсез уйларда, әлбәттә, зур гына дөреслек тә бар. Бүгенге чынлык шундыйрак. Бик кызганыч булса да...

Ләкин Наил Касыймны алга таба укыйк әле:

Ятимлеге аның – язмыштандыр,
Бөеклеге ләкин халыктан!
Тукай үзе – халкын үксезлектән
Йолып алыр өчен калыккан!

Шагыйрьнең бу юллары бүгенге чынбарлыкта ничек актуаль яңгырый! Чыннан да, сүзне туры мәгънәсендә алганда да, шагыйрьләр халыкның саклый бит.

Тукай таланты һәм көчле рухы белән төрле җирләрдә чәчелеп яшәүче халкыбызны үз шәхесе янына берләштерә алды. Аңа кадәр халкыбызда шундый рухи югарылыктагы талантлы бөек шәхес күзәтелми. Үзе ятим үскән Тукай халкын үксезлектән (ятимлектән) йолып алыр өчен калыкты. Күңелләрне тетрәндерерлек нинди олы фикер әйтеп, безнең күзләребезне ача шагыйрь. Бөек Тукаебыз турында күпме шигырьләр укысам да, аңа шундый зур дәрәҗәдәге бәһа куелган шигырь юлларын очратканым булмады.

Әнә шулай – Наил Касыйм бүген халыкны уйландырган, борчыган иң җитди темаларга яза. Һәм ул үзенең безгә җиткерергә теләгән фикерләрен матур образлы күренешләр аша, истә калырдай һәм бер үк вакытта тәэсирле итеп сурәтләп бирә... Менә бер мисал. Шагыйрь, диңгез буенда ял иткәндә, текә ярда үсеп утырган имән агачын күрә:

Ярга сикерде дулкыннар –
Янап үлем имәнгә!
Яр белән бер яралган ул –
Тамырлары тирәндә...
(«Бергәлектә – көч!»)

Күрәсезме, «яр белән бер яралган ул» дип язып, шагыйрь бөек бер гармония, олы бер ныклык, ышанычлылык, төпләлек нигезен әйтеп бирә. Бүгенге кешеләр, аеруча яшь буын өчен үтә мөһим, үтә дә кирәкле яшәү хакыйкате бу.

Халыкны саклый туган тел,
Туган тел ул – текә яр!
Халкыңа ярдәм итәрлек
Имән булып үсә ал!

Наил Касыйм үзенең чыгышы белән Тукайлар, Хәкимнәр ягыннан... Әмма моның белән һич тә мактанмый ул, ә менә бөекләр яшәешен безнең күз алдында яңарта-яңарта, тормыш өчен үтә дә мөһим булган фәлсәфи нәтиҗәләр ясый.

...Бер күренеш: өлкән яшьтәге Сибгат Хәким авырып ята... Инде әҗәл якынлашканы да сизелә... Авыр, гаять авыр минутлар... Әнә шул минутларда шагыйрьнең җәмәгате Мөршидә апа аңа Аккош күлендәге бакчаларыннан әле генә җыеп кайткан җир җиләген каптыра һәм шул минутта Сибгат ага дөнья белән хушлаша.

Үзәк өзгеч тәэсирле бу күренеш турында Наил Касыйм болай яза:

Өзелгәндә гомерең, иреннәрең
Җир җиләге килеп кызартты.
Җир җиләге булып, туган җирең
Иреннәрең үбеп озатты...
(«Кояшлы яңгыр»)

«Туган җирең иреннәрең үбеп озатты» – нинди көчле, зур образлы фикер! Бу – шагыйрьләргә бирелеп була торган иң зур бәһа. Әлеге юлларны укыгач, һәр шагыйрь дә шулай яшәргә омтылсын иде, дигән теләк уяна. Күрәсезме, биредә дә ил белән, туган җир белән һәм, әлбәттә, туган тел белән берлек, бергәлек идеясе калкып чыга. Кешенең дә, шагыйрьнең дә бәхете әнә шунда! Шагыйрьләр иҗатының халыкчан һәм озын гомерле булу сере дә әнә шул берлектә, бергәлектә!

Наил Касыйм – гаять нечкә күңелле, тирән хисле лирик шагыйрь. Шуңа күрә аның сүзләренә язылган җырларның күп булуы бер дә гаҗәп түгел. «Аның сүзләре үзләре үк җырлап тора бит», – дигән гыйбарәне нәкъ менә шушы җирдә тагын бер мәртәбә куллану бик урынлы булыр иде. Дөресе дә шулай!

Ак төсләрне әллә күп сөйгәнгә,
Чәчләрең дә бүген ак синең...
(«Ак яулыклы әнием»)

«Су буенда учак яна...» җыры исә Зөһрә Шәрифуллина башкаруында үзәкләрне өзәрдәй моңлы яңгырый. Бүген шәһәрләрдә көн күреп, туып-үскән авылларын сагынып, зарыгып яшәүчеләрнең җан авазы, җан сыкравы бигрәк тә тулы чагыла анда. Наил Касыйм үзенең:

«Тыныч сулап йоклый авыл –
Йөрим төнге урамында.
Таныш сукмак, таныш кое –
Утсыз да мин күрәм монда», –

дигән шигъри юлларында «яратам» дип бер генә сүз әйтмәсә дә, укучыга авторның туган авылына искиткеч көчле мәхәббәте ачык аңлашыла, кузаллана. Бу юллар шагыйрь каләменең образларга бай булуын тагын бер мәртәбә калку рәвештә исбатлап куя.

Нечкә күңелле шагыйрь хисләренең вулкан сыман ташып торуы күп әсәрләрендә чагыла. Ләкин биредә тагын шунысы бик мөһим – әлеге хисләрне белдерү өчен, кулга каләм алып, өстәлгә ап-ак кәгазь куйгач, сүзләр сайлаганда, таләпчән булырга да кирәк. Сүз боткасы гына килеп чыкмасын өчен! Наил Касыйм әдәби иҗат эшенә нәкъ әнә шулай – үтә дә җаваплы карый. Әнә шуңа аның шигырьләрендә халык мәкальләренә яисә афоризмнарга якын хикмәтле гыйбарәләр дә очрый: «Мәхәббәт – яратып үлү ул, яңадан туу ул дөньяга», «Җырга ия хис ялкыны, җыр ул – хиснең балкышы!», «Туй күлмәге бер көнлекме? – Туй күлмәге – гомерлек!», «Моңсыз кырлар икмәк бирмәс, кала күрмик тургайсыз!», «Колач җәеп җилдек дулкынны» һ.б. Наил Касыймның шигырь килеш үк җыр булып яңгыраган моңлы, яисә салават күпере кукне бизәгәндәй, шигъри дөньябызга ямь биреп торган әсәрләре дә, зур фәлсәфи мәгънәгә ия кыска шигырьләре дә бар.

Сәләтле каләм иясе – хаклы рәвештә халкыбызның моңлы сайрар кошы! Ул – очышта! «Канатлары талмасын!» – диясе генә кала...

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ,
язучы, тәнкыйтьче.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

8 апрель (шимбә). ***Рамазан аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 22.34 сәгатьтә калка, 6.18 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 13.36 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Миомадан дәва

1 әр чәй кашыгы дуләнә чәчәге һәм җимеше, кычыткан, эт тигәнәге, гөлҗимеш, валерьян тамыры, канлы үлән, бөтнек, сукыр кычытканны 1 литр кайнар суга салып төнәтәләр, иртәнге аш белән төшкесе арасында яки төшке аш белән кичкесе арасында яртысын, төнгелеккә калган яртысын эчәләр. Яисә кычыткан һәм меңъяфракны тигез микъдарда кушып, шунын 1 аш кашыгын 1 стакан кайнар суга салалар, төреп, 2 сәгать буе төнәтәләр, көненә 3 тапкыр, ашаганнан соң, 100 әр мл эчәләр.

9 апрель (якшәмбе). ***Рамазан аеның 18 нче көне. 19 нчы Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Чаян йолдызлыгында, 0.07 сәгатьтә калка, 6.31 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 13.40 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Солы сихәте

1 стакан солыны 1 литр салкын суга салып, төнгелеккә калдыралар, иртән кайнатып чыгарып, сүрән утта яртылаш кимегәнче пешерәләр, сөзәләр, грипп белән авырганда, шушы төнәтмәне көн буена әз-әзләп җылы килеш эчеп бетерәләр.

10 апрель (дүшәмбе). ***Рамазан аеның 19 нчы көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 1.38 сәгатьтә калка, 6.50 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 13.45 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь.

Чәч агару чир түгел

Чаларуын киметү өчен, югаңнан соң сары чәчкә ромашка, шалфей, чабыр үләннәре төнәтмәсе, ә кара чәчне колмак күркәсе, имән кайрысы, әстерхан чикләвеге яфрагы төнәтмәсе белән чайкыйлар. Чәч коелмасын өчен, баш тиресенә эре тоз ышкыйлар, 1-8 минут массажлыйлар, аннан соң юалар. Чәч ялтырап торсын өчен, 1литр суга 1 аш кашыгы лимон согы кушып чайкыйлар. Тиз майлана торган чәчне мондый кайнатма белән чайкау файдалы: 50 г әрекмән тамыры, 100 г наратбаш, 10 г ромашка, 20 г кычыткан өстенә 1 стакан су салып, сүрән утта кайнатып чыгаралар, 15 минуттан соң сөзәләр. Юар алдыннан баш тиресенә 20-40 минутка әчегән сөт сөртеп тору исә чәчне үстерә, ефәктәй йомшарта.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

11 апрель (сишәмбе). *Рамазан аеның 20 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 2.54 сәгатьтә калка, 7.23 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 13.49 сәгать.*

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Тәмле дару

Бавыр авыртканда, мондый сихәтле кайнатма хәлне җиңеләйтә. 2 алманы турап, 1 литр суда 10-15 минут кайнаталар, тәменчә шикәр һәм лимон өстәп, җылы килеш, көненә 2-3 стакан эчәләр.

12 апрель (чәршәмбе). *Рамазан аеның 21 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 8.19 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 13.54 сәгать.*

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

13 апрель (пәнҗешәмбе). *Рамазан аеның 22 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 3.47 сәгатьтә калка, 9.36 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 13.58 сәгать.*

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

Кан басымын төшерү

14 тәүлек дәвамында көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, 2 шәр аш кашыгы кара миләш согы эчәргә яки ай буе, көненә 3-4 тапкыр, 1 әр аш кашыгы балан согы эчәргә кирәк. Яисә мүк җиләген шикәр белән изеп, көненә 3 тапкыр, ашаганнан соң, 1 әр аш кашыгы кабалар.

14 апрель (җомга). *Рамазан аеның 23 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 4.15 сәгатьтә калка, 11.13 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 14.03 сәгать.*

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Чумарлы аш

1-2 бәрәңге, 2 баш суган, 1 йомырка, 2 аш кашыгы кефир яки каймак, 150г он, 100 г атланмай, тоз кирәк. 1,5-2 литр суга вак кына туралган бәрәңге салып, изелгәнче пешерәләр. Суганны вак кына турап (уылган кишер кушарга да була), атланмайда кыздырып алып, ашка кушалар. Йомырка, каймак (кефир), тоз һәм оннан чумар (клецки) камыры туглыйлар. Юеш чәй кашыгы белән әз-әзләп алып, чумарны кайнап торган бәрәңге шулпасына салалар, 8-10 минут пешерәләр. Мондый бик тиз пешә торган арзанлы аш күп итеп яшел тәмләткеч үләннәр һәм каймак салып ашаганда аеруча тәмле.

Аллаһ Тәгалә кешелеккә бүләк иткәнгә кадәр, Китабының иң камил бер хәлдә һәм гарәп теле аркылы иңдерелүен теләп, бу телдә сөйләшкән кешеләргә Коръәннең иңгәнче гасырларча элгәрерәк оста сүз (сөйләм матурлыгы), риторика (сүз матурлыгы) һәм әдәбият үсешенә мөмкинлек бирә. Гарәпләр, бу өлкәдә төрле ярышлар күрсәтеп, телләренең тагын да камилләшүен тәэмин итә һәм нәтиҗәдә бу тел, илаһ сүзе буларак бер байлыкка һәм камиллеккә ирешә.

Коръәни-Кәрим могҗизасы

Гасырларча дәвам иткән бу эш соңында гарәпләр арасында аз сүзле күп мәгънә белдерү киң таралган бер сыйфат була. Шагыйрьләр һәм нотыкчылар, җәмгыятьтә көнләшүдән күз камаштырырлык бер вазыйфа дәрәҗәсенә күтәрелә. Шул сәбәпле хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аша могҗизаларның иң зурысы, сүзләрнең иң бөек җыелмасы булган илаһи сүз, ягъни Коръәни-Кәрим килде.

Кешене башка тереклектән аерган иң мөһим вазыйфалар акыл, аң, аңлату һәм бәян булганга күрә, иң соң һәм иң камил китап булган Коръәни-Кәримнең иҗазы да акыл, бәян һәм гыйлем белән исәпләнә.

Коръәни-Кәримнең иҗазы хакында тел галимнәре күпсанлы әсәрләр яза, һәм аларда күп кыйммәтле фикерләр әйтелә. Без монда шуларның бер өлешен генә мисал итеп карарга телибез.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм пәйгамбәрлеген игълан иткәч, кяферләр:

«Раббыңнан Аңа төрле могҗизалары иңәргә тиеш түгелме иде?» – дип каршы әйтәләр.

Аллаһ Тәгалә аларга болай җавап бирә:

«…Аларга: «Могҗизалар тик Аллаһның хакимлегендә. Мин исә тик ап-ачык бер үгетләүче» дип әйт! Үзләренә укыган Китапны Сиңа иңдерүебез аларга (могҗиза буларак) җитмиме? Шөбһәсез, анда иман китергән җәмгыять өчен рәхмәт һәм нәсыйхәт бар» («Әл-Ганкәбут», 50-51).

Коръәннең иҗазы – риторикасы һәм стиле, эчтәлегенең байлыгы, үз эченә алган кыйммәтләренең кешелеккә файда итүе, яшерен хәбәрләр бирүе, даими чынбарлыкны күрсәтүе, тәэсирлелек ягыннан өстенлеге кебек бик күп эштә һәркемгә ачык була.

Коръәннең могҗиза булган иң мөһим юнәлешен риторика һәм стиле тәшкил итә. Риторика эчтәлеккә, максатка, проблемага һәм әңгәмәдәшкә күрә, иң кирәкле сүзне әйтүдән гыйбарәт. Коръәни-Кәрим күтәрелгән бөтен мәсьәләләрендә моны иң матур рәвештә чынга ашыра.

Коръәни-Кәрим мәгънәви яктан караганда да бик күркәм. Аерып алган сүзләрдә, төзелгән җөмләләрдә һәм болардан килеп чыккан мәгънәләрдә кечкенә бер ялгышлык табу да мөмкин түгел.

Коръәндә мәгънәле укылыш, дикция дә Җәнабел-Хакка карый. Аны кодси хәдистән аерып торган иң мөһим үзенчәлек бу. Коръән текстын уңайлы сүз белән, яки гарәпчә булган башка бер кәлимәгә алмаштыру, әгәр белә торып болай эшләсә, кешене кяферлеккә чыгара; хата буларак эшләнсә, мәгънәнең билгеле дәрәҗәдә үзгәрүе сәбәбе белән, гыйбадәтнең төгәлсезлегенә китерә. Мондый теләмичә ясалган ялгыш әйтелеш яки сүз алмаштыруның куркыныч нәтиҗәләре хакында галимнәр фикһ китапларында «зеллетул-кари» исеме астында бик күп аңлатмалар бирә. Димәк, Коръәнне аңларлык дәрәҗәдәге тәрҗемәләре белән дә гыйбадәт кылырга мөмкин дигән сафсаталар нинди зур газапка илтерлек иман хатасыдыр!

Коръән стилендә мәгънә һәм сүз балансы бар. Бу хакта Ибне Гатиййә рәхмәтуллаһи галәйһи болай ди: «Коръән шундый бер китап ки, аннан бер сүз алып ташланса, аның урынына алмаштыру өчен бөтен гарәп теле китерелсә дә, аннан да муафыйк сүзне табу мөмкин булмый».

Һәр пәйгамбәрнең могҗизасы үз дәверенә карый. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә бөтен кешелеккә пәйгамбәр буларак җибәргәнлеге өчен, Аның иң бөек могҗизасы булган Коръәни-Кәримнең көче, бөтен заман һәм җирләргә кыямәткә кадәр дәвам итә.

Коръәни-Кәримдә, Җәнабел-Хакның асылы һәм кодрәтенең дәлиле булу өчен, күп төрле тапкыр фәнни хакыйкатьләр дә урын алган. Мең дүрт йөз елдан бирле фән өлкәсендә булган баш әйләндергеч алгарыш һәм ачышлар Аның һичбер әйткәнен ялганга чыгара алмыйча, киресенчә, һәрвакыт раславы да Аның могҗизаларын күрсәтә.

Коръәни-Кәрим һәр яклап бөек бер могҗиза. Менә шуның аркасында Коръәни-Кәрим ул вакытта дөрес һәм матур сөйләмнең югары дәрәҗәсенә ирешкән гарәпләргә һәм кыямәткә кадәр килеп китәчәк кешеләр һәм җеннәргә, аның белән ярышырлык булган бер сүз уйлап табарга тәкъдим итеп, гасырлар дәвамында бу бәйгедә җиңеп бара. Бу хакта Коръәни-Кәримдә башта «Тур» сүрәсенең 34 нче аяти кәримәсендә: «(Мөшрикләр, Коръәннең Аллаһ сүзе түгел дигән дәгъваларында) дөрес (һәм ихлас) булса, аның кебек бер сүз китерсеннәр!» – дип әйтелә.

Җәнабел-Хак «Исра» сүрәсенең 88 нче аяти кәримәсендә дә болай ди: «Әйт: Кешеләр һәм җеннәр, берберләренә ярдәмче буларак бу Коръәнгә охшашын ясарга теләсәләр, ант булсын, бернинди охшашын да ясый алмаслар».

Мөшрикләр, бу илаһи мөрәҗәгать каршында сүзсез калганнан соң, Җәнабел-Хак, аларның бу эштә булдыксыз булуларын тагын да анығрак күрсәтү өчен, түбәндәге аяти кәримәне иңдерә: «Әллә аны уйлап чыгардымы диләр? Әйт: «Алай булса, сез дә аның кебекне уйлап табыгыз, уйлап чыгарылган ун сүрә! Әгәр дөрес (һәм ихлас) булсагыз, Аллаһтан башка кемне чакыра аласыз, (ярдәмгә) чакырыгыз!» («Һуд», 13).

Өченче очракта, эшне тагын да җиңеләйтеп, бары тик бер сүрәнең генә охшашын китерүләрен тели («Йунус», 38). Монда да гаҗиз калгач, дүртенче очракта нинди дә булса бер сүрәнең охшашын, ягъни бер өлешен, анарга охшаган бер сүз китерүләрен теләде: «Кулыбызга иңдерелгән Коръәннән шөбһә итсәгез, сез дә аның кебек бер сүрә уйлап табыгыз; әгәр дөрес сүзле икәнсез, Аллаһтан башка, үзегез ышанганнарны да ярдәмгә чакырыгыз» («Әл-Бәкара», 23).

Коръәни-Кәрим шигырь дә, проза да түгел. Киресенчә, шигырьнең һәм дә әсәрнең дә үзенчәлекләрен үзенә туплаган бер стильдә ул, һәм бу стильгә хас гаҗәеп бер гармониясе һәм эчке музыкасы бар. Коръән укыган вакытта, кеше бу эчке музыка тәэсирен күңеленең иң төпкелендә хис итә ала. Коръәннең текстында кечкенә генә бер урынны алмаштыру яки нинди дә булса бер үзгәртү кертү, аның моңын һәм мәгънәсен шунда ук боза.

Коръәни-Кәрим, бу үзенчәлеге белән кешеләрнең күңелләрендә гадәттән тыш көчле тәэсир тудыра, гарәпләр аны Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мөбарәк авызыннан тыңлап, төркем-төркем иманга килә. Бөтен мөшрикләр, бер охшаш нәрсә уйлап таба алмаулары сәбәпле, Коръәннең дөрес һәм матур яңгырашын рухлары белән таныйлар. Алар Коръәнне, бары тик үзләренең дөньялык мәнфәгатьләренә туры килмәгәнгә һәм ниндидер бер ятимгә буйсыну аларга авыр булганга күрә генә кабул итмәгәннәр.

Мөхәммәд пәйгамбәрлек вазыйфасын алган тәүге елларда шигъри бәйгеләрдә җиңү яулап танылган, әсәрләре Кәгъбәнең диварына эленгән Имриүл-Кайсның бертуганы әле исән булган. Аңа Коръәни-Кәримнән бернечә аять укыйлар. Дөрес һәм матур сөйләм кагыйдәләрен бик яхшы белгән бу хатын Коръән аятьләрен ишеткәч:

«Бу бер кешенең сүзе була алмый. Әгәр җир йөзендә мондый шигырь бар икән, кардәшемнең шигыре Кәгъбә диварында эленеп тору дөрес түгел. Аны төшереп, урынына бу сүзне элергә кирәк», – дип әйтергә мәҗбүр кала, һәм кардәшенең касыйдәсен үз куллары белән Кәгъбә диварыннан алып куя. Аннан дәрәҗәсе белән түбәнрәк булган башка шигырьле такталарда, кире кагырлык сүзләре калмаганлыктан, берәм-берәм дивардан төшерелә.

Сәламәт акыллы кешегә Коръәнне бары тик тыңлау гына да аның Хак Тәгалә сүзе икәнлеген аңларга җитә. Шул сәбәпле Әфәндебез галәйһис-саләту вәссәламгә Коръәни-Кәримне кешеләргә ишеттерү йөкләнә дә.

Мәсәлән, аяти кәримәдә әйтелә: «Әгәр мөшрикләрдән берсе Синнән иминлек теләрсә, аны якла. Аллаһның сүзен ишетә алсын (уйлап йөрсен, хакыйкатьләргә төшенсен). Соңыннан аны ышанычлы урынга илт…» («Әт-Тәүбә», 6)

Димәк ки, Аллаһ сүзнең колакларга барып җитүе иман нурының йөрәктә урын алуына бер форсат булып тора. Коръән сүзендәге моң һәм музыка, андагы аваз тәртибеннән, ягъни сүзләрнең, хәрефләрнең, сукун вә хәрәкәләрнең, озын вә кыска иҗекләрнең иң камил формада тезелүеннән барлыкка килә. Үзенчәлекле бер тавыштан икенчесенә күчкәндә барлыкка килгән гаҗәеп моң белән йөрәкләр тетрәнә. Мәгънәсен аңламаганнар да, ысуллары һәм кагыйдәләре үтәлерлек итеп укыганда, аның тиңсез яңгырашынан ләззәт алырлар.

Утыз Имәни шәҗәрәсе

Лениногорск районының Куакбаш авылы мәдәният йортында милли рухлы, затлы-зыялы чара булды: Әлмәттә яшәүче төбәк тарихчысы Әлфия Ямаеваның «Габдеррәхим Утыз Имәни нәселе шәҗәрәләре» дип аталган фәнни-документаль китабы халыкка тәкъдим ителде.

Чарага Әлмәт һәм Лениногорск районнарыннан, Чаллыдан төбәк тарихчылары, дин әһелләре, язучылар, Утыз Имәнинең нәсел дәвамчылары җыелган иде. Әлмәтнең үзеннән, сәнгать әһелләрен дә алып, дистәдән артык кеше килде, төбәк тарихчылары Дамир Таҗиев, язучы Минзифа Әхмәтшина, Альбин Вәлиев, Лениногорскидан күп китаплар авторы Рәсим хәзрәт Хәбибуллин, районның мөхтәсибе Булат хәзрәт бу якларның бай тарихына, Әлфия Ямаеваның китабына зур бәя бирде. Әйе, озак еллар буе архивларда, ревизия материалларын, мөселман-татарларның метрикаларын өйрәнеп, шушы төбәкнең Югары Чыршылы, Куакбаш, Зәй-Каратай, Түбән Чыршылы, Сарабиккол, Тимәш авылы кешеләре белән аралашып, Әлфия ханым Утыз Имәнинең өч меңгә якын нәсел дәвамчысын тапкан, аларның 1227 сен китабына керткән.

Әлфия Ямаева Казанда төзүчеләр институтын тәмамлаган, чирек гасыр Әлмәттә проект институтында инженер, конструктор, бүлек җитәкчесе булып эшләгән, күп еллар нефть өлкәсендә дә хезмәт куйган. Соңгы 20 елда ул төбәк тарихын һәм шәхесләр язмышын өйрәнү белән шөгыльләнә. Ул шушы төбәктә йөздән артык шәҗәрә төзегән кеше, шәҗәрә төзү методикасын эшләгән белгеч. Әлфия Ямаеваның моңа кадәр «Чәшелем – асыл илем», «Югары Чыршылы кабер ташлары ни сөйли?», «Фәттах хәзрәт балалары», «Ай нурында нәсел сукмагы», «Сугыш чоры хатирәләре», «Зичәбаш чукмарлары» китаплары басылып чыккан. Әле дөнья күрмәгән «Ризаэддин Фәхреддиннең нәсел шәҗәрәсе» дип аталган 450 битлек кульязма хезмәте үз чиратын көтә...

Әлфия Ямаева үзе дә Ризаэддин Фәхреддиннең дүртенче буын туганы булып чыкты, бу документлар белән расланa. Затлы, укымышлы нәселдән булган Әлфия ханым, төбәк тарихын өйрәнгәндә, төп игътибарын архив документларына, гарәп язулы метрика кенәгәләренә, никах белешмәләренә, ревизия кәгазьләренә, борынгы кабер ташларына, нәсел шәҗәрәләренә юнәлтә, халык күңелендә сакланган истәлек-хатирәләр дә аңа нык ярдәм итә.

Ә Утыз Имәни китабындагы төп ачышы, яңалыгы – Әлфия ханым, архив документларына нигезләп, Утыз Имәнинең өч хатыныннан туган егерме баласының да исемнәрен ачыклаган, нәсел шәҗәрәләрен төзегән. Китапның саф татар телендә булуы, тарихи һәм бүгенге фотолар, шәҗәрәләр, архив документлары белән баетылуы кабул итүне җиңеләйтә. Бәлки бу хезмәт белән риза булмаучылар да табылыр, ул үзе дә моңа кадәр Утыз Имәни турында язылган хезмәтләрдән шактый ялгыш тапкан. Тарих шулай языла инде ул, фән шулай алга бара, яңа табылдыклар искеләренең хаталарын төзәтә.

Әлфия Ямаева барлык китапларын да үз хисабына чыгара, шуңа күрә Утыз Имәни турында китабы да нибары 150 данә генә басылган. Бу китапның Әлмәттә һәм Казанда да зурлап презентацияләрен уздырырга иде, әмма уздырырлармы икән, ай-һай... Моның өчен китапның кыйммәтен аңларга, кешенең кадерен белергә кирәк бит!

Көчләп чукындыруларның иң аяусыз вакытында, XVIII гасыр уртасында дөньяга килгән Габдеррәхим Утыз Имәни әл-Болгари дини һәм иҗтимагый яктан шул чорның әйдәп баручы лидерына әйләнә. Озын һәм катлаулы гомерендә ул үзеннән соң йөздән артык дини-әдәби эчтәлекле хезмәт калдыра, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны кульязмаларына тәнкыйди анализ ясап, төп нөсхәне булдыра, аны 1839 елда Казанда бастырып чыгара. Моңа өстәп, ул мәдрәсәләр салдыра, шәкертләр әзерли, китаплар яза. Карагруһларга, милләтне һәм динне сатып көн күрүчеләргә, динне бозучыларга каршы кискен көрәш ача. Нәтиҗәдә, хакимият аны, ул милләтне изүче хакимиятне дошман итә.

Госман улы Габдеррәхим Куакбашта 1805-1809 елларда яши, 1821-1823 елларда авылда мәдрәсә төзетә, яраткан кызын да шушы авыл кешесенә кияүгә бирә. Хәзер Куакбашта Габдеррәхим хәзрәтнең дистәләгән нәсел дәвамчылары яши, бу чарада алар да чыгыш ясады. Бу авыл тарихы, гомумән, үзе дә аерым өйрәнүгә лаек. Дөрес, 2012 елда Мәмдүдә Вәлиуллина һәм Фәрхәт Шәйхетдиновларның «Туган авылым – Куакбаш» дип аталган китаплары басылып чыга, бу җыенда Мәмдүдә апа үзе дә бик үтемле чыгыш ясады. Халыкның сөйләве буенча, 1920 елгы сәнәкчеләр сугышы вакытында Куакбашта аларның үзәкләре була, ике яктан да күп кеше үлә. Куакбашны болай гына буйсындыра алмагач, кызыл гаскәриләр, тау башына пулемет куеп, авыл халкын кырып сала... Бу канлы тарих та әле ахыргача ачылмаган һәм өйрәнелмәгән.

Мәдәният йортында Коръән белән башланган очрашу мәчеттә бергәләп намаз уку, милли һәм дини көрәшчеләребез рухына дога кылу, уртак табын белән тәмамланды.

Фәүзия БӘЙРӘМОВА.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

8 апрель – зур залда – «Сәфәр» (А.Шакиров). Кече залда – «Көл» (К.Митани).
9 апрель – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
11 апрель – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
12 апрель – зур залда – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев). Кече залда – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
13 апрель – «Тормышмы бу?..» (Г.Исхакый).
14 апрель – «Рәшә» (Ә.Еники).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

7,8 апрель – «Паяцы» (Р.Леонкавалло).
12, 13 апрель – «Травиата» (Дж.Верди).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

7 апрель – «Аферист» (Н.Исәнбәт).
8 апрель – «Кияүләр» (Х.Вахит).
9 апрель – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
12 апрель – 14.00 – «Татар теле – сәхнә теле» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Ашина» (Р.Зәйдулла).
13, 14 апрель – Премьера. «Яратам! Бетте-китте!».

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

9 апрель – «Супер кияү» (Т.Миңнуллин).
10 апрель – «Гөлчәчәк» (Татар халык әкиятенә нигезләнеп куелган).
11 апрель – 13.00 – «Сәлам, Актәпи!» (А.Сальникова). 18.30 – «Корт» (Ф.Галиев).
12 апрель – «Шәй-бу! Шай-бу!» (К.Кәримов).
13 апрель – «12 адым» (Б.Минкин).
14 апрель – «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

7 апрель – зур залда – Премьера. «Конек-горбунок» (П.Ершов әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы). Кече залда – «Адәмнәр» (Г.Ибраһимов).
8 апрель – Премьера. «Конек-горбунок» (П.Ершов әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы). Кече залда – «Сертотмас үрдәк» (А.Алиш).
9 апрель – зур залда – «Муха-цокотуха» (К.Чуковский). Кече залда – «Серая шейка» (Д.Мамин-Сибиряк әсәренә нигезләнеп куелган).
11 апрель – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина).
13, 14 апрель – Саратов курчак театрының «Бременские музыканты» спектакле.

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

7 апрель – Татарстан Республикасы филармония джаз оркестры һәм Аркадий Шилклопер башкаруында джаз премьералары яңгыраячак.
8 апрель – Ева Геворгянның фортепиано концерты.
9 апрель – 11.00 – Балалар өчен «Бременские музыканты» музыкаль әкияте. 17.00 – «Свадьба в Малиновке» опереттасы.
11 апрель – Башкортстан Республикасы милли симфоник оркестры концерты.
14 апрель – Татарстан Республикасы халык музыка уен коралары оркестрына Ф.Кузнецов һәм Р.Галимова кушылып җырлый.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

7 апрель – Мобилизацияләнгәннәрнең гаиләләре өчен хәйрия концерты. Катнашалар – Татарстан Республикасының Миләүшә Тәминдарова җитәкчелегендәге дәүләт камера хоры, С.Гобәйдуллина исемендәге заманча музыка үзәгенең Анна Гулишамбарова җитәкчелегендәге оркестры. Дирижер – Ләйлә Гарифуллина.
8 апрель – «Рахлин сезоннары» XII халыкара фестивале кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт академия симфоник оркестры концерты. Дирижер – Деян Савич. Солист – Нарек Ахназарян (виолончель).
9 апрель – 12.00 – Казан хореография училищесы укучылары концерты. 18.00 – Рус гитарасының патриархы Андрей Сихраның 250 еллыгына багышланган концерт. Солист–гитаристлар Айнур Бегутов һәм Сергей Руднев, Асия Гәрәева (скрипка), Валерий Ксенофонтов (гитара), Анна Халлдорсдеттир (вокал), Роман Вәлиев (гитара).
10 апрель – Башкортстан Республикасы милли симфоник оркестры концерты. Дирижер – Дмитрий Крюк.
12 апрель – «Рахлин сезоннары» XII халыкара фестивале кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт академия симфоник оркестры концерты. Дирижер – Алессандро Кадарио. Солист – Фредерик Кемпф (фертепиано).

Борычлы шоколад эчәсеңме?

“Шоколад” сүзе борынгы ацтекларның “чоколатль” сүзеннән килеп чыкса да, әлеге халыкның хәзерге шоколадка бернинди катнашы да юк. Эш шунда: ацтеклар какаодан тозлы, борычлы, бик ачы эчемлек – чоколатль гына ясый белгән. Испан конкистадорлары исә башта әлеге эчемлеккә шикәр кушып эчәргә җайлашкан, аннан соң бөтенләй тоз һәм борыч салмый башлаган. Уналтынчы гасырда Испания короле шоколад әзерләү серен чит ил кешеләренә ачуны тыйган, аны саклый алмаган шактый испан җәзалап үтерелгән.

(“The Local”).

Тактадагы җәүһәрләр

Японияней Нара шәһәрендә яшәүче рәсем укытучысы һәм графика дизайнеры Хиротаки Хамасаки, мәктәп тактасына акбур белән картиналар ясап, 2012 елда бөтен дөньяга танылган һәм популярлыгы елдан-ел арта бара. Егет атаклы рәссамнарның картиналарын һәм анимэ фильмнары күренешләрен ясый. Дәресләр беткәч, башка мөгаллимнәр өйләренә тарала, Хиротаки исә берничә сәгать буе яңа картинасын язып мәш килә – иртән укучылары килешкә сурәт әзер булырга тиеш бит! Балалар аның чираттагы иҗат җәүһәрен карап рәхәтләнә дә, фотога төшереп, Интернет челтәренә куя, шул рәвешле башкалар хозурына да җиткерә. Акбур белән ясалган сурәтләр Япониядә шулкадәр популярлашкан ки, сыйныф тактасы җитештерә торган Nichigaku компаниясе моны үзен рекламалау өчен файдаланырга булган һәм ил буенча иң шәп рәссамны билгеләүгә конкурс игълан иткән. Хәзер бәйге ел саен үткәрелә, акбур белән ясалган картиналар да камилләшкәннән-камилләшә бара. Хамасаки талантына мөкиббәннәр саны бөтен дөнья буйлап инде миллионнарча исәпләнә. Рәссамны метрополитен бизәргә дә чакырганнар, ул анда да искиткеч сурәтләре белән таң калдырган.

(“Livemaster.ru”).

Алтынга тиңнәр юк

Алтын – иң кыйбатлы гына түгел, иң сыгылмалы металл да. 1 грамм алтыннан 2,4 чакрым озынлыктагы чыбык сузып яки кеше чәченнән 500 тапкырга юкарак фольга ясап була. Алтын – иң инерт металл, ул кислоталар катнашмасында яки кайнар селен кислотасында гына эри. Кешелек тарихында барлыгы 201 296 тонна алтын табылган, җир астында тагын 53 мең тонна запас бар дип санала. Барлык табылган алтынның 46 проценты (93253 тоннасы) зәркән эшләнмәләр рәвешендә, 17 проценты дәүләтләрнең халыкара резервларында саклана.

(“Fishki.net”).

● Сәмәркандтагы Олугбәк обсерваториясе.

Йолдызларга гашыйк хан

1394 елның 22 мартында Аксак Тимернең оныгы Олугбәк дөньяга килә. Кырыс һәм рәхимсез ханның оныгы нечкә күңелле шагыйрь һәм галим Гариф Азари тәрбиясендә үсә. Бабасы үлгәннән соң, Олугбәк Сәмәрканд һәм Бохара хакиме булып кала, ә 1447 елда әтисе Шаһрух бакыйлыкка күчкәч, улы аның эшен дәвам итә. Данлыклы бабасы үрнәгендә сугышлар алып барса һәм хәтта Фирганәне яулап алса да, Олугбәкне иң кызыксындырган нәрсә астрономия була. 1424-1428 елларда ул обсерватория төзетә. Астрономнар Олугбәк җитәкчелегендә күк картасын сыза. 1018 йолдыз кертелгән әлеге карта 200 ел буе иң төгәл күк картасы булып санала (Җирдән телескопсыз гына барлыгы 6 мең йолдыз күренә). 1449 елда Олугбәкне явызларча үтерәләр, обсерваториясен җимерәләр. Бохара мәдрәсәсе порталына Олугбәк сүзләре язылган: “Белемгә омтылу – һәр мөселманның бурычы”, – диелгән.

(“Интересно.cc”).



● Джим Льюис (сулда) һәм Джим Спрингер психолог Томас Бушар белән.

39 елдан соң күрешү

Ерак 1939 елда Американың Пиква шәһәрендә 15 яшьлек кыз игезәк бала тапкан һәм, үзенең тәрбияләп үстерергә хәленнән килмәячәген белгәнгә, аларны уллыкка биргән. Өч атнадан бертуганнарны аерганнар. Берсе Пиквада яшәүче Спрингерлар гаиләсендә калган, икенчесен Льюислар гаиләсе Лайм шәһәренә алып киткән. Уллыкка алган сабыйларының игезәк сыңары икәнен белмәгән ике гаилә дә, үзара сүз куешмыйча, малайларга Джим исемен кушкан. Гомере буе нәрсәдер җитешмәвен тоеп яшәгән Джим Льюис 39 яшендә эзләнә башлаган һәм игезәк сыңарын тапкан. Күрешкәч, гаҗәеп фактлар ачыкланган. Мәктәптә укыганда, икесе дә математиканы яраткан, матур язуны кулалмаган, икесе дә Линда исемле кызга өйләнгән, берничә елдан соң аерылып, икенчегә өйләнгән – бу юлы хатыннары Бетти исемле булган. Улларына да бер генә хәрефе белән аерылган – Джеймс Алан һәм Джеймс Аллан дип исем кушканнар. Икесе дә бер үк төрле тәмәке тарткан, баш әйләнгәннән интеккән, бер үк төрле сыра яраткан, зәңгәр төстәге Chevrolet машинасын йөрткән, ел саен Флорида штатындагы бер үк комлыкка ял итәргә йөргән, балта остасы булган, сызым сызарга яраткан. Ике Джимның тарихы Минесота университеты психологы Томас Бушарны яңа тикшеренү башларга рухландырган, ул аларны һәм балачакта бер-берсеннән аерылган тагын 137 пар игезәкне 1979 елдан 1999 елга кадәр өйрәнгән. Мондый нәтиҗәгә килгән: игезәкләрнең шәхес булып формалашуы кимендә 50 процентка генетикага, калганы исә алар үскән мохиткә бәйле икән. Джимнарга хәзер 80 тулып узган, Льюис – Элида, Спрингер исә Дейтон шәһәрчегендә, берничә айга бер тапкыр күрешеп, хәлләрен белешеп яши.

(“USA Today”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

10 апрель «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00, 18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
11.30, 16.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «КАЛДЫРМА МИНЕ». 12+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
19.00, 0.25 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 0.40 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Татар сүзе». 6+
17.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Ватандашлар». 16+
19.30, 0.15 «Калеб». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПРОСТАЯ ЖИЗНЬ». 12+
14.35 «Вместе в космос». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Сети обмана. Фальшивая реальность». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». 12+
23.40 «ПОЧКА». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛЮБОВЬ ПРЕОДОЛЕЕТ ВСЁ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Елизавета Кульман.
7.35 «Хозяйки Удоры».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45, 12.25 «Забытое ремесло».
9.05 «Бельмондо Великолепный».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Два портрета на звуковой дорожке. Изабелла Юрьева и Вадим Козин».
12.40 Линия жизни. Карэн Бадалов.
13.35 «СТАРЕЦ ПАИСИЙ И Я, СТОЯЩИЙ ВВЕРХ НОГАМИ».
15.00 Новости. Подробно. АРТ.
15.15 «Агора».
16.20 Спектакль «Лунев сегодня и завтра».
17.35 «Посёлок Юрино. Марий Эл. Шереметевский замок».
18.05 «Русское церковное пение от знаменного распева до Рахманинова».
18.50 Цвет времени. Иван Крамской. «Портрет неизвестной».
19.00 «Александр Островский. Пьеса моя сыграна...»
19.45 Главная роль.
20.05 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТЫЕ».
20.50 «Спокойной ночи, малыши!»
21.10 «Хранители жизни. Бурденко».
21.55 «Сати. Нескучная классика...»
22.40 «ОБИТЕЛЬ».
23.40 «Завтра не умрет никогда».

«НТВ»

4.50 «ФЕМИДА ВИДИТ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.10, 0.00 «МЕТОД МИХАЙЛОВА». 16+
0.40 «УГРО». 16+

Сишәмбе

11 апрель «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00 «Азбука долголетия». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «КАЛДЫРМА МИНЕ». 12+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40, 17.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Ватандашлар». 16+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Татар сүзе». 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПРОСТАЯ ЖИЗНЬ». 12+
14.35 «Вместе в космос». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Плесецк. Таежный космодром». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». 12+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «ПОЧКА». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛЮБОВЬ ПРЕОДОЛЕЕТ ВСЁ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Новые люди Переславля и окрестностей».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45, 20.05 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТЫЕ».
9.30, 19.00 «Александр Островский. Пьеса моя сыграна...»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Вечер поэзии в Лужниках».
12.20 «Видимое невидимое. Александрина Вигилянская».
13.15 «Забытое ремесло».
13.30 «Игра в бисер» «А.Н. Островский. «Гроза».
14.15, 23.40 «Завтра не умрет никогда».
15.00 Новости. Подробно. Книги.
15.15 «Эрмитаж».
15.45 «Сати. Нескучная классика...»
16.30 Спектакль «Лунев сегодня и завтра».
17.35 «Ростов-на-Дону. Особняки Парамоновых».
18.05 «Русское церковное пение от знаменного распева до Рахманинова».
19.45 Главная роль.
20.50 «Спокойной ночи, малыши!»
21.05 «Несломленные».
21.55 «Белая студия».
22.40 «ОБИТЕЛЬ».

«НТВ»

4.50 «ФЕМИДА ВИДИТ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.10, 0.00 «МЕТОД МИХАЙЛОВА». 16+

Чәршәмбе

12 апрель «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00, 0.50 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «КАЛДЫРМА МИНЕ». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 0.25 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.00 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Иөрәктән - йөрәккә». Азат Тимершәех турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Татар сүзе». 6+
17.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.30 «Ватандашлар». 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПРОСТАЯ ЖИЗНЬ». 12+
14.35 «Первые в мире». 12+
14.50 «Звездные войны Владимира Челомея». 12+
15.40 «Собаки в космосе». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». 12+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛЮБОВЬ ПРЕОДОЛЕЕТ ВСЁ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Скажи мне, Новгород...»
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45, 20.05 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТЫЕ».
9.30 «Александр Островский. Пьеса моя сыграна...»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Все, что на сердце у меня... Соловьев-Седой».
12.20 Дороги старых мастеров. «Палех».
12.35 «Город №2».
13.15 «Забытое ремесло».
13.30 Искусственный отбор.
14.15, 23.40 «Завтра не умрет никогда».
15.00 Новости. Подробно. Кино.
15.15 «Библейский сюжет».
15.45 «Белая студия».
16.30 Спектакль «Пока бьется сердце».
17.55 Сказки из глины и дерева. Богородская игрушка.
18.05 «Русское церковное пение от знаменного распева до Рахманинова».
18.50 Цвет времени. Николай Ге.
19.00 200 лет со дня рождения Александра Островского. «Александр Островский. Пьеса моя сыграна...»
19.45 Главная роль.
20.50 «Спокойной ночи, малыши!»
21.10 «Игорь Курчатов».
21.40 День космонавтики. Линия жизни. Александр Александров.
22.40 «ОБИТЕЛЬ».

«НТВ»

4.55 «ФЕМИДА ВИДИТ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.10, 0.00 «МЕТОД МИХАЙЛОВА». 16+

Пәнҗешәмбе

13 апрель «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
10.00, 23.00 «ТАИНСТВЕННАЯ СТРАСТЬ». 12+
11.00, 0.40 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «КАЛДЫРМА МИНЕ». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Рыцари вечности». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10, 0.15 «Соотечественники». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «АЛМАШ». 16+
15.25 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Татар сүзе». 6+
17.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.55 «ПРОСТАЯ ЖИЗНЬ». 12+
14.35 «Вместе в космос». 12+
15.00 «Библейский сюжет». 12+
15.30 «Спутник. Русское чудо». 12+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗА ПОЛЧАСА ДО ВЕСНЫ». 12+
22.45 «Большая игра». 16+

23.45 Подкаст.лаб «Собрались с мыслями». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛЮБОВЬ ПРЕОДОЛЕЕТ ВСЁ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Душа Петербурга».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45, 20.05 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТЫЕ».
9.30, 19.00 «Александр Островский. Пьеса моя сыграна...»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Бал Вячеслава Тихонова, или Герой нашего времени».
12.30 «Купола под водой».
13.20 «Забытое ремесло».
13.35 Абсолютный слух.
14.15, 23.40 «Завтра не умрет никогда».
15.00 Новости. Подробно. Театр.
15.15 Моя любовь - Россия! «Загадки Рюрикова городища и Ярославова дворища».
15.45 «Партитура счастья».
16.30 Спектакль «Пока бьется сердце».
17.40 «Плавск. Дворец для любимой».
18.05 «Русское церковное пение от знаменного распева до Рахманинова».
19.45 Главная роль.
20.50 «Спокойной ночи, малыши!»
21.05 «Могучий мститель злых обид».
21.55 «Энигма. Гектор Инфансон».
22.40 «ОБИТЕЛЬ».

«НТВ»
4.50 «ФЕМИДА ВИДИТ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.10, 0.00 «МЕТОД МИХАЙЛОВА». 16+

Җомга

14 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «КВН РТ-2023». 16+
23.10 «В ЛЕСАХ СИБИРИ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 15.25, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30, 16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Уроки истории». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.15 «Татар сүзе». 6+
17.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
18.20 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Җырлы-моңлы сынчы-тылсымчы Бакый Урманче». 16+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ОСКОЛКИ». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ВОСТОК - ЗАПАД». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.55 «САБРИНА». 12+
15.10 «Библейский сюжет». 12+
15.40 «Салют-7. История одного подвига». 6+
16.30 «НАСЛЕДНИКИ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос». 12+
23.30 «Вызов. Первые в космосе». 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Моя мелодия». 12+
23.30 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Хранители жизни. Бурденко».
8.15 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 «БЕЗ ВИНЫ ВИНОВАТЫЕ».
9.30 «Александр Островский. Пьеса моя сыграна...»
10.15 «ПРАВДА - ХОРОШО, А СЧАСТЬЕ ЛУЧШЕ».
12.50 «Библиотека Петра: слово и дело».
13.20 «Забытое ремесло».
13.35 Власть факта. «Реформы Дэн Сяопина и китайский путь».
14.15 «Завтра не умрет никогда».
15.00 Письма из провинции.
15.30 «Энигма. Гектор Инфансон».
16.15 «Андреевский крест».
17.00 «Царская ложа».
17.40, 23.45 Владимир Спиваков, Национальный филармонический оркестр России, Академический Большой хор «Мастера хорового пения». С. Рахманинов. «Колокола». Поэма для симфонического оркестра, хора и солистов.
18.25 90 лет Юрию Оганесяну. Линия жизни.
19.45 «Андрей Рублев». Начала и пути».
20.25 «СТРАСТИ ПО АНДРЕЮ».

«НТВ»
4.45 «ФЕМИДА ВИДИТ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «НЕВСКИЙ. РАСПЛАТА ЗА СПРАВЕДЛИВОСТЬ». 16+
22.10 «МЕТОД МИХАЙЛОВА». 16+
0.00 «Своя правда». 16+

Шимбә

15 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Очрашулар эзләп». Габделфәт Сафин концерты. 12+
12.00, 0.30 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
14.30 «Яңа татар җыры-3» конкурсының гала-концерты. 12+
16.30 «Уроки истории». 6+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит шоу». 16+
23.00 «ПОЕЗДКА В ВИСБАДЕН».

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Бату Мулюков турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Синең өчен сөюләрем». Азат һәм Алсу Фазлыевлар концерты. 16+
17.15 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Яратып яшик». Раяз Фасихов концерты. 16+
22.35 «АЛМАШ». 16+

«ЭФИР»
5.00, 0.25 «Человек на своем месте». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайны нашего кино». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «ДЕНЬ РАСПЛАТЫ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ХОЧУ ЗАМУЖ». 12+
14.35 «Вместе в космос». 12+
15.00 «Десять львов А. Тихонова». 12+
15.30 «МОЯ ЛЮБИМАЯ МИШЕНЬ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ДОРОГОЙ ФРЭНКИ». 12+
22.45 «ТАНЦЫ НА ГРАНИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 14.20, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10 «ПроУют».
12.15 «Храм Гроба Господня».
13.00 Схождение Благодатного огня.
14.30 «Иисус. Земной путь».
15.20, 18.20 «Крещение Руси». 12+
19.20 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.30 «ОДНА». 12+
23.30 Пасха Христова.

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00 «Доктор Мясников». 12+
12.00, 14.20, 17.00, 20.00, 23.00 Вести.
13.00 «Схождение Благодатного огня».
15.00 «ТОМУ, ЧТО БЫЛО - НЕ БЫВАТЬ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ДОКТОР СЧАСТЬЕ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.30 «КАМЕННЫЙ ЦВЕТОК. УРАЛЬСКИЙ СКАЗ».
8.50 «Звезды о Небе. Илзе Лиепа».
9.20 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ДЫМ ОТЕЧЕСТВА».
11.45 «Эрмитаж».
12.20 «Звезды о Небе. Юрий Вяземский».
12.50 «Между двух океанов: дикая природа Коста-Рики».
13.45 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
14.50 «Надежда Катаева-Лыткина. Спасти дом Марины».
15.20 Концерт хора Валаамского монастыря в Московском международном Доме музыки.
16.20 «Огонь».
17.45 «ДОЖИВЕМ ДО ПОНЕДЕЛЬНИКА».
19.45 «Звезды о Небе. Наталия Нарочницкая».
20.15 Концерт Олега Погудина в Московском международном Доме музыки.
21.10 «Россия в Святой земле».
22.20 «СЕРДЦЕ НЕ КАМЕНЬ».

«НТВ»
4.55 «Жди меня». 12+
5.40 «ДВОЕ В ЧУЖОМ ДОМЕ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Схождение Благодатного огня».
14.20 «Своя игра».
15.20 «Игры разумов».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Страна талантов». 12+

Якшәмбе

16 апрель
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Гомер китабы». Лилия Муллагалиева концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан - ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Тархан». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Музыкаль мәйдан». 16+
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ЛЮБОВЬ НЕ ПО СЦЕНАРИЮ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Җырларымда мин бәхетле». Фердинанд Фәтхинең иҗат кичәсе. 16+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Ибраһим Нуруллин турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Театрның тажы-Тажетдин». Ринат Тажетдиновның 85 яшьлегенә багышланган юбилей кичәсе. 16+
14.30 «Татар сүзе». III Халыкара телевизион нәфис сүз бәйгесе. 6+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 «Олы юл әйтте...» циклыннан «Алып калыр өмет». Айдар Фәйзрахманов җырларыннан концерт. 16+

«ЭФИР»
5.00 «Человек на своем месте». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайны нашего кино». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Магия вкуса». 12+
8.30 «МОЯ ЛЮБИМАЯ МИШЕНЬ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ПЕРЕПИСАТЬ ЛЮБОВЬ». 12+
14.45 «Блин. Ком». 16+
15.45 «ДЕНЬ РАСПЛАТЫ». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «АДАПТАЦИЯ». 16+
22.50 «ДОБРО ПОЖАЛОВАТЬ В РИМ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.05 «ОДНА». 12+
16.10 «Владимир Мулявин. «Песняры». 16+
19.00 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.55 «На футболе с Денисом Казанским». 18+

«РОССИЯ»
6.05 «ФОРМУЛА СЧАСТЬЯ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Большие перемены».
12.35 «НЕСЛАДКАЯ МЕСТЬ». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Лето Господне.
7.05 Мультфильмы.
8.10 «КОНЕК-ГОРБУНОК».
9.30 Диалоги о животных.
10.15 «ДОЖИВЕМ ДО ПОНЕДЕЛЬНИКА».
11.55 Невский ковчег. Теория невозможного. Елена Мрозовская.
12.25 «Игра в бисер» «А.Н. Островский. «Бесприданница».
13.05 «Я, Майя Плисецкая...»
14.25 Майя Плисецкая и Александр Богатырев в балете П.И. Чайковского «Лебединое озеро». Постановка Юрия Григоровича.
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 «Михаил Абрамов. Русское наследие».
18.35 «Романтика романса».
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 «Синяя птица и друзья».
22.25 «Бесприданница».

«НТВ»
4.50 «КОНТРАКТ НА ЛЮБОВЬ». 16+
6.30 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». 12+
23.20 «Звезды сошлись». 16+

Узган елның 10 маенда иртүк Бөгелмә урамнарын урап йөргән Авазов Гоголь урамындагы дүрт катлы йорт янында яткан ир-атны күрә, аның исерек килеш йоклап ятучы түгел, ә җансыз икәнен чамалый һәм «112» коткару хезмәтенә шалтырата. Ашыгыч ярдәм һәм полиция килеп җиткәнче шул урында тора ул.

Бөгелмәдә вәхшәтле мәхшәр

Оперативниклар кичекмәстән эшкә керешә, чөнки мәрхүмнең үз үлеме белән вафат булмавы күренеп тора. Эзләү-тикшерү эшләре тиз бара, алдан мәрхүмнең 52 яшьлек Андрей Новоселов икәнe ачыклана, шикләнерлек кешеләрне табу өчен дә күп вакыт таләп ителми. Ир кеше җиргә югарыдан, шул турыдагы өч балконның берсеннән төшкән дигән фаразны тикшерү ниятеннән икенче каттагы фатирга килеп керү белән, чынлыкта, барысы да мәгълүм була.

Әнисеннән калган торакта яшәүче 1977 елгы А. Ворониннан тыш анда тагын өч кеше була. 27 яшендәге Роман Захаров коммуналь хезмәтләр өчен түләмәгәнгә, үз фатирында газ, электр өзелгәч, танышы янында оялаган. 1988 елгы Ирина Козлова, ире төрмәгә утыртылгач, кайнанасы белән яшәгән, берничә ай элек аның белән әрләшеп чыгып киткән дә шушында сыенып урын тапкан. Арада иң өлкәне 60 яшьлек Сергей Севастьянов атна-ун көн чамасы Воронин фатирында кунып йөри. Боларга мәрхүм А. Новоселовны да өстәргә кирәк, чөнки аның шушы фатир балконыннан ыргытылуы шикләндерми.

Ошбу агай да – сикәлтәле язмыш кешесе. Гомер көзендә ялгыз калган Андрейның бары тик бер генә туганы, әнисе башка ирдән тапкан 25 яшькә яшьрәк сеңлесе Регина гына бар. Аның белән дә аралашмаган ул, соңгы тапкыр 2009 елда, Түбән Камада яшәүче ханым Кызыл Чишмә авылына әниләре каберенә кайткач очрашалар. Ул чакта абый кеше шул авылдагы әнисеннән калган иске өйдә гомер итә. Соңгы вакытта сукбай дусты А.Воронин фатирында яшәгән. Регина Әүхәдиева җинаять эшендә мәрхүм абыйсының рәсми вәкиле булырга ризалаша, үзләренең канкардәшләр икәнен раслаучы документ та күрсәтә.

Шулай итеп әлеге бер бүлмәле фатирда биш кеше даими яшәгән дияргә мөмкин. Ул гына да түгел, соңгы өч көндә анда Людмила атлы ханым белән 26 яшендәге Сергей Абашин да кунып-төнеп ята әле. Ике улы, бер кызы булган ханым, эшләмичә, әнисе пенсиясе, балалар пособиясе хисабына яшәвен яшерми. С.Абашин ун яшькә өлкәнрәк ошбу хатынның «сожительница»сы икәнен кире кага, әмма өйдәгеләр моның нәкъ шулай икәнен раслап торалар. Сергей наркотик кулланучы булып исәптә тора, ике тапкыр кеше талаган өчен, 18 яшендә 4 еллык шартлы хөкем алган, ике елдан – наркотиклар белән бәйле җинаять кылып, 4 ел ярымга Түбән Камадагы колониягә озатылган һәм 2021 ел язында азат ителгән.

Өйдәге дүрт кеше белән аерым-аерым әңгәмә коргач та, «исерек җинаять»нең ни рәвешле килеп чыгуы аңлашыла, шикләнердәй өч кеше дә тиз ачыклана. Аларның берсе С.Севастьянов шунда, калган икесе С.Абашин белән Л. Булгакова төнге сәгать өчләр тирәсендә чыгып киткән була. Соңгыларын эзләп табу да күп хезмәт сорамый. Кинолог Р.Яһудиннең Чиззет атлы эте әлеге фатирдан чыккач, Гоголь, Ямашев урамнары буйлап җилдерә, ахыр чиктә, Муса Җәлил, Абдулла Алиш урамнары чатындагы йортка алып килә. Парлылар шунда, ир-егетнең әти-әнисе фатирында булып чыга.

Алты кешенең барысы да 7 майда очрашканнан бирле туктаусыз эчүләрен әйтәләр, кайберләре моны бәйрәм итү дип атаса да, әлбәттә, аларның тормыш рәвешен күрсәтә бу. Эшләмичә йөрүче хәерчәннәрнең акча табуына гаҗәпләнергә генә кала. Хәер, аларның күрсәтмәләрендә ошбу сорауга кайбер җаваплар бар. Мәсәлән, өлкән абзый С. Севастьянов 8 майда «Магнит» кибете тирәсен җыештыра, шуның өчен бирелгән тавык, кыяр, сөт, кефир тотып, сәрхүшләр торагына кайта. Роман Захаров мәрхүм Новоселовның «Баба Варя» дип йөрткән карчыкка еш кына супермаркетлардан алынган срогы чыккан азык-төлек кертеп йөрүен, әлеге хезмәт өчен әбинең аракы бирүен, азрак акча да тамызуын сөйли.

Ул көнне, гадәттәгечә, иртәдән үк эчә төркем. Көндез Новоселов, фатирдагы ризыкларны пакетка тутырып ала да, үзенә Р. Захаровны да ияртеп «Баба Варя» янына китә, «күчтәнәч»не тапшырып акчасын алгач, сыйлану мөмкинлеге туа. Бу вакытта сукбайлар фатирында ыгы-зыгы куба, чөнки Новоселовның ашамлыкларны, шул исәптән, Севастьянов эшләп тапкан әйберләрне дә урлавы мәгълүм була. Гаҗәп, ләкин ул көнне хуҗа А. Воронин эчми, күбрәк, шкаф артындагы караватында ята.

Барысы бергә җыелу табын түгәрәкләнә дигәнне белдерми. Севастьянов бурлыкны кичерми, әлбәттә. Абзый Р.Захаровны дөмбәсләп авыз-борынын каната. Яшь-яшь егет каршылык күрсәтми, җавап та кайтармый, күрәсең, кабымлыксыз калдырылган башкалардан да эләгер дип шикләнә. Шулай да җиңелрәк котыла ул. Тынычлана төшкән абзый өстәл артына утыра, Новоселовка аракы да салып бирә, ләкин ошбу тәнәфес озакка сузылмый.

Новоселов та һөҗүмгә күчкән шешәдәше белән кара-каршы бәргәләшми, кухнядан алып чыгып агач уклау белән баш, күкрәк тирәсен тукмый башлый. Аннан чыгып качу ниятеннән ишеккә таба ташлана, әлбәттә, котырынган дустына яный, хак булса, дусларын алып киләчәген әйтеп, барыгызга да «хана» диеп кычкыра. Ләкин качып котыла алмый ул, тикшерү материалларындагы Севастьянов сүзләреннән күренгәнчә, С.Абашин аны подъездан җилтерәтеп алып керә. Менә шуннан соң мәхшәрнең вәхшәтле өлеше башлана, чөнки С. Абашин да «эшкә» керешә, Новоселовка кул белән дә суга, тибә, шул ук уклау белән тукмый. Арага керүче дә, аны туктатырга тырышучы да булмый. Бары тик өлкән яшьтәге Ирина гына үтерәсең бит, дип кычкырып карый, С. Севастьянов «авызыңны яп» дип боергач, ул да тынып кала. Ул гына да түгел әле, ачу-нәфрәтләре кайнаган Людмила да сөйгәненә кушыла, уклау белән идәндә яткан ир-атны тукмарга керешә, бу мәлдә Абашин да тик кенә тормый.

Ахыр чиктә, вәзгыять тынычлана, угрылыкта гаепле Р. Захаров һәм үз теләге белән хәмердән баш тарткан хуҗа А.Ворониннан кала, башкалар эчәргә керешә. Шактый вакыт узганнан соң, әйтүенә караганда, бер ел санитарка булып эшләгән Л. Булгаковага балкон ишеге янында яткан Новоселовның хәлен тикшерергә кушыла. Ханым аның үле икәнен белдерә. Бу хәбәр сәрхүшләрне куркытмый калмый, бераздан С. Севастьянов мәеттән котылырга кирәклеген әйтә, С. Абашин белән икесе Новоселовны балконнан ыргыталар.

Суд-медицина эксперты мәрхүмнең күкрәк читлеге, калак сөякләре, 25 җирдән кабыргалары сынуын, үпкә, талак һәм башка әгъзаларга зыян килүен, эчкә кан тулуын, күп кан югалуын, башка авыр җәрәхәтләр ясалуын күрсәтә. Аларның зур өлеше икенче каттан төшеп бәрелү нәтиҗәсе икәне дә мәгълүм. Искәртеп үтик, җинаять эшендә 52 яшьлек ир-ат өйдә түгел, урамда җан биргән дип санала.

Без фаҗигале вакыйганы тикшерү комитетының Бөгелмә бүлегеннән Т. Әхмәтхановның, башлыча, шаһитлар күрсәтмәләре нигезендә ясалган нәтиҗәләре буенча бәян иттек. Гаепләнүчеләр исә үз гамәлләрен шомартып күрсәтергә тырыша. Алданрак җинаять кылуда шикләнелүчеләр арасына Л. Булгакова да эләгә, чөнки аның да уклау белән мәрхүмнең башына һәм башка урыннарына сугуын әйтеп торучылар бар бит. Ләкин тиздән алар хатын-кыз Новоселовның кулына гына суккалады дип, аны аклый башлыйлар. Хәер, әгәр Людмила башка эләктергән булса да, андагы җәрәхәтләр җиңел дәрәҗәдә, димәк, үлемгә сәбәпче булмаган дип белдерелә. Шулай итеп өч бала анасы шаһит итеп калдырыла, фаш иткеч күрсәтмәләр бирә. Фатир хуҗасы шкаф артында яттым, күрмәдем дип барса, ике хатын-кыз һәм Р. Захаров сөйләп кенә калмыйча, җинаять урынында Севастьянов белән Абашин гамәлләрен манекен ярдәмендә күрсәтеп, аңлатып йөриләр, кара-каршы сорау алганда гаепләнүчеләр алдында сөйләп бирәләр.

С. Севастьянов А. Новоселовның кул һәм күкрәгенә ике тапкыр сугуын гына таный, С. Абашин аяк белән тибүләрен кире кага, икесе дә аны балконнан ташлауларын танымый, шулай да бер-берсенең явызлыкларын тулысынча сөйләргә тырышалар. Кыскасы, әлеге ике кешенең үтерүчеләр икәне икеләндерми. Алар өчен иң хәтәре шунда, тикшерү комитеты һәм прокуратура әлеге җинаять алдан сөйләшү буенча төркем белән эшләнгән дип белдерә. Ә бу исә 8 дән 20 елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган аеруча авыр җинаять санала. Гаепләнүчеләр бернинди дә сөйләшү, килешү булмады, барысы да үзеннән үзе килеп чыкты дип монысын да кире кагалар.

Эш моның белән генә дә бетми әле. Абашин Бөгелмәдә тоткарлангач та, аның инде ай ярым Казандагы «Воровский» полиция бүлеге тарафыннан эзләнүе билгеле була.

2021 елда азат ителгәч тә, Сергей Казанга китә, җәй көне анда бер баласы булган яшь ханым белән танышып китә һәм декабрь аенда алар хатын-кыз фатирында бергә яши башлыйлар. Беренче чорда бар да әйбәт була, кияү кызның әнисе белән дә яхшы гына аралаша. Диананың әйтүенчә, төзелештә эшләп аны һәм кечкенә кызны тәэмин итеп тора, ләкин тора-бара эчеп, холкын күрсәтергә керешә, өстәвенә, аягын сындырып эшкә дә йөрми, аңа кул күтәргән чаклары да була. Бу хәл өлкәннәргә дә барып җитә, алар Диананы теге явыздан коткарырга теләп, фатирларын алмаштырырга була.

2022 елның 31 мартында Воровский урамындагы фатирга С. Абашин килә, өйдәгеләргә Диана белән сөйләшергә теләвен әйтә. Әни кеше сүзне кыска тотып ишекне яба, ләкин теге китәргә теләми, ишек шакуын дәвам итә, аның белән аңлашу ниятеннән ир-ат подъездга чыга. А. Горлов белән С. Абашин арасында ызгыш-тарткалашу башлана, явыз бәндә колак төбенә тондыргач, хуҗа идәнгә ава, аңа ярдәмгә хатын-кыз ташлана, инвалид ирен яклау-саклау максатыннан өстенә ята. Әлбәттә каплап бетерә алмый ул аны, соңрак үткәрелгән экспертиза А. Горловның баш, арка, муенына кимендә 11 тапкыр тибелүен, бер сөяге чатнаганын ачыклый. Бусы кеше саулыгына уртача дәрәҗәдәге зыян дип табыла. Аннан кала күп кенә җиңел җәрәхәтләр булуы да билгеле була. А.Горлов 7 нче шәһәр сырхауханәсендә дәваланып чыга.

Әлеге эшне дә аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүче Т. Әхмәтханов алып бара. С. Абашин гаебен өлешчә генә таныйм дип белдерә, үзен А.Горлов һөҗүменнән сакланучы итеп күрсәтә, шулай да типкәләүләрен яшерми, зарар күрүчедән гафу үтенеп белдерә. Февраль аенда ике эпизодлы җинаять эше Татарстан Югары судына тапшырылды.

Наил ВАХИТОВ.

БИЗӘКЛЕ КҮН ОСТАСЫ

«Хәзинә» милли сәнгать галереясында Татарстанның халык рәссамы, республикабызның атказанган сәнгать эшлеклесе күн остасы Наилә Кумысникованың иҗат әсәрләреннән күргәзмә эшли. Татарстан Рәссамнар берлеге быел Наилә ханымны Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим итте.

Күн сәнгатенең тарихы меңеллыклар белән исәпләнсә дә, белгечләрнең сүзләренә караганда, дөньядагы бүтән бер халыкта да очрамый торган каюлы күнне XVIII гасырда тегелгән аяк киемнәре һ.б. гамәли бизәү әйберләрендә генә күрәбез. Шулай да татар күн сәнгате Алтайда Пазырык курганнарында табылган аяк киемнәренә бик охшаган, дип бара сәнгать белгечләре. XVIII гасырдан башлап каюлы күнне татарлар гына түгел, башка мөселман халыклары да киң куллана. Татар читекләре бөтен Россия буенча чибәр ханым-туташларның мәхәббәтен яулап кына калмый, Франция, Германия һ.б. илләрдә эре күргәзмәләрдә күрсәтелә. Каюлы күннән аяк киемнәрен актриса Вера Комиссаржевская, шагыйрь С.Есенинның хатыны Америка балеринасы Айседора Дункан һ.б. таныган шәхесләр киеп йөргәнлеге билгеле.

XX гасырның канлы сугышлары милли һөнәребезнең үсешен сүлпәнәйтсә дә, ул юкка чыкмый. Арча фабрикасында байтак еллар милли аяк киемнәре җитештерелде. Сугышлар да бетерә алмаган һөнәрнең тамырына үзгәртеп кору еллары балта чаба язды, фабрикабыз эшләүдән туктады. Бүген республикабызның Мәдәният министрлыгы Арчада каюлы күннән әйберләр эшләп чыгаруны кабат торгызмакчы, аны туристлар маршрутына кертеп, янадан халыкара мәйданга кайтармакчы.

Каюлы күн сәнгате сакланган икән, без бу һөнәрнең осталарыннан берсе Наилә ханым Кумысниковага да рәхмәтлебез. Театр белгече Халит Кумысников һәм актриса Асия Хәйруллинаның кызы Наиләгә Казан сәнгать училищесының театраль декорация бүлегендә белем алырга, аннары сәнгати зәвыгын һәм осталыгын атаклы В.Суриков исемендәге институтта камилләштерергә язмыш үзе язган.

Бүген Наилә ханым XVIII гасыр ахыры XIX йөз уртасы гамәли бизәү сәнгате үрнәгендә күзгә бәреп тормаган, табигый төсле аяк киемнәре, янчык, мендәрләр иҗат итеп кенә калмый, каюлы күн сәнгатенә заманча сулыш өреп, төрле төсләрдән композицияләр дә тези. Н.Кумысникова күнне төрле материаллар, мәсәлән, тире белән катыштырып та бу сәнгатькә үзенә күрә яңалык кертте. Аяк киемнәре, мендәрчекләр белән генә чикләнмичә, төрле зурлыктагы дивар панноларын иҗат итеп, Халит кызы Наилә каюлы күнне гамәли-бизәү сәнгатеннән монументаль югарылыкка күтәрде. Н.Кумысникованың иң яраткан сюжетлары – кошлар, гүзәл чәчкәле оҗмах бакчалары, тармакланып киткән нәсел агачлары һ.б. борынгы халык авыз иҗатыбыздан килә.

«Рәссам Наилә Кумысникованың эскизлары буенча сервизлар ясадылар, республикабызның төрле театрлары, Татарстаныбызның мактанычы булган Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен костюмнар тектеләр. Шулай да иң зур казанышы иҗат әсәрләренең саны күп булуында түгел, борынгы һөнәргә яңа сулыш өрүендә, күп гасырлык традицияне үстергән татар милли стиль барлыкка китерүендә. Аның 1990 нчы елларда беренчеләрдән булып күн остаханәсе оештыруы да, каюлы күн өлкәсендәге новаторлыгы да, Казан Кремлендә табылган археологик материалларны тарихи реконструкцияләве дә, музейларыбыз өчен милли аяк киемнәре ясавы да хәзерге заман мәдәнияте өчен бер үк дәрәҗәдә мөһим», – диде күргәзмәне ачканда сәнгать фәннәре докторы Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән авазлаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 7.04.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2612

16+